Безнең МИРАС

ISSN:2500-011x

09

сентябрь 2016

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

ТАРИХИ, МӘДӘНИ, ПЕДАГОГИК, ДИНИ МИРАС, ТӨПЛЕ ФАРАЗ, ӘДӘБИЯТ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

ХӘЕРЛЕ ЮЛ, ЯШЬ МӨГАЛЛИМ!

16 августта Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов, «Иннополис» фәнни шәһәрчегендә булып, «Һөнәри үсеш һәм укытучы карьерасы» дип аталган яшь педагоглар форумында катнашты. Мәктәпләргә эшкә килүче 200 яшь мөгаллимгә Президентыбыз үзенең теләкләрен ирештерде, гаять җаваплы, катлаулы һәм мактаулы хезмәт юлына чыгулары белән тәбрик итте.

Фотолар president.tatarstan.ru сайтыннан алынды.

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең Мирас 12 +
9 (56)
сентябрь 2016

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АЖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

76

23 **РАВИЛ ӘМИРХАН МИРАСЫ.** *Илдус Заһидуллин*

90 **ИЛАҺИ МОҢ ИЯСЕ.** *Филүсә Арслан*

ЭЧТӘЛЕК

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 *Атилла Расих*

ТАРИХИ МИРАС

4 **Болгар. Археологик тикшеренүләр.**
6 **Зөләйха.** *Ә.Мөхәммәдиев*
12 **«Уйларыбызны әйтүдә бик сак булырга туры килде...»** *Р.Гарипов*
17 **«Йолдыз»ның тарихы.** *Ә.Максуди*
23 **Равил Әмирхан мирасы.** *И.Заһидуллин*
29 **Авыл тарихы — милләт тарихы!** *(Түгәрәк өстәл)*

«БЕЗНЕҢ МИРАС» — 25

38 **М.Мәхмүтов. Ә.Кәримуллин:«Без нинди мираска мохтаҗ?»**

ДИНИ МИРАС

42 **Ишмөхәммәт хаҗи кыйссасы.** *Г.Гатауллин*

ӘДӘБИ МИРАС

48 **Кутадгу билик. (Котайткыч белем).** *Й.Баласагуни*
52 **Чыңгызханның ак болыты.** *Ч.Айтматов*
58 **Һәр әсәре — камиллек үрнәге!** *Л.Тимерова*
64 **Атилла Расих: «Мин шулай өметләнеп ятам...»**
70 **Мәгъсум абый сөлгесе.** *В.Нуриев*
72 **Бер китап эзеннән...** *Г.Давыдова*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

76 **Бер кат кис...** *А.Фәизов*

ТАТАР ГАМЕ

80 **Нурланыш галиме.** *М.Кәримов*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары
Марат Закиров
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Андрей Кузьмин
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Энгель Фәттахов
(ТР премьер-министры урынбасары – ТР фән һәм мәгариф министры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Ирада Әюпова
Альберт Борһанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Данил Салихов
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Ирек Шәрипов

Җаваплы мөхәррир
Фирдәвес Зарифуллин
(843) 222-09-83 (17-91)

Бүлек мөхәррирләре
Ленар Гобәйдуллин
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-90)

Гомуми мәсьәләләр буенча мөхәррир
Рәдиф Сәгъдиев
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

СӘНГАТИ МИРАС

84 **Нурлы сәхнәдә иҗат нуры.** *Ә.Зарипов*
90 **Илаһи моң иясе.** *Ф.Арслан*
96 **Остазым Бакый Урманче.** *Н.Әлмиев*
100 **Бакый аганы сагыну.** *Д.Гайнетдинова*

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

106 **Миллият сүзлеге.** *А.Тимергалин*
109 **Этнонимнар ни сөйли?** *Й.Гәрәй*
111 **Чырткемесь.** *Ф.Госман*

ХӘТЕР САГЫНДА

112 **Әлифба.** *Г.Җәләлева*

100 ЕЛ ЭЛЕК...

114 **«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1916 елның сентябрь ае.** *Л.Гобәйдуллин*

ШАЯН МИРАС

116 **Вак-вак ләтыйфәләр...**

118 **Мирасворд**
119 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Сентябрь*
120 **Резюме**

Заказ №М-2224. Тираж – 1705 данә. Формат 70 X 108 1/16
Басарга кул куелды: 24.08.2016
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә
Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең
Татарстан Республикасы буенча идарәсендә
ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән
туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми
һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта
гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән
башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Бу хакта техник контроль бүлегенә 519-44-61
телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин төшергән,
авторларның һәм Татарстан Милли музее архивларыннан,
«Татар энциклопедиясе» томнарыннан фотосурәтләр, җиде томлык
«Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Тышлыкның 1 нче битендә – «Шәрык натюрморты». 2012 ел.
Киндер, майлы буяу. *Фәридә Хәсьянова рәсеме*

АТИЛЛА РАСИХ
(1915-1996)

***

«Гомер ул, искән җил кебек – уза да китә».

***

«Җимешнең өлгергәч өзелгәне яхшы».

***

«Тормыш иткәндә кайчак түзә белергә дә, гафу итә белергә дә кирәк».

***

«Ахыр чиктә барысын да хәл итүче – мәхәббәт, бары саф мәхәббәт».

***

«Балалар, дип, мәхәббәтсез, тупас, ни тән, ни җан җылысыннан мәхрүм ят хатын белән газап чигү табигать законнарына каршы килә торган бернәрсә түгелмени?»

***

«Тормыш ул бик катлаулы, дип авыз ачсаң – бик гади кебек, ә ул гади бит, дип карасаң – артык катлаулы».

***

«Адәм баласының сыйфаты иң беренче чиратта ана кеше сыйфаты белән билгеләнә. Ана ул кешене тудыручы гына түгел, ул аңа иң әйбәт тойгылар сеңдерүче дә. Ата кешенең дә үз урыны бар. Ул ана белән баланы саклаудан гыйбарәт, ягъни кешелекнең сакчысы ул».

***

«Кыз баланың күркәм горурлыгы: ул егетләр белән дә дус булырга тиеш, егетләрне үз итеп, чын иптәш һәм яклаучы итеп карарга тиеш. Ләкин ул шул ук вакытта ир-атка хас бер кимчелекне дә онытмаска тиеш. Аларда нәсел арттыру инстинкты бик көчле. Бу – җан иясенә хас бер инстинкт, күп очракта мәхәббәткә үрелмәгән хәлдә үсә, ул күп очракта мәхәббәт тойгыларына буйсынмастан, хәтта кайбер вакытта аңа капма-каршы рәвештә дә яши ала. Мондый үзенчәлекне ихтыяр көченә ия булмаганнар җиңә алмый. Кайбер очракта ир кеше, бик намуслы булса да, үзенең изге тойгылары белән җенси теләген гармониядә саклый алмый».

***

«Ихлас күңел белән сөйгән егеткә өмете өзелерлек бер генә усаллык та эшләнергә тиеш түгел. Ир-ат шулчагында гына кызга тартыла һәм бу якынлык тирән мәхәббәткә дә әверелеп китүе мөмкин».

Гыйбарәләрне ***Ләбиб Лерон*** *әзерләде.*

Болгар.
Археологик тикшеренүләр

Сәхифәне Нурсөя Шәйдуллина алып бара.

Дөнья цивилизациясендә халыклар һәм культуралар даими һәм күптөрле рәвештә үзара тәэсир итешкән берничә төп төбәк бар. Идел буе шундый төбәкләр исәбенә керә. Нәкъ менә биредә күп халыкларның тарих сәхифәләре, тиңсез энҗе бөртекләредәй, күп гасырлар буе бер-берсенә йогынты ясап, бер җепкә тезелеп барган.

Идел буе төбәген өйрәнү – глобаль тарихи-мәдәни цивилизация проблемасы. Ул фәннәрнең һәм фәнни эзләнүнең мөстәкыйль юнәлешләренең бер спектрына бәйле. Безнең заманда – дөньяның бөтенлеген җимерүче деструктив факторларның тәэсире әле көчле булганда, дөньяны берләштерү юлларын эзләү һәм табу гаять әһәмиятле.

Идел буе төбәген комплекслы өйрәнү зур фәнни һәм гамәли әһәмияткә ия һәм Россиянең, дөньяның күп шәһәрләреннән төрле белгечләр арасында тыгызрак элемтәләр урнашуга закончалыклы рәвештә ярдәм итә. Бүгенге көндә Татарстан Фәннәр академиясенең, Россия Фәннәр академиясенең, аларның институтларының һәм бүлекчәләренең, Казанда дәүләт структуралары ярдәме белән яңадан оештырылган федераль университетның бердәм эшчәнлеге нәтиҗәсендә комплекслы фәнни тикшеренүләр гамәлгә ашырыла.

Болгар шәһәрлегенең һәм аның истәлекләренең беренче тулы тасвирламасы 1712 елга карый, ул чакта дьяк Михайлов, биредә Успение ирләр монастыре оештырылуга бәйле рәвештә, бу ядкярләрнең исемлеген төзегән. Ун елдан соң, Идел буйлап баручы Петр I шәһәрлеккә туктаган һәм хәрабәләрне караганнан соң, таш корылмаларны саклау чараларын күрергә кушкан.

Шәһәрлеккә системалы тикшеренү эшләре 78 ел элек, 1938 елда А.П.Смирнов җитәкчелегендә башланган. Бу Болгар шәһәренең төрле чорларының тарихы һәм мәдәнияте мәсьәләләре, шул исәптән социаль топографиясе, территориясенең үсеш динамикасы, төзелеше, һөнәрчелеге, сәүдә тармагы, төзекләндерү эшләре һ.б. буенча зур һәм күптөрле материал тупларга мөмкинлек биргән.

2010 елдан башлап, Татарстан Республикасының Беренче Президенты М.Ш.Шәймиев тәкъдиме буенча, эшчәнлеге Болгар музей-тыюлыгы, «Зөя утраукала» музее, Татарстан биләмәсендәге башка тарихи һәм мәдәни истәлекләр үсешенә ярдәм итүгә юнәлтелгән Татарстан Республикасы тарихи һәм мәдәни истәлекләрне торгызу Республика фонды оештырылгач, әлеге бурычларны үтәү буенча киң колачлы эшләр алып барыла башлады.

Программаны гамәлгә ашыру кысаларында 2010-2011 елларда Болгар шәһәрлегендә казу эшләре алып барылды. Алар музейлаштыру һәм тарихи истәлекләр торган биләмәләрне төзекләндерү буенча эшләр барган урыннарда җимерелеп баручы мәдәни катламны өйрәнүгә юнәлтелгән иде.

Археологик тикшеренүләрнең соңгы өч елы эчендә Болгарның урта гасырлардагы тарихы турында уникаль мәгълүмат җыелды. Казу эшләре барышында шәһәрлек территориясендә, аның үзәк өлешендә торак йортлар салынган районнар ачылды, йортларның калдыклары табылды. Бу елларда казу эшләре алып барылган зур объектларның берсе – Хан сарае бинасы. Шәһәрлекнең үзәк өлешендә тикшерелгән зур монументаль биналар исәбенә елга вокзалы янында табылган таш мунча калдыклары да керә.

Планлы эшләр барышында Галанкино күле тирәсендә табылган чүлмәк ясау мичләренең калдыклары ачылды.

Болгарда археологлар өчен махсус комплексның төзелеше тәмамланды. Бу заман таләпләренә җавап бирүче фәнни база булачак, ул халыкара фәнни тикшеренү буенча хезмәттәшлекнең зур үзәгенә әвереләчәк. ■

ЗӨЛӘЙХА*

Әзһәр Мөхәммәдиев

Аның, кем, ал иңендә миң яратты,
Буе берлә сачыны тиң яратты.

Хәрәзми, XIV йөз.

Шәһри Болгарда яшәү дәвере артык озак булмаса да, Бибарсның язмышына ул зур үзгәрешләр кертте. Малай вакытта ук әнисеннән ишетеп калган әлиф, би, ти, си, ягъни әлифба догасы урынына ул мәдрәсәдә укырга-язарга гына түгел, остазы Баяннан дөньяга икенче төрлерәк, тәҗрибәле күз беләнрәк карарга да өйрәнде. Җитезлеге, тырышлыгы һәм уңганлыгы өчен аны Баян үзенең улларыннан ким күрмәде, яратты. Ә Баян вәзир дә булып алгач, инде буй җитеп килгән Бибарс та, аның йомышчысы буларак, патша хезмәтенә күчте. Патша сараена аңа да юл ачылды. Дөрес, ул Баянның яраннарыннан булганга күрә, электән ук патша хезмәтендә булган кайберәүләр аңа кырынрак күз ташлаштыргалый иде. Ләкин ул чигүле күн артугын[1] киң каеш белән буып, пычагының ялтыратып сөяктән эшләнгән бизәкле сабын бераз гына итек кунычыннан чыгарып куеп, күкрәк киереп, башын горур тотып йөрергә өйрәнде.

Шундый көннәрнең берсендә Бибарс, иртәдән үк торып, сарайга юл тотты. Шәһәр уртасындагы патша кирмәне капкасыннан кергәндә текәлебрәк карап торган чаушка салкын гына:

– Вәзир Баян янына! – дип кенә салды.

Кирмән эчендәге йортлар, мәчетләр, сарайларның мәһабәтлеге, хозурлыгы Баянның зур иркен нарат йортына да гаҗәпләнеп караган Бибарс күңелендә тирән эз калдырды.

Ул патша сарае ишеге төбенә якынлашканда йомыш белән килгән кешеләр байтак кына иде инде. Атлылар исә, атларын махсус баганаларга беркетелгән киртәдәге боҗраларга бәйләп, кабул итү вакыты җитүен көтә. Арада түгәрәк кырма сакаллы болгар халкы, озын җитү чәчле кыр ягы халкы, кызгылт-җирән сакаллы чирмешләр (угро-финнар) һәм башка төрле халыклар бар. Шәһри Болгар халкының киң күңелле булуын, йомыш, йә булмаса сәүдә белән йөргән, гомумән, башка халыкларга түземлек һәм ихтирам белән каравын белгәнгә, ул моңа гаҗәпләнмәде. Бер урыс кешесенә икенче бер суар кешесенең аты бик нык охшап киткән, күрәсең, алар, дөньяларын онытып, шунда ук сатулаша да башлады.

– Якши, якши! – диде, урысы булса кирәк, ул кырылмаган чәч-сакаллы иде. – Мин сенин лошадька биш денга бирәм, – ул бармакларын җәеп күрсәтте, – биш денга!

---

* «Зөләйха» – 2 нче саннан (2016) бирле чыгып килгән «Чыңгызхан хәйләсе» әсәренең дәвамы.
[1] Йомшак күннән эшләнгән җилән.

Равил Заһидуллин рәсеме

– Моя лошат (алаша-ат) хаклы! – диде аргамагы янында торган суары. – Тагын пер тәңкә хуш![2]

Кинәт килеп чыккан бу сатулашуның ни белән тәмамлануын көтеп тормыйча, Бибарс эчкә узды. Ул вәзир бүлмәсенә барып кергәндә Хаҗи морза Баян янында кара көеп утыра иде. Күрәсең, тархан нәрсәдер дәгъвалый, ләкин вәзир тарафыннан катгый каршылыкка очраган иде.

Бибарс килеп кергәч, Хаҗи тархан сүзен бүлеп, ачулы йөзен аска иеп, ләкин идәнгә каты басмаска тырышып, күрәсең, Баянның каты куллы вәзир икәнлеген аңлап алган иде, чыгып китте. Баян аның кыр ягыннан икәнлеген ничектер Бибарска сөйләгән иде инде.

– Хәерле иртә, остаз! – дип ачык йөз белән сәлам бирде Бибарс. Ул остазы

[2] Минем алашам кыйммәтрәк. Тагын бер тәңкә куш.

Баянның шундый матур туран келәмнәре эленгән, идәненә кыйммәтле паласлар җәелгән вәзир бүлмәсендә хуҗа булып утыруына куанды. Ә кеше шатлыгына сөенә белүдән дә зуррак күңел күркәмлеге бармы?! Бәлки шуңа күрәдер, Бибарс үзен бик бәхетле тойды.

– Беләсеңме нәрсә өчен чакырдым мин сине?

– Әйтсәң, белермен, остаз!

Ул, Баянның киң күңелле кеше икәнлеген белгәнгә, үзен аның белән иркен тотарга өйрәнгән иде.

– Соңгы дәвердә патшаның кайда булганлыгы, кемне кабул иткәнлеге һәм кем белән сөйләшкәне нindидер юллар белән әллә кайда, ялан-япанда һәм еракерактагы мангул ханы урдасына җиткерелеп тора. Моңарчы миңа беркайчан да синеке кебек яшь, үткер күз-колакның бу кадәр кирәк булганы юк иде әле...

– Син мине, остаз, шымчы итмәкче буласыңмы? – дип сорады йөзенә борчылу чыккан Бибарс.

– Киресенчә, Бибарс, сүз дошман шымчысын тоту турында бара! Син зиһенле, уйлап эшли белә торган, үткен егет. Нәкъ шушы чалым безгә җитми дә. Иртәгәдән башлап син, патша сараена иртә таңнан алып, кичкә кадәр кем кереп, кем чыгып йөргәнлеген бермә-бер хәтерләп кенә түгел, ә аны күз алдында тоту өчен язып та куярга тиеш.

– Сарайга иртә таңнан хәрби сакчылар янынннан үтеп керер өчен им[3] кирәк.

– Имле ир үлмәс, ди мәкаль. Дөрес әйтәсең. Әйдә барып белешеп килик әле караулбашы Гаяннан. Ул үзенең чаушлары янында, каравыл биналары тирәсендә булыр, мөгаен...

Икенче көнне таң атып яктыра башлау белән Бибарс патша сараена ашыкты. Ләкин ничек кенә иртә килмәсен, капка төбендә сарайга керү сәгатен көтеп торучы кешеләрне, шулар арасында Хаҗи тарханны да күрде. Имнең кирәге дә калмады... Көтеп торучыларга ул игътибар белән карады. Алар арасында сәүдәгәрләр, йомышы төшкән шәһәр халкы һәм җиз кыңгыраулар, төрле ялтыравыклы калай кисәкләре таккан бер дивана да бар иде...

Бибарс, капкадан үткәч, сарайга кергән халыкның кайсы-кая таралуын игътибар белән күзәтте. Аннары бакчага керде, соңрак төрле сарайлар, мәчетләр тирәсендә йөрде, ара-тирә күренгән каравышларга да сынаулы караш ташлады, ләкин нинди дә булса бер нәтиҗәгә килә алмады.

Зур һәм гүзәл патша сарае янына барып чыккач, Баянны исенә төшерде һәмниләр күргәнлеген сөйләп киңәшеп чыгарга уйлады.

Әле вакыт бераз гына иртәрәк булганга күрә, ул сарайның арткы ягына – Иделнең тирән яры күренеп торган якка чыкты һәм андагы бакчага кереп бер фонтан янындагы утыргычка барып утырды. Ләкин хозурланып утырырга насыйп булмады: аның игътибарын бөтенләе белән бакча сукмагы буйлап нәркис чәчәкләре арасыннан фонтанлы хауска[4] таба якынлашып килгән кыз җәлеп итте.

Әлбәттә, Бибарсның үз гомерендә чибәр кызларны күргәне бар, ләкин аларның әле аның күңелендә яшеренеп яткан серле кылларны тибрәтә алганы юк иде. Шундый гүзәл зыялы кызны очрату, җитмәсә, патша сарае бакчасында ук! Мондый хәлгә аның очраганы юк иде әле!

[3] Им – пароль.

[4] Хаус – бассейн.

Кызның куе коңгырт чәчләре иңнәренә салынып төшкән – әле ул аларны үрергә генә җыена иде, күрәсең. Беләгендә арыслан башлы беләзек, ә колакларында сорау билгесен хәтерләткән алтын сыргалар ялтырый. Балалыктан чыгып кына килгән матур йөзендә сөрмәле зур зәңгәр күзләр сызылып киткән каш астыннан сөйкемле итеп карыйлар. Ефәк күлмәк аша кояш нурларына омтылгандай, аның очлы, нәфис күкрәкләре үзләренә игътибар сорый иде кебек...

Кыз яшь вә саф күңелләргә хас беркатлылык белән утыргычның икенче башына килеп утырды. Ул егеткә игътибар белән карап алды. Бибарсның куе җитү җирән чәчләре (күрәсең, аның бабалары арасында ар кабиләләре токымы булмый калмагандыр), ә кыпчак бабаларыннан мирас итеп алынган кыйгач күзләре йөзенә бертөрле үзенчәлек бирә иде.

– Кем син, минем биредә бер дә сине күргәнем юк? – дип сорады кыз аны беренче күрүенә гаҗәпләнеп. Аннары соравы бәйләнү булып яңгырамасын өчен, үзенең исемен әйтте: – Минем исемем Чәчәк, ә мөселман исемем – Зөләйха.

– Ә мин Бибарс, бийм. Гафу ит, бийм, мин хезмәт кешесе, – дип урыныннан торды һәм китәргә җыенды.

– Утыр, бу безнең бакча. Утыргычлар утырыр өчен куелган...

Мондый гүзәл кызның гади бер зат түгеллеген чамалап, Бибарс ничек итеп патша сарае янындагы «безнең бакчадан» чыгып ычкынганын үзе дә сизми калды – капкадан чыктымы ул, әллә коймадан гына сикердеме соң?

Ул урамда гына һушына килде һәм вәзир бүлмәсенә юл тотарга уйлады. Шулай ук вәзир катына керергә кӧтеп торган Хаҗи тархан, аны күреп:

– Баян әфәнде күренмәдеме әле? – дип сорады.

– Белмим шул, үзем дә яңа киләм. Бүлмәсендә булыр, соңлап йөрергә яратмый ул.

Аннары, Хаҗи тарханнан уңайсызлануын яшерергә тырышып:

– Бер соравым бар иде, сорарга яраса, Хаҗи әфәнде? – дип аңа таба карады.

– Тыңлыйм.

– Бу сарай артындагы бакча кемнеке? Анда... ниндидер бер кыз утыра.

Бу сүзләрдән Хаҗи тарханның болай да симез бите елмаюыннан тагын да җәелеп, күзләре мутланып китте:

– Һе, чибәр нәрсәме?

– Мин бары тик белергә генә теләгән идем...

– Ярар, ярар, үпкәләмә. Солтан кызы ул.

Бибарсның башына тәртә белән китереп суккандай булды, ләкин ул үзенең хисләрен сиздермәскә тырышты, дәшмәде. Хаҗи тархан исә күкрәгенә сугып:

– Менә монда ике йөз мең тәңкәгә ышаныч кәгазе ята. Патша кызына яучы җибәрергә җитәрлек бит, ә? Тик яшьрәк. Морзалар унике-унөч яшьлек кызларга өйләнергә яраталар дигән сүзгә ышанма син, ялган сүз ул. Маллы кешегә асрау бала түгел, ә таза беләкле, аның дөньясын алып барырдай, милкен арттырырдай эшлекле хатын кирәк. Ә икенче яктан уйлаганда, эшли торган хатыннар җитәрлек инде, патша кызы патша кызы булыр – уйлап карарга да ярый...

Хаҗи тарханның болай күп сөйләшүенә эче пошкан Бибарс сарай ишеген ачып кереп китте. «Патша серләрен дошманга җиткереп торучы шушы явыз түгел микән?» дип уйлады ул эченнән генә.

Баян бүлмәсенә җиткәч, ул, рөхсәт сорап, эчкә керде һәм исәнләшкәннән соң, күргәннәрен бәйнә-бәйнә остазына сөйләп бирде. Баян, аны игътибар белән тыңлаганнан соң, җентекләп сорашасы итте:

– Ә җиз калайлар таккан диванаНы башка күрмәдеңме?
– Ерактан гына күреп калдым. Кайдадыр булып, сарайдан чыгып бара иде инде.
– Алайса менә нәрсә: әгәр дә ул дивана сарайга иртәгә дә килсә, аннан күзеңне алма: кай җирдә булганын гына түгел, ә сарайдан чыккач та кая киткәнлеген дә хәтерлә һәм күренмичә генә артыннан барып, кайда торганлыгын да ачыкла!
– Бер соравым бар иде.
– Сора.
– Бакчада солтан кызын очраттым, ә соңрак Хаҗи тарханны күрдем: патша кызына өйләнәм, менә калымга акча алып килдем, ди бу. Дөресме?
– Остазыңны ихтирам итмисен, Бибарс. Итсәң, мондый юк-бар сорау бирмәс идең! – диде ул ярым шаяртып. – Хәер, утырып тор, үзең дә күрерсең. Озакламый Хаҗи әфәнде килеп керер...
Ул арада кемдер ишек шакып:
– Мөмкин булырмы? – дип сорады.
– Рәхим итеп, кер!
Ләкин бу Бибарс уйлаган Хаҗи тархан түгел, ә ниндидер башка бер түрә булып чыкты.
– Мине чакырткан икәнсең, Баян бий.
– Әйе. Тик, Рахман әфәнде, мин харита төзеп, юллар тасвирламасы да алып килергә кушкан идем!
Бибарс Рахман бийнең ямчылар рәисе икәнлеген аңлады. Ул сәхиб әл барид вә хәбәр, ягъни ям һәм яңалыклар хуҗасы дип аталып, әмиргә төрле яңалыклар һәм илдәге юллар, кичүләр, күперләр турында төгәл мәгълүмат кирәк булган очракта, аның кул астында әзер харитасы да, тасвирламасы да булырга тиеш иде...
– Ни бит, Баян бий, тасвирлама бар иде. Катиб кәгазьләр арасыннан таба алмады...
Баян, күзләрен кыса төшеп, Рахманга усал итеп карады. Бибарс аның бу карашын белә – ул бик ачуы чыкканда гына шулай карый иде.
– Менә нәрсә, Рахман бий. Дошман безнең кыпчак далаларына кадәр килеп җиткән инде. Ягъни туган илебез Бөек Болгар бусагасына менеп баскан. Ә синең хезмәткәрләрең юллар тасвирламасының да кайда икәнлеген белми. Бүген кичкә Сембер, Самар, Сарытау, Бөрҗан, Машаек, Саксин, гомумән, Идел буен эченә алган юллары тасвирламасын керт. Бигрәк тә күперләр, елга кичүләре, тау-кыялы урыннар җентекләп тасвирланган булсын. Ә бу атна эчендә бөтен дәүләтебезнең юллары тасвирламасы Болгардан көньякка таба – Хазар диңгезенә, көнчыгышка таба – Сибер шәһәренә, көнбатышка таба – Аладимер-Сүздал кенәзлегенә кадәр эшләп куелган булсын. Бу киләсе кан көн[5] була, шулай бит?
Тыныч вакытта хуҗасыз яки үзе генә хуҗа булып яшәргә өйрәнгән Рахман бий, канәгатьсезлеген сиздермәскә тырышып, битараф бер тавыш белән:
– Яхшы, Баян бий, – диде.
– Әгәр дә бу әйтелгән эшләр вакытында эшләнеп кертелмәсә, үзеңә үпкәлә. Хәрби канун – яса кертелгәнен дә, анда үлем җәзасы барлыгын да беләсең. Солтан бу мәсьәләгә бик катгый карый. Чаушлары тиреңне салдырып, салам тутырылган гәүдәңне шәһәр каланчасына элеп куймас, дип ышанам. Бар, эшлә!
Рахманның чыгып китүе булды, ишек артында чират көтеп торган Хаҗи тархан

[5] Кан көн – чәршәмбе.

да килеп керде. Ул Рахман бий белән бер-ике генә сүз булса да сөйләшеп өлгергән иде инде, күрәсең, йөзе борчулы иде. «Патша кызын яуларга килгән кешегә бик охшамаган бу», – дип уйлап куйды Бибарс.

Хаҗи тархан кергәннән сон, беренче мәртәбә аңа күтәрелеп карап, Баян сүз башлады:

– Нәрсә яшерәсең анда күкрәгеңдә?

– Ышаныч кәгазе. Тик, Баян бий, ике йөз мең тәңкә бөтен бер мөлкәт бит ул. Әлбәттә, патшага акча кирәген дә, дошманның Болгар йортына килеп җиткәнлеген дә аңлыйм. Әмма, үтер, бушлай бирә алмыйм!

– Курыкма, Хаҗи бий! Мин сине үтерергә җыенмыйм, – дип җавап бирде Баян. – Узган сөйләшүдә үк хөкүмәткә тиешле акчаны китерергә күндергән идем инде мин сине. Бу юлы тагын да ныграк үтемле сүзем бар. Әйтим: Карачура бий миңа биш йөз мең тәңкәгә ышаныч кәгазе биреп торырга булды. Мин бу дирһәмнәрне патшага биреп, синең бөтен мөлкәтеңне һәм ар ягы салым килерен сатып алам. Патша җәлладлары тырнакларыңны суыртып биш йөз мең дирһәмне миңа көнендә үк кайтарып бирерләр. Ясак җыю кагыйдәләрен һәм кануннарын яхшы беләсең, чөнки Кудама бийдән ар ягыннан салым җыю рөхсәтнамәсен казнага үзең бары ике йөз мең дирһәм биреп сатып алдың. Идел буендагы биләмәләрең генә дә елына якынча йөз мең дирһәмгә кадәр килер бирә, ә Чулман аръягындагы биләмәләрең тагын да зуррак, алары турында әйтеп тә тормыйм!

Хаҗи тархан тынгысызлануыннан кечерәеп үк калгандай булды.

– Тәңредән курык, Баян бий! Нәрсәгә дип миңа бу кадәр канлыкканлыгыңны һич кенә дә аңлый алмыйм...

– Ике йөз мең тәңкәгә ышаныч кәгазен өстәлгә куй! Гаҗәпләнгән булып та кыланырга кирәкми, ярдәм итмәс. Без бу мәсьәләдә кичә үк ачык итеп сөйләштек, килештек. Акча солтанга ашау-эчү оештырыр өчен кирәктер, дип уйладыңмы әллә? Юк! Акча бүгеннән үк гаскәр тупларга, аны коралландырырга һәм Чыңгыз нойоннарына каршы сугыша алырлык итеп өйрәтер өчен кирәк!

Остазның тирән борчулы соңгы сүзләре Бибарска да тәэсир итте. Хаҗи тархан һәм аның патша кызына карата өметләре бөтенләй әһәмиятен югалттылар...Чөнки елга комы кебек күп халыклы Кытайның үзен таптаган дәһшәтле дошманнар һәм каһәрле юлбасарлар иксез-чиксез Кыпчак далаларын да таптап, Болгарны урап алып, хәтта тагын да арырак урнашкан Аладимер кенәзлегенә таба юл тота...

Рөхсәт сорап, Рахман бий килеп керде. Ул, вәзир каршында абруен саклап калыр өчен булса кирәк, яңа гына юлдан килгән бер атчабарны вәзир янына үзе алып кергән икән.

– Баян бий, Саксиннән кирмәнбашы Басманнан, ям саен ат алыштырып, атчабар килгән. Шөкер, ямнарыбыз да әйбәт эшли икән. Тик ул бик хәтәр яңа хәбәрләр дә алып килгән...

Киеменә юл тузаны утырган, үзе берөзлексез ат өстендә чабудан йончыган, таушалган атчабар түшеннән тамгалы-мөһерле хат чыгарып аны вәзиргә тапшырды. Баян хатны җентекләп укырга кереште. Аның йөзе караңгыланды, хәбәрләр күңелле түгел иде, күрәсең. Ул укыган арада Бибарс, аның бушавын көтеп тормыйча, үз йомышы белән китеп барды.

Дәвамы бар ■

«Уйларыбызны әйтүдә бик сак булырга туры килде...»

(Ә.Н.Максудиның тормыш юлы һәм «Йолдыз» газетасы)

Рамил Гарипов[1]

Әхмәтһади (Һади) Максуди 1868 елның 28 сентябрендә Казан губернасы Ташсу авылында (хәзер Татарстан Республикасының Биектау районы) Низаметдин мулла гаиләсендә туган. Башлангыч белемне туган авылында, әтисенең мәдрәсәсендә ала. 1881 елда аңа Казанга барып укырга мөмкинлек туа һәм ул, башлангыч мәдрәсә курсы өчен барлык имтиханнарны экстерн рәвештә тапшырып, «Галләмия» мәдрәсәсенең игдадия бүлегенә, ягъни төп курсына укырга керә. Бу адымы аның аңгыйлем ягыннан шактый яхшы әзерлекле булуы турында сөйли.

Әхмәтһади тырыш һәм кызыксынучан шәкерт булып чыга. Укуы тәмамлангач, «Галләмия» мәдрәсәсе җитәкчелеге аңа укытучы вазифасын тәкъдим итә. Әхмәтһади кече сыйныфларны укырга һәм язарга өйрәтә башлый. 1892 елда «Тәрҗеман» газетасы аркылы яңа фонетик ысул һәм И.Гаспралының «Хуҗаи сыбьян» («Сабыйларның укытучысы») дәреслеге белән танышып, башлангыч сыйныфлар өчен татар әлифбасы дәреслеген, соңрак Босфордан алып Шәркый Төркестанга кадәр булган барча төрки халыкларның уку әсбабына әверелеп киткән «Мөгаллим әүвәл» («Беренче мөгаллим») китабын әзерли. Бу дәреслекнең үзенчәлеге шунда ки, анда элеккеге әлифбалардагы кебек иҗек ысулы түгел, ә фонетик ысул кулланылган. 1918 елга кадәр «Мөгаллим әүвәл» 30 мәртәбә (ә бәлки аннан да күбрәктер) нәшер ителә, аның гомуми тиражы 1 200 000гә кадәр җитә.

Әхмәтһади Максудида шәкертлек чорында ук туган телендә газета чыгару идеясе туа. 1892 елда Матбугат эшләре буенча баш идарәгә үз акчасына Казанда татарча газета чыгарырга рөхсәт итүләрен сорап гариза яза, ләкин аңа бу

[1] Гарипов Рамил Марат улы – Актанышның «Сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернат» директоры, ТР ФАнең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты аспиранты.



«Мөгаллим әүвәл»



«Мөгаллим сани», 1917 ел

изге ниятне гамәлгә ашырырга рөхсәт итмиләр. 1893 елда Максуди, мәдәният һәм мәгариф өлкәсендәге иң соңгы яңалыклар белән танышу өчен, Госманлы дәүләтенә китә. Сәяхәт вакытында бу илдәге матбага эше белән таныша һәм газета-китап нәшер итүнең серенә төшенә. Монда ул «Икъдам» газетасы мөхәррире, атаклы галим, тарихчы һәм мәгърифәтче Әхмәд Мидхәт белән дә очраша.

Кайтыр юлында Ә.Максуди Кырымда туктала һәм анда үзен күптәннән Бакчасарайга, «Зынҗырлы» мәдрәсәсенә кунакка чакырган «төрки милләтнең атасы» Исмәгыйль бәк Гаспралы белән очраша. Чынлыкта И.Гаспралының да, Ә.Максудиның да сөйләшер сүзләре шактый күп була. Алар икесе дә алдынгы карашлы укытучы, икесе дә мөселманнарның хәлен яхшыртырга тели һәм китапчылык эше белән кызыксына, күп кенә мәсьәләләр буенча уй-фикерләре дә уртак. И.Гаспралы татарларга туган телдә белем бирүне хуплый, Россия империясендә «инородецлар» өчен кабул ителгән мәгариф системасын тәнкыйтьли, аны мәгънәсез дип саный. Бакчасарайда Ә.Максуди яңа уку ысулын яхшырак өйрәнә, мәгариф өлкәсендәге иң яңа идеяләр белән таныша, газетаны ничек чыгарырга икәнлеген күреп белә һәм эшне башлап җибәрү турында кыйммәтле киңәшләр ала.

И.Гаспралы Ә.Максудига «Тәрҗеман» газетасында эшләргә һәм «Зынҗырлы» мәдрәсәсендә укытырга да тәкъдим итә. Әхмәтһади исә моңа бик теләп ризалаша, чөнки, беренчедән, күптән башында йөргән хыялын чынга ашырыр өчен яхшы мөмкинлек туа, икенчедән, матбугат эше буенча зур тәҗрибә туплый. Бертуган энесе Садрины да үз янына, «Зынҗырлы» мәдрәсәсенә укырга чакыра.

1896 елда Казанга кайткач та Әхмәтһади остазы И.Гаспралы белән элемтәсен өзми, алар даими хат алыша. Шул ук елда экстерн рәвештә Казан татар укытучылар мәктәбенә имтиханнар тапшыра. Укытучы шәһадәтнамәсен алгач, Апанай мәдрәсәсендә мөгаллим була, бер үк вакытта мөселман балалары приютында да, бертуган хәйрияче Юнысовлар

үтенече буенча, укытучы булып эшли. Әхмәтһади Максуди Казан каласында гына түгел, ә бөтен төрки дөньяда мәшһүр шәхескә әверелә. Аны җирле түрәләр дә, жандармерия дә яхшы белә. Соңгылары исә Әхмәтһадины Идел буе төбәгендә панисламизм һәм пантюркизмның[2] төп тарафдары итеп күрә.

Ә.Максуди 1898 елда Сарытаудагы постау фабриканты кызы, сәнәгатьче Исхак Йосыф улы Апанаевның оныгы Зәйнәпбану Сөләйман кызы Мишкинага өйләнә. Аларның биш баласы туа: Фатыйма-Галия (1898-1991), Һарун (1899-1981), Шәфыйка (1903-1981), Һашим (1905-1988) һәм Бәхрәмия (1920).

***

1903 елның башында Әхмәтһади Максуди, мәгърифәтче Ибраһим Терегулов белән бергәләп, хакимияттән рус һәм татар телләрендә «Йолдыз» газетасын нәшер итәргә рөхсәт сорый. Ләкин түрәләр, милли газета *«рус телен өйрәнүгә ихтыяҗны озак вакытка бетерәчәк һәм, һәрхәлдә, татарларның рус халкы белән мәдәни кушылуына булышасы урынга, милли сепаратизмны гына көчәйтәчәк»*, дигән сылтау белән, үтенечне кире кага[3].

Аннан соң Ә.Максуди, Эчке эшләр министры П.А.Столыпин исеменә гариза язып, хөкүмәткә файдалы булырдай татар газетасын чыгарырга рөхсәт бирүләрен сорый. Хатында татар телендә газета нәшер итүнең гамәли яктан кирәк булуын аңлата. Татар халкының «наданлыгы һәм эчкерсезлеге аркасында һәрбер басма сүзнең дөреслегенә ихластан ышануына» игътибарны юнәлтеп, татарлар арасында «төрек мәнфәгатьләрен яклый торган» Госманлы дәүләте газеталарының киң таралган булуын әйтә, эшче сыйныф арасында хөкүмәткә каршы фирканең булуына, теләсә нинди инкыйлаби идеялардән читтә торган халкыбызның наданлыгы һәм басма сүзгә сукырларча ышануы белән уйнап, татар телендә идән астында бастырылган җинаятьчел кәгазьләр таратылуы хакында искәртә. Үзенең гаризасында Ә.Максуди П.Столыпинга: *«Россиядә башка инородецлар телендә, мисалга, кырым татарларының да, Кавказ арты азәрбайҗаннарының да, Төркестан сартларының да һәм хәтта дала кыргызларының да сөйләшендә күп газеталар чыгарыла. Бары без, казан татарлары гына бу мәрхәмәттән мәхрүм...»*, – дип яза[4].

Гозере янәдән кире кагылгач, Ә.Максуди белән И.Терегулов, Россиянең иң югары хакиме – патшага: *«Хөкүмәтнең яхшы күңелле омтылышларын аңлаешлырак итеп аңлатачак, Ватаннары Россиянең бөеклеге һәм кодрәте белән таныштырачак, татарлар белән русларның туганнарча якынаюына китерәчәк һәм, гомумән, аларны хәзерге акыл торгынлыгыннан чыгарачак»*[5], – дип, туган телдә газета чыгарырга рөхсәт бирүен сорап гарезнамә яза, ләкин бу ният тә барып чыкмый.

Күрәсең, түрәләр нашир итеп *«татарларны рус халкына якынайту идеясе белән янган, татар халкын руслаштыру юнәлешендә агарту максатын куйган»* кешене тәгаенләргә теләгәндер, ә Ә.Максуди исә бу идеягә туры килмәгән. Алар фикеренчә, Максуди *«үзенең газетасында төньяк-көнчыгыш Россия татарлары арасында әлегә төгәл ачыкланмаган һәм аңлы рәвештә таралмаган, Россиянең мәдәни бурычлары өчен зыянлы булган панисламизм идеясен таратачак»*. Алай гына да түгел, аның *«хөкүмәткә каршы хәрәкәттә катнашуда»* гаеплиләр һәм *«Казан шәһәрендә шактый күләмдә таратыла торган татар телендәге прокламацияләрне бастыру эшенә»* кагылышлы булуын әйтәләр[6].

Патша түрәләре фикеренчә, иң

---

[2] ТР ҮДА. 1ф., 4 тасв., 1622 эш, 10 б.

[3] Амирханов Р.У. Татарский народ и Татарстан в начале XX века: Исторические зарисовки. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2005. – С.115.

[4] ТР ДКК. 4 ф., 1 тас., 40 т., 293-294 б.

[5] ТР ДКК. 4 ф., 1 тас., 40 т., 292 б.



«Гыйбадәте Исламия. Намаз», 1904 ел



«Рузә, зәкят вә хаҗ», 1913 ел

куркынычы шунда: *«Газета, эчтәлеге белән хөкүмәткә бернәрсә белән каршы килмәсә дә, ирексездән, милли узаңны, хәтта сәяси хыялларны уята алган»*[7]. Бу мәсьәлә буенча Казан губернаторының язган сүзләре дә күп нәрсә сөйли: *«Рус хөкүмәте Россиядә татар һәм мөселман мәдәниятенең юклыгын, була да алмавын ачык итеп әйтергә тиеш»*[8].

Россиянең күп кенә халыклары, шул исәптән, татар тормышына да тирән үзгәреш алып килгән 1905 елгы Беренче рус инкыйлабы җитә. Үзгәрешләр иҗтимагый, сәяси һәм мәдәни тормышның барлык өлкәләрендә чагылыш таба: матбагачылык эше, сәхнә сәнгате, мәгарифтә яңарыш башлана. Бу елның иң төп казанышы – татар вакытлы матбугаты барлыкка килү. Ел ахырында дүрт татар басмасы чыга, ә бу исә, чыннан да, җитди нәтиҗә. Укый-яза белү дәрәҗәсе шактый югары булган халыкның милли матбугатка ихтыяҗы һаман да зур була. 1906 елда 16 яңа басма, шул исәптән, 15 гыйнварда Ә.Максуди мөхәррирлегендәге «Йолдыз» газетасының да беренче саны дөнья күрә.

Ә.Максудиның «Йолдыз» газетасы нашире һәм баш мөхәррире вазифасында уздырган еллары (1906-1918) иң нәтиҗәле чор булып санала. Галимнең барлык дәреслекләре дә диярлек шушы вакытта дөнья күрә, аларның басылып чыгуы турында автор «Йолдыз» газетасы битләрендә даими рәвештә хәбәр итеп тә барган. Ә.Максуди, нашир дә, җаваплы мөхәррир дә булганга, һәр мәкаләне шәхсән үзе тикшергән. Дөньяның төрле өлкәләре буенча аның гыйлеме искиткеч зур була, ләкин күбрәк үзе педагогика, дин һәм фәлсәфә фәннәренә илтифат күрсәтә.

«Йолдыз» газетасы битләрендә мәгариф, мәктәп-мәдрәсә реформасы, татар язуы, сәяси проблемалар һәм төп яңалыклар буенча кызу бәхәс барган. Дәүләтнең сүз һәм матбугат ирекен тулысынча бирергә теләмәвен һәм мөмкинлек туган саен, гаебе табылган басмаларның эшен чикләргә омтылуын

[6] ТР ҮДА. 1ф., 4 тас., 1622 эш, 10-11 б.
[7] ТР МА. 1ф., 4 тас., 107 эш, 4 б.
[8] РДТАА. 821ф., 133 тас., 472 эш, 125 б.

онытырга ярамый. Максуди газетада басылачак мәгълүматны тәкъдим итү ысулына һәрвакыт сак караган. Патша цензурасының бу газетаны япмавы да моны исбатлый торган бер факт. Мөхәррир сәяси мәсьәләрне яктыртканда гына түгел, ә дини сораулар буенча да, аеруча, кадимиләр белән җәдидиләрнең каршылыгына карата да игътибарлы һәм сак мөнәсәбәттә булган. Бу мәсьәлә буенча ул беркайчан да теге яки бу фикер тарафдары булмый, нибары: *«Без барыбыз да мөселман һәм барыбыз да татар җәмгыяте үсешенә булышырга телибез»*, дигән сылтама белән, халыкны *«фикер алышу өстәле»* артына утыртырга гына тырыша. Аның фикеренчә, милли яңарыш, милләтне саклау һәм үстерүдә төп фактор ислам дине булырга тиеш[9].

1916 елның 15 гыйнварында газета чыга башлауның ун еллык юбилее уңаеннан мөхәррир болай дип яза: *«Бу 10 ел эчендә безнең дәүләттә 100 ел дәвамында да булмый торган үзгәрешләр булды. Бу вакыт эчендә безнең дәүләтебездә бик күп фикер һәм карашлар үзгәрде. Хәзер инде кайчандыр модада булган сул хәрәкәткә игътибар юк, күпләр аннан арыды инде. Ләкин туган халкына хезмәт итүдән «Йолдыз» беркайчан да арымаячак һәм халык фикерен үстерүне дәвам итәчәк. Кайчагында безгә бик буталчык сәясәт алып барырга һәм үз фикерләребезне, сугышка карата уйларыбызны әйтүдә бик сак булырга һәм сакланып калырга туры килде»*[10].

Чыннан да, дәүләт өчен шундый буталчык чорда «Йолдыз» бик уңышлы гына чыгып килә алган, 12 ел эчендә аның бер саны да патша охранкасы рецензентлары һәм башка күзәтү органнары тарафыннан конфискацияләнмәгән. Бу факт Ә.Максудиның бик яхшы мөхәррир генә түгел, шәп «сәясәтче» дә булуы хакында сөйли.

Ә.Максуди дини темага караган китаплар, дәреслекләр дә нәшер иткән. Заманында башлангыч һәм урта сыйныф шәкертләре өчен язылган әлеге басмалар хәзерге көндә дә Россия һәм Урта Азия илләрендә яшәүче мөселманнарның өстәл китабы. Алар теленең җиңеллеге, материалның гади итеп бирелүе аркасында уңайлы китаплардан саналган, шунлыктан күпләп басылган һәм бик тиз арада сатылып та беткән. «Гыйбадәте Исламия» (ул «Гакаид», «Тәһарәт», «Намаз», «Җәмагать», «Рузә, зәкят вә хаҗ» дигән биш өлештән тора), «Һилял», «Әхкәмү шәргыя» (ислам кануннары: фарыз, ваҗиб, сөннәт, хәләл, мөхтәсәб һәм хәрам гамәлләр турында), «Хокуки исламия» һ.б. дәреслекләрен аерып күрсәтергә мөмкин. «Мөгаллим Сәни» исемле гарәп теле һәм исламның төп кануннары дәреслеге бүген дә дөньяның күп почмакларында нәшер ителә, имамнарның, мөгаллимнәрнең, гади мөселманнарның «Әлифба»сы булып тора. Ә.Максуди үзе имам булмаса да, аңа Диния нәзарәте указы белән имам һәм мөдәррис дәрәҗәсе бирелә.

1917-1918 елларда Әхмәтһади Максуди энесе Садри Максуди җитәкләгән Милли Идарәнең – Эчке Россия һәм Себер мөселманнары милли-мәдәни мохтариятенең барлыкка килүендә һәм эшли башлавында актив катнаша, аның мәгариф идарәсе җитәкчесе итеп сайлана. Милли Идарә таратылып, аның әгъзалары куылгач, Әхмәтһади Максуди, Садридан аермалы буларак, Россиядә кала.

Әдәбият:

1. Гаффарова Ф.Ю. «Йолдыз» кабызган Максуди. – Казан: Алма-Лит, 2006. – 186 б.
2. Забиров Г.Г. Максуд баба һәм Максудилар. – Казань, 2000.
3. Рәхимов С. «Я был ближе всех связан с Гаспринским» // Гасырлар авазы. – 1995. – №1. ■

[9] Йолдыз. – 1906. – №7.
[10] Йолдыз. – 1916. – №1591.

1916 елда татар халкы башкалабыз Казанда «Йолдыз» газетасының чыга башлавына ун ел тулуны күркәм бәйрәм итеп билгеләп үтә, Әхмәтһади Максуди үз йортында, милли зыялыларны, галим-голәмәне, цензура комитеты әгъзаларын (М.Н.Пинегин, Н.И.Ашмарин, гарәп Җүзи җәнаплары) җыеп, татар, гарәп һәм рус телләрендә зур мәҗлес үткәрә. Шул уңайдан газетаның гыйнвар ае саннарында да саллы мәкаләләр, котлаулар басыла. Аларның берничәсен сезнең хозурга да тәкъдим итәргә булдык (№1591. – 15 гыйнвар). *Шуларның берсе – Ә.Максуди язган «Йолдыз»ның тарихы» исемле истәлек-мәкалә. Биредә «Йолдыз»ның барлыкка килүе, аның беренче тәҗрибәләре Казан артындагы кечкенә генә Ташсу авылында башлануы турындагы мәгълүмат аеруча кызыклы.*
Мөгаен күпләр Максудилардан Һади һәм Садретдиннарны гына беләдер, ә аларның бертуганы Сәлахетдин (1869-1949) (Мәсфуфә һәм Мәншүрә исемле кыз туганнары да була) күпләр өчен мәгълүм түгел. Алда тәкъдим ителгән котлау хатыннан без аның аң-гыйлемле, укуга һәвәс һәм сәүдә эшен кәсеп итеп алып, милләтенә хезмәт иткәнен, ата-анасын тәрбияләгәнен аңлыйбыз.

«ЙОЛДЫЗ»НЫҢ ТАРИХЫ

Әхмәтһади Максуди

1881 нче сәнәгә *(елга)* кадәр минем тәхсилем *(гыйлем алуым)* өйдә, Казаннан 33 чакрым мәсафәдә *(ераклыкта)* Ташсу карьясендә, мәрхүм пәдәрем *(атам)* мелла Низаметдин Максуди хозурында булды. Мин пәдәремдә сарыф *(морфология)* вә нәхү *(синтаксис)* китапларын иске тәртиптә фарсыча укыдым. «Әнмузәҗ» вә «Кафия» мәтеннәрен *(текстларын)* күңелдән хифыз кылган *(ятлаган)* идем. Пәдәремнең тәшвикы *(кушуы)* буенча мин гарәби һәр сүзнең сыйгасын *(форма, төрләнешен)* белергә вә асылын табарга вә һәрбер гарәби җөмләнең тәркибен *(тезмәсен, составын)* хәл кыйлырга *(таркатырга)* тырыша идем.

Пәдәрем Казанда хаҗилар аркылы килгән төрки иске гәзитәләр алып кайтып укый иде. Берничә фарсы вә госмани әхлак китапларын дәрес итеп укыганлыгымнан, бу гәзитәләрне укып, бер дәрәҗә аңлый идем. Ул гәзитәләрдә күбрәк 1878 нче сәнәгә кадәр булган рус-төрек сугышының тәфсыйлат вә нәтаиҗе *(нәтиҗәсе)* язылган була иде. Бер сәнәдә Плевна мөхасарәсенең *(камалышының)* тәфсыйлатын укыганлыгым әле дә хәтеремдә. Бу гәзитәдә мәзкүр *(әлеге)* мөхасарә вакытында һәр ике тарафтан никадәр гаскәр һәлак булганлыгы язылган иде.

Гәзитәләрнең вәкаигъ *(вакыйга)* языла торган әүрактан *(кәгазьдән)* гыйбарәт икәнлеген мин шул гәзитәләрдән аңлаган булмак кирәк, шуларга тәкълидән *(ияреп)* мин авылымызда булып кичкән, үземчә мөһим күренгән зур вакыйгаларны бер табаклы кәгазьгә фасыл-фасыл *(бүлек)* итеп яза башладым. Табаклы кәгазьләрнең башларына зур итеп төрле исемнәр язып, гәзитәгә охшата идем дә, урталарына төрле гонваннар *(исемнәр)* белә авылымызда булган хәлләрне яза идем. Бу әүракка авылымызда булып кичкән туй вакыйгалары, Сабан туе илә җыен хәлләре языла иде. Ханәмездә булган голәмә вә әкъриба *(кардәшләр)* мәҗлесләре вә анда булган мөзакәрә *(фикер алышу)* вә моназарәләр *(бәхәсләшү)* мөндәриҗ *(теркәлгән)* була иде. Авыл

Ленар Гобәйдуллин фотолары

Бертуган Әхмәтһади һәм Садри Максудилар туган Ташсу авылы. Биектау районы

Ташсу авылындагы элекке мәчет бинасы. 2013 ел

Инеш һәм чишмә

Максудилар туган нигез шушы тыкрыкның сул ягында булган

Ташсу авылындагы мәктәп бинасы

Сабан туйларында вә җыеннарында һәр авылда үзенә күрә бик күп вакыйгалар була: сугыш кычкырышлары да була, Сабан туенда чабучылар аттан да егылалар, көрәшчеләр дә гяһан *(кайчакта)* имгәнәләр, җыеннарда исә авыллар бигрәк шау итәләр. Кечкенә Ташсу авылының әхвәл вә вәкаигы бер-ике табак кәгазьне тутырырга йитә иделәр.

Мәзкүр әуракымә мин төрле исемнәр кушып караганым хәтеремдә. Мин аларга тәүсыйфлы-изафәле гарәп вә фарсы исемнәре дә кушып карадым, ләкин иң соңгы вә үземә муафыйк күренгән исем татарча «Йолдыз» булган иде. «Йолдыз» исеме белә ничә табак кәгазь язып караганымны белмим. Мондый язулар белән шөгыльләнүемне минем мәрхүм пәдәрем һич яратмый иде. Укуыңа зарар килер, дип юк-бар язудан һаман мәнгы кыйла *(тыя)* иде.

Бу эштән шәдидлә *(кырыслык белән)* мәнгы кыйлынуыма «юшкын» вә «кушуч» дигән сүзләр сәбәп булдылар. Бер чәй мәҗлесендә берсе ни өчен юшкынга «юшкын» дип вә кушучка «кушуч» дип әйтәләр икән, дигән иде. Ул вакытта гарәби сарыф вә нәхү укып, кәлимәләрнең *(сүзләрнең)* бер асылы барлыгыннан хәбәрдар булу сәбәпле, мин бөйлә *(болай)* җавап биргән идем: «Юшкын – юеш ком, кушуч – куш уч, дигән сүз булса кирәк», – дигән идем. Ни өчендер пәдәрем минем җавабымны бер дә яратмады: «Андый сүзләрне тикшерергә куелган бер Каюм Насыйри бар инде, син алар белән маташма, «Кафия»ңне яхшы бел. Авылның юк-бар хәбәрләрен язып та маташма, үзеңә бирелгән сабакны укы!» – диде. Шуннан соң минем гәзитәм рәсмияттән чыгып, яшерен кәгазьләр җөмләсеннән санала башлады.

1881 нче сәнәдә мин Казанга мәдрәсәгә килдем. Анда килгәч, минем зиһенемне нәхү бәхәсләре, мантыйк моназарәләре мәшгуль иттеләр. Имди мин табаклы кәгазьләремне бөгеп тегеп, аларга хәбәрләр урынына бетмәс-төкәнмәс бәхәсләр яза башладым, авыл хәбәрләре, төрки сүзләрнең асыллары онытылдылар. «Әлхәмде» кеби сүзгә меңәр мәгънә бирүләр, исбат-важиб бәхәсләре минем дикъкатемне бик каты җәлеп кылдылар. Авыл хәбәрләре язу инде минем үземә дә бик вак эш булып калды.

1883 нче сәнәнең апрелендә «Тәрҗеман» гәзитәсе чыга башлады. Бу гәзитә Казанга берничә чәйханәгә вә әкъребамнан *(кардәшем)* Мифтахетдин Иманколов җәнапларына килә иде. Бу гәзитәнең хәбәрләре минем дикъкатемне янә икенче якка чәүерделәр. Сәяси хәбәрләр мантыйк бәхәсләреннән дә ләззәтле тоела башладылар. Шул көннән башлап, мин һәр һәфтә *(атна)* бер йирдән «Тәрҗеман»ны укый башладым. Бу хәл дүрт-биш ел дәвам итте, соңгы елларда мин «Тәрҗеман»ны мәдрәсәгә үз исемемә ала башладым. «Тәрҗеман» сәхибе *(иясе)* мәрхүм Исмәгыйль бәк Гаспринский шул елларда ике-өч мәртәбә Мәкәрҗәгә килеп китте. Һәр сәфәрендә мин аны күреп, сөйләшергә муаффәкъ булдым *(ирештем)*. Берничә еллар «Тәрҗеман»га мөхбирлек тә кыйлдым. Ләкин Казанда гәзитәгә язарлык һичбер хәбәр булмый иде. Шөйлә исә дә, мәүлүд *(мәүлид)* кыйссасын укыту хакында чыккан низаг илә мәдрәсәи «Мәрҗания» мөдәррисләренең гаугаларын берничә мәртәбә яздым.

1890 нчы сәнәдә мин мәдрәсә тәхсилен *(укуын)* тәмам итеп, мөкәррирлек *(өйрәтүче, репетиторлык)* вә мөгаллимлек кыйла башлаган идем, шулвакытта Казанда үз шивәмездә бер гәзитә булмавына минем бик әчем поша иде. Каюм Насыйри вә Габдерәхман Ильясов Казан телендә бер гәзитә чыгарырга рөхсәт сорап бакканнар, ләкин дарелфөнүндә *(университетта)* укымаганлыкларыннан, аларга рөхсәт бирелмәгән, дигән хәбәр халык арасында шаигъ итте *(таралды)*. Ул вакытта Казанда дарелфөнүн тәхсилен күргән кеше фәкать мәрхүм Шаһбәзгәрәй Әхмәров

җәнаплары иде. Халык сөйләвенә караганда, Казанда татарча бер гәзитә чыкса, фәкать ошбу мирза исеменнән генә чыгарылу мөмкин иде.

Казанда үз телемездә бер гәзитә чыгуын арзу кыйлганлыкымнан *(теләгәнлегемнән)*, мин Шаһбәзгәрәй әфәнде Әхмәров белә танышып, киңәшүне лязим *(тиеш)* таптым. 1892 нче сәнәдә бер көн аның мәхәл икамәтенә *(учительская школага. –* **Авт. иск.***)* барып, мирза әфәнде белә күрештем. Шул беренче мәҗлестә мин аңа Казан өчен бер гәзитә лязим икәнлеген дәлилләре илә бәян кыйлып, аннан шул гәзитәне чыгаруын үтендем. Ул миңа бөйлә җавап бирде: «Миндә бу фикер күптән бар. Ләкин гәзитә чыгару өчен татарча яхшы яза белүчеләр кирәк. Мин үземне дә яхшы яза алырмын дип белмим, яза алсам да, гәзитә өчен бер кеше кяфи *(җитәрлек)* булмаячак», – диде. Шуннан соң мин аңа, мәдрәсә тәхсилен тәмам иткәнлегемнннән, башка мәшгулиятем булмаганлыгын, гәзитә чыга калса, даими язучы булачагын гарыз кыйлдым *(белдердем)*, төрки вә гарәби гәзитәләрдән татарчага тәрҗемә кыйлырга икътидарымны аңлаттым. Ул вакытта мин Мисырдан «Ән-нил» вә «Әл-мүәид» гәзитәләренең мөштәриләреннән *(абунәчесе)* идем. Мәрхүм бер дустым Гариф Мусин илә «Тәрҗеман хакыйкать» гәзитәсен ала идек. Әхмәров җәнапларына мин ошбу гәзитәләрне күрсәттем. Һәммәсен укып аңлаганымны аңлаттым. Шул елда басылып чыккан беренче әсәрем булган «Мөгаллим әүвәл»не дә тәкъдим кыйлдым. «Мөгаллим әүвәл»не укып карагач, мирза әфәнде минем татарча яза беләчәгемә канәгать хасыйл итте.

Минем бу киңәшем Әхмәров җәнапларына яхшы тәэсир итте. Шул мәҗлестә үк русчадан тәрҗемә өчен мелла Фәсыйх әфәнде Мөхетдинов илә Шакир Таһири җәнапларын күздә тотып, бу эшкә керешәчәк булды. Бу мәҗлестә булачак гәзитәнең «Казан» исемле булуы мөнасиб *(яраклы)* күрелде. Шуннан соңра ул ике мәртәбә Петроградка матбугат нәзарәтенә гариза бирде, ләкин һәр мәртәбәсендә аңа мөсагадә *(мөмкинлек бирү)* урынына рәд *(кире кагу)* җавабы килде.

1894 нче сәнәдә мәрхүм Исмәгыйль бәк Гаспринский җәнаплары илә Зынҗырлы мәдрәсә мөдәррисе хаҗи Хәбибулла әфәнденең дәгъватлары буенча, мин Кырымга, Бакчасарай шәһәренә киттем. Казанда вакытымда да Петроград ахунды Гатаулла хәзрәт Баязитов белә мөрасәләм *(хат язышу)* бар иде, Кырымда вакытымда да бу мөрасәлә дәвам итте. Мәрхүм илә мәктүпләребездә *(хатларыбызда)* татарча гәзитә мәсьәләләрен һаман киңәшә идек, мәрхүм мине чыгачак гәзитәгә язышып булышлык итү өчен Петроградка дәгъват кыйла иде. Мин, гәзитә чыгарырга рөхсәт бирелү илә, Петроградка күчүне вәгъдә кыйла идем.

Әхмәров җәнаплары, мин Кырымга киткәннән соңра, өченче гаризасын биреп караса да, һаман рөхсәт ала алмаганлыгы соңгыннан мәгълүм булды.

Ике сәнә Кырымда булган заманымда «Тәрҗеман» идарәсендә һаман булына идем. Исмәгыйль бәк Мисыр вә Бәйрут гәзитәләрен тәрҗемә кыйлырга миңа бирә иде, ләкин «Тәрҗеман»ның кечкенәлеге сәбәпле, минем бу тәрҗемәләремнең һәммәсе керми иделәр. Исмәгыйль бәк аның иҗмален *(кыскачасын)* гына дәрҗ кыйла *(бастыра)* иде. Соңра, мин бу гәзитәләрне укып, иҗмалләрен вә мөһим хәбәрләрен Исмәгыйль бәккә тел белән генә сөйли башладым. Исмәгыйль бәк, бу мөһимнәрнең дә мөһимрәкләрен сайлап, үз гыйбарәсе белә дәрҗ кыйла иде. «Тәрҗеман»га «Ән-нил», «Әл-мүәид», «Сәмрател-фөнүн» гәзитәсеннән күчерелгән хәбәрләргә 1894, 1895 сәнәләрдә мин васита *(сәбәп)* булдым.

1896 нчы сәнәдә Кырымнан кайтып, Казанга тәвәттын иткәч *(төпләнгәч)*, мин ысул җәдидә мәктәпләре өчен китаплар язу белә мәшгуль булдым.

Ул заман Казанның ысул җәдидәгә каршы тору заманы иде. Галимҗан хәзрәт Баруди, Шакирҗан Таһири вә мәрхүм Әхмәт бай Хөсәенов ысул җәдидәне нәшер вә тәгъмим кыйлырга *(таратырга)* бик тырыша иделәр.

1891 нче вә 1892 нче сәнәләрдә Галләм хәзрәт мәдрәсәсендә мин үземнең «Мөгаллим әүвәл»ем белә ысул җәдидә буенча ике ел укыткан булсам да, Кырымга киткәч рөшди *(урта)* сыйныфлар өчен гарәби сарыф вә гарәби нәхү һәм шифаһияләр* язу белә мәшгуль булган идем. Казанга кайткач, мин янә ибтидаи *(башлангычта)* мөгаллим булып, ибтидаи китаплар язу белән һәм ысул җәдидә хакында мөҗадәлә кыйлу *(сүз көрәштерү)* илә мәшгуль булдым. Берничә сәнәләр гәзитә чыгару мәсьәләсе кичектерелде. Ул арада гәзитәгә мөхәррир булырлык мирзамыз 1900 нчы сәнәдә мәрхүм дә булып китте.

١٦ نجی نومر. ١٣٢٤ سنه. ٤ ربیع الاول. شنبه. ١٩٠٦ سنه. ١٥ اپریل. ١ نجی بیت

ЕЖЕНЕДѢЛЬНАЯ ГАЗЕТА „ЮЛДУЗЪ"
Цѣна 3 руб. на годъ.
Адресъ Редакцiи: Казань, Екатерининская ул.

هر اتناده بروگاها ایکی مرتبه چغاچق ادبی، فنی، معاشی وسیاسی جریدهٔ ترکیه‌در.

١٥ آپریل، شهر قزان.

«Йолдыз»ның 1906 елгы бер саны

Имди мин чыгачак гәзитәгә үзем мөхәррир булуга керештем, хосуси сурәттә *(үзлегемнән)* фәннәр укып игъдади дәрәҗәсендә имтихан бирү өчен әзерләнә башладым. Фөнүн җәдидә *(җәдиди фәннәр)* мине янә үзенә тартты. Мин имди үземә лөзүми *(кирәк)* булса, булмаса һәр фәннең иҗмален *(конспектын)* тәхсил *(укырга)* итәргә тотындым. Бу һәвәс гәзитә мәсьәләсен янә дүрт-биш ел кичектерде.

Шөйлә исә дә, гәзитә чыгару фикере минем башымнан һич китмәде. 1903 нче сәнә язында мин мөхәррирлеккә Ибраһим мирза Терегулов җәнапларын күрсәтеп, матбугат нәзарәтенә «Йолдыз» исемле гәзитә чыгарырга сорап, беренче гаризамны юлладым. Бу гаризадан соң, Казанда татарча гәзитә чыгаруның идарәи дәүләтчә файдалы булып-булмаячагы хакында Петроградтан Казан мәэмүрләренә *(түрәләренә)* мөрәҗәгатьләр булган. Ибраһим мирза Терегулов илә минем хакта тәфтишләр *(тикшерүләр)* кыйлынган. Ләкин ни сәбәптәндер, матбугат нәзарәте шул сәнә 5 нче августта миңа 7535 рәкымле *(номерлы)* рәд *(тискәре)* җавабы йибәрде: «Дахилия вәзире *(Эчке эшләр министры)* бу эшне муафыйк тапмады», – дип җавап бирде. Август ахырында мин Петроградка барып, Дахилия вәзиренең үзенә гариза бирдем. Моңа да матбугат нәзарәте аркылы 23 октябрьдә 10016 рәкымле рәд җавабы килде.

1904 нче сәнә эчендә ике мәртәбә

* «Шифаһия» – гарәп телен өйрәнү дәреслеге.

падишаһ хәзрәтләре исеменә гариза бирдем. Бу гаризаларыма каршы да матлуб булмаган *(таләп ителмәгән)* җаваплар килде. 1905 нче сәнәдә «Йолдыз» дигән исемнең үзендә бер шөбһә юк микән, дип, матбугат идарәсенә «Казан» исемендә бер гәзитә чыгарырга рөхсәт сорап гариза бирдем, моңа каршы 14 апрельдә язылган 4406 рәкымле рәд җавабы алдым. Гәзитәгә рөхсәт бирмәсәләр дә, бәлки журналга бирерләр, дип гөман кыйлып, шул сәнә җәендә «Йолдыз» исемле һәфтәлек *(атналык)* журнал сорап гариза бирдем. Моңа да матбугат нәзарәте 3 үктәбердә язылган 10865 рәкымле рәд җавабын бирде.

1905 нче сәнә ахырында, матбугат хакында яңа низам *(канун)* чыгу сәбәпле, гәзитә нәшеренә губернатордан рөхсәт алу мөмкин кыйлынды. Шуннан соңра мин тизлек белә Казан губернаторына «Йолдыз» исемле гәзитә чыгарырга рөхсәт сорап гариза бирдем. Бу гаризама каршы губернатор Рейнбот 1905 нче сәнәнең ахырында рөхсәт биреп, шәһадәтнамәгә имза кыйлган булса да, бу шәһадәтнамә минем кулга 1906 нчы сәнә ибтидасында *(башында)* гына тапшырылды. Ошбу шәһадәтнамә буенча «Йолдыз» гәзитәсенең беренче номеры 1906 нчы сәнәнең 15 нче гыйнварында чыкты.

Шуңа бинаән, буген «Йолдыз»ның чыга башлавына ун ел тулып, унберенчегә китәдер. Бу унъеллык мөддәттә *(вакытта)* «Йолдыз»ның нинди муаффәкыять *(уңыш)* белә дәвам иткәнлеге укучыларга мәгълүмдер. Ул хосуста хаким алардыр. Фәкать шулкадәресен язарга лязим *(кирәк)*: «Йолдыз» бу мөддәт дәвамында үзенә Русия мөселманнары эчендә йиде-сигез мең укучы тапты вә үзенең истикъбале *(киләчәге)* өчен кяфи *(кирәкле)* микъдарда мая әзерләде. Ун ел эчендә изһар кыйлган *(мәйданга чыгарган)* мәсләген үзгәртмичә, иләә мәшә Аллаһ, «Йолдыз» дәвам итәчәктер.

Сәлахетдин Максуди

БОРАДӘРАНӘ (ТУГАННАРЧА) ТӘБРИК

Газиз борадәрем[*]! Без икемез бергә үстек, бала вакытымызда безнең ниятләремез бер-беренә бик якын иделәр. Без һәр икемез гыйлем вә мәгариф юлына китәчәк кешеләр идек. Һәр икемез мәдрәсәдә берничә еллар укыган идек. Ләкин, пәдәремезнең мәгыйшәтен тәэмин итү өчен, безнең беремезгә сәүдә вә кәсеп юлына китү лязим ***(кирәк)*** *булган иде.*

Икемезнең иттифак белә булган карарымыз буенча, кәсеп вә сәүдә юлына кереп, ата вә аналарымызны тәрбия кыйлу вазифасы миңа йөкләнгән иде.

Бу вазифаны мин мөкаддәс гад ***(исәп)*** *кыйлып ихтияр иткән идем. Ләкин сез дәхи* ***(тагын)*** *да мөкаддәс булган гыйлем вә мәгариф юлында калган идеңез. Бу юлда муаффәкътә булдыңыз.*

Мин үзем хәлемнән вә тоткан юлымнан шикаять кыйлмасам да, сезнең хәл вә мәсләкеңезне, ягъни гыйлем вә нәшер мәгариф юлын бигрәк мөкаддәс саныйм. Сезнең гыйлем вә нәшер мәгариф юлындагы муаффәкыятеңез ***(уңышыгыз)*** *бу көн «Йолдыз»га ун ел тулу берлә бигрәк заһир* ***(билгеле)*** *буладыр. Бу көнге бәйрәм сезнең өчен генә түгел, барча туганнарымыз өчен дә мөштәрәктер* ***(уртак)****. Сезнең бу бәйрәмгә мин сезнең үзеңез кадәр үк сөенәм. Бу көнге көнеңез берлә мин сезне чын күңелемнән тәбрик итәм.*

Текстларны һәм искәрмәләрне басмага ***Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде.* ■

[*] Борадәр – ир туган.

Бу ел татар җәмәгатьчелеге өчен Әмирханнар нәселенең күренекле вәкилләрен искә төшерү, хәтер яңарту вакыты булды. 29 гыйнвар көнне Татарстан Язучылар берлегенең Тукай клубында мәшһүр татар язучысы Фатыйх Әмирханның тууына 130 ел тулу уңаеннан бик матур һәм тирән эчтәлекле кичә үтте. Анда әдәбият галимнәре, язучылар, сәнгать әһелләре чыгыш ясады. 10 март көнне Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты Гыйльми шурасының киңәйтелгән утырышы тарих фәннәре докторы, Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе Равил Госман улы Әмирханов истәлегенә багышлап, тууына 70 ел тулу уңаеннан оештырылды.

РАВИЛ ӘМИРХАН мирасы

Илдус Заһидуллин

Бирәдә галимнең хезмәттәшләре, туганнары, укучылары катнашты, истәлекләр белән уртаклашты. Р.Әмирханның тарих фәне үсешенә керткән өлеше, татар гуманитар фәненең совет һәм үзгәртеп кору елларында иҗтимагый тормышта, яшь буында милли үзаң һәм актив тормыш позициясен формалаштыруда тоткан урыны хакында мәгънәле сөйләшү булды.

«Анналлар» тарих мәктәбенә нигез салучыларның берсе Макс Блок: «*Тарихчы бәйсез кеше түгел. Ул узган вакытларны тарих рөхсәт иткән кадәр генә белә*», – дип язган. **Равил Госман** улы **Әмирханов** – тарих ышанычын казанган, фәнни даирәдә танылу алган мөхтәрәм галим, халкыбызның тарихи хәтерен, милли үзаңын яңартуда артый-талмый эшләгән мәгърифәтче.

Күренекле тарихчы, узган гасырның 90 нчы елларында татар милли хәрәкәте идеологы буларак, күпсанлы фәнни-популяр һәм публицистик язмалары ярдәмендә тарихи милләтпәрвәр шәхесләрне хәзерге буынга үрнәк итеп куеп, яңарышка өндәгән җәмәгать эшлеклесе дә. Коллегалары, бигрәк тә 80-90 нчы елларда фән юлына аяк баскан галим-голәмә өчен ул фикердәш, мәсләктәш, төпле киңәш бирә торган өлкән иптәш һәм остаз булды. Аның уй-гамәлләрен без данлыклы Әмирханнар нәселенең күренекле бер вәкиле фикере дип кабул итә, үзебезнең фәнни эшләрне анык үрнәк итеп куеп яза, кешеләр белән мөгамәләне Равил Госман улы кебек корырга омтыла идек. Бүген дә шулай.

Ульян өлкәсе Иске Кулаткы районының Муса, аннары Иске Атлаш, Татарстанның Биектау районы Татар Әйшәсе авыллары мәктәпләрендә эшләгән математика укытучысы Госман

Госман Әмирханов хатыны һәм тугыз баласы белән. Иң арткы рәттә, уңнан беренче – Р.Әмирхан. 1959-1960 еллар

Әмирханның ишле гаиләсендә тәрбия алган ул-кызлар «буй тарткач», мәктәпне тәмамлагач, «Казанга кайтып» (Илдус Әмирханов сүзе) башкалабызда югары белем ала һәм биредә төпләнеп, гаилә корып, һәрберсе үзе сайлаган өлкәдә милләткә намуслы хезмәт итә.

Р.Г.Әмирхан, Казан дәүләт педагогика институтын «милли мәктәптә рус теле һәм әдәбияты укытучысы» белгечлеге буенча тәмамлагач, Балтач, Иске Салавыч һәм Ленино-Кокушкино авылларындагы урта белем бирү мәктәбендә өч ел эшли. 1971 елда Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының тарих секторы аспирантурасына укырга керә – гомерен фәнгә багышлый[1].

Р.Г.Әмирханның тормыш юлы XX гасырның 60 нчы еллар «җепшеклеген», 70 нче еллар «торгынлыгын», 80 нче еллар азагы «үзгәртеп-коруын», 90 нчы еллар «суверенитет хәрәкәтен», 2000 еллар башындагы «милли сүрелешне» колачлый. Ул – бер сәяси шартларда тәрбияләнеп һәм галим булып җитлегеп, совет идеологиясе беткәч, гуманитар өлкәдәге хөррият һәм методологик кризис шартларында иҗат иткән, мәсләген көйләгән шәхес. Аның КПСС сафына басмавы да күңел халәтен, гражданлык мәсләген чамаларга ярдәм итә сыман.

Фәнни җитәкчесе, тарих фәннәре докторы Хөсәен Хәсән улы Хәсәнов, күрәсең, аспирантның гарәп имлясын белүен исәпкә алып, үзе шөгыльләнгән чор белән бәйле һәм шул заман идеологиясенә туры килгән «Беренче рус революциясе елларында (1905-1907) татар демократик матбугаты» дигән диссертация темасын бирә[2]. Р.Г.Әмирхан аспирантураны диссертациясен өстәлгә куеп тәмамласа да, хезмәтне биш ел үткәч кенә яклый һәм тарих фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗәгә ия була. Бүгенге көн күзлегеннән караганда, бу хезмәт – 1905-1907 елларда татар җәмгыятенең җитлегеп килүче милләт икәнлеген дәлилләүче, вакытлы матбугатның төрле юнәлештәге сәяси агым тарафдары булуын раслаучы китап.

Милли яңарыш чоры – XX гасыр башы тарихы белән шөгыльләнә башлау яшь галимнең киләчәктәге гыйльми эшчәнлек юнәлешен билгели. Р.Г.Әмирханның докторлык диссертациясе темасы да үзгәртеп кору башланганчы ук эшли башлаган теманың дәвамы булып тора. 1997 елда Казан университетында уңышлы якланган «Татар вакытлы матбугатында рус мәдәнияте үсеше мәсьәләләре (1905-1917 еллар)» дип аталган докторлык диссертациясе «Шәрык-Гареп» кысаларында Россиядә революциягә кадәрге татар вакытлы матбугаты (рус мәдәнияте үсеше мисалында)» исеме белән 2002 елда дөнья күрде[3]. Китап татар иҗтимагый фикеренә рус мәдәнияте һәм фәненең йогынтысын, татарларның төрле мәдәниятне кабул итәргә әзер, яңалыкка йөз тоткан милләт булуын раслый. Мин китапны культурологик планда эшләнгән классик фәнни хезмәт дип саныйм. Анда: татарларның матбу-

[1] Гарипова З.Г., А.М.Валиев. Жизненный и творческий путь Р.У.Амирханова // Страницы истории татарского народа и Татарстана в новое и новейшее время. Памяти Равиля Усмановича Амирханова посвящается: Сб. статей. – Казань: Институт истории им.Ш.Марджани АН РТ, 2007. – С.3-9.

[2] Амирханов Р.У. Татарская демократическая периодическая печать в годы первой русской революции (1905-1907 гг.) – М.: «Наука», 1988. – 191 с.

[3] Амирханов Р.У. Татарская дореволюционная пресса в контексте «Восток-Запад» (на примере развития русской культуры). – Казань: Татар .кн. изд-тво, 2002.

гат булдыру өчен көрәше, татар газета-журналларының таралу географиясе яктыртыла; идея-юнәлеше ягыннан татар басма матбугатының сыйфаты билгеләнә; төпле классификация ясала; рус мәдәниятенең әдәби-публицистик һәм фәлсәфи мәсьәләләре турында язылa; рус музыкасы, рәсем, сынлы сәнгате мәсьәләләре тикшерелә, мәгариф һәм фәнгә кагылышлы язмалар анализлана.

Китапта галимнең совет елларында язган монографиясе белән дәвамлылык та күзәтелә. Әйтик, татар телендә басылган газета-журналларның беренче китапта тәгаенләнгән сәяси юнәлешләрен «үстереп», яңа хезмәтендә 7 төркемгә аера. Бер үк вакытта, 1917 елгы Февраль инкыйлабыннан соңгы татар матбугатының төрле сәяси агымнарга бүленеше игътибарны җәлеп итә. Биредә инде карагруһчылар, консерваторлар калмаган, либерал-буржуаз юнәлеш тә юк. Либерал-демократик, милли һәм дини, милли һәм патриотик, хәрби-патриотик, революцион-демократик, социал-демократик агымнар гына бар. Шулай итеп, вакытлы матбугат нинди тиз йогынтыга ирелүче иҗтимагый көч һәм бер үк вакытта көчле иделогик корал, дигән фикер уздырыла.

Р.Г.Әмирхан, шушы монографияләреннән тыш, «Казан тарихы» исемле күмәк хезмәтнең беренче томында (Казан, 1988) «Ике революция арасында (1907 ел-1917 елның феврале)» исемле бүлекне яза. «Материалы по истории татарского народа» исемле җыентыкта «Татар милләте оешу», «Төрле төркем татарларның үзара мәдәни якынаюы һәм кушылуы» исемле саллы мәкаләләр белән катнаша[4]. Рус телендәге мәкаләләре тупланган «ХХ гасыр башында татар халкы һәм Татарстан» китабы милли яңарыш чорын төрле яктан ачып бирә, «Иттифак әл-мөслимин» партиясе, Дәүләт Думасы татар депутатлары, татар яшьләре, шәкертләре,

[4] Амирханов Р.У. Культурное сближение и слияние различных групп татар // Материалы по истории татарского народа. – Казань, 1995. – С.298-334; Амирханов Р.У. Образование татарской нации // Материалы по истории татарского народа. – Казань, 1995. – С.298-323.

Экспедиция вакытында. Сулдан уңга: Назыйм Ханзафаров, Равил Әмирхан, Өбрә авылында яшәүче бабай белән әби, Марсель Әхмәтҗанов, Рәшит Ягъфәров. Биектау районы, 1975 ел, сентябрь

Р.Әмирхан галимнәрне, әдипләрне «Әмирхания» фонды белән таныштыра. 1996 ел

милли оешмаларының эшчәнлеге, милли хәрәкәт лидерлары, вакытлы матбугатта милләт үсеше турында барган фикер алышулар, татарларда сәүдә һәм икътисад үсеше һ. б. турында тәфсилле мәгълүмат бирелә[5].

Югарыда аталганнардан тыш, Р.Г.Әмирханның фәнни иҗатыннан берничә зур теманы аерып алып була. Шуларның иң мөһиме: *«Татар мәгарифе тарихы, мәгариф һәм тарихчылар»* («Мөхәммәдия» мәдрәсәсе, Казан татар укытучылар мәктәбе, Г.Баруди, Р.Фәхреддин, М.Худяков, Ә.Вәлиди, дәреслекләр һәм татар мәгарифе үсеше үзенчәлекләре турында, шулай ук бу хакта «Татар энциклопедиясе»ндә басылган мәкаләләре), *«Иҗтимагый-сәяси тарих һәм җәмәгать эшлеклеләре»* (Г.Исхакый, Ф.Туктаров, Г.Еникиев, Х.Әмирхан, Ф.Әмирхан, Мөхәммәткамал Габделваһапов, И.Камалов, Дәүләт Думасында татар депутатлары, шәкертләр хәрәкәте, «Иттифак әл-мөслимин» партиясе һ.б. турында саллы язмалар).

Галим төбәк тарихын татар укучысына пропагандалау юнәлешендә дә мактаулы хезмәт куйды. Үзгәртеп кору башланганчы ук вакытлы матбугатта башкалабыз Казанның урамнары, истәлекле урыннары турында мавыктыргыч, кызыклы мәкаләләр циклын бастырды.

Р.Г.Әмирхан совет идеологиясе онытылырган Ә.Вәлидинең «Кыскача төрек-татар тарихы» әсәрен[6], Р.Фәхреддиннең «Шура» журналында басылган Алтын Урда, Казан ханнары турындагы мәкаләләр циклын 1990 нчы елларда ук вакытлы матбугатта һәм аерым җыентыклар[7] итеп халыкка кайтарды. Бу чорда урта һәм

[5] Амирханов Р.У. Татарский народ и Татарстан в начале XX века. Исторические зарисовки. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2005. – 152с.

[6] Вәлиди Әхмәд-Зәки. Кыскача төрек-татар тарихы. / Китапны төзүче, төп текстның транскрипциясен әзерләүче, искәрмә-аңлатмалар, библиографик исемлек һәм ахыр сүз авторы Равил Әмирхан. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – 181 б.

[7] Ризаэтдин Фәхретдин. Алтын Урда ханнары / Ризаитдин Фахретдин. Ханы Золотой Орды /

Ш.Мәрҗани кабере янында. Сулдан уңга: Рәшит Әмирхан, Марсель Әхмәтҗанов, Илдус Әмирхан, Рашат Әмирхан, Равил Әмирхан, Даниял Әмирхан, Рәшит Бикбаев. 1995 ел

югары мәктәптә яңа кертелгән «Татарстан һәм татар халкы тарихы» курсын укытырга әдәбият җитмәү сәбәпле, без бу хезмәтне уку әсбабы итеп тә файдаландык.

Р.Г.Әмирханны 1990 нчы елларда милли хәрәкәт идеологына әверелдергән әсәрләрне дә атап китү мәслихәт. Аның «Без татармыз»[8] исемле китабы милләткә бердәмлек кирәклеген искәртеп, халык санын алу кампанисе алдыннан махсус язылган иде. «Иманга тугрылык»[9] исемле җыентыгына авторның төрле елларда газета-журналларда дөнья күргән язмаларыннан үзе иң тирән мәгънәле һәм мөһим дип санаган фәнни-популяр һәм публицистик әсәрләре кертелгән. Мин бу китапны, галимнең үсеп килүче буынга мөрәҗәгате, дип атар идем. Бу мәкаләләрдә Равил ага милли мирасны, гореф-гадәтләрне кадерләп саклау, горур һәм кыю булу, милли рухны үстерү кирәклеге турында сүз алып бара.

Болардан тыш, галимнең әле басылмый калган мирасы да барлыгын искәртәсе килә. Р.Г.Әмирхан Казан шәһәренең меңьеллыгы уңаеннан Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтында башкалабыз тарихына багышлаган күмәк хезмәтне әзерләүдә дә актив катнашты. Бу китап басылмый калды. Шулай ук 1980 еллар азагында Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында башланып, 1990 нчы елларда Тарих институтында дәвам иткән 4 томлык «Татарстан тарихы» һәм «Татар халкы тарихы» исемле коллектив хезмәтләргә язган мәкаләләре дә дөнья күрми калды. Болар барысы да шул заман тарихчысы карашын һәм татар тарихи фикере үсешен өйрәнү өчен мөһим чыганак булып тора.

Фотолар ***Рәуфә Әмирханова*** *архивыннан.* ■

Равил Әмирхан тәрҗемәсендә һәм эшкәртүендә. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. – 127 б.; Ризаэтдин Фәхретдин. Казан ханнары. / Төзүчесе Равил Әмирхан. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. – 189 б.

[8] Әмирхан Р. Без – татармыз. – Казан: «Мәгариф» нәшр., 2002. – 32 б.

[9] Әмирхан Р. Иманга тугрылык. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. – 384 б.

АВЫЛ ТАРИХЫ – милләт тарихы!

Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты, Энциклопедия һәм төбәкне өйрәнү институты галимнәре, Бөтендөнья Татар конгрессы белгечләре белән килешеп, татар авыллары, бистә һәм шәһәрләре тарихын язарга карар кылды. 2015 елның октябрь аенда Россиякүләм, 2016 елның февраль аенда Республикакүләм татар төбәк тарихын өйрәнүчеләрнең корылтае уздырылды. Конгресс карамагындагы иҗтимагый оешма – Бөтентатар төбәк тарихын өйрәнүчеләрнең җәмгыяте төзелде (рәисе –* ***Камил Әбләзев****) һәм Республикакүләм төбәкне өйрәнүчеләрнең шурасы сайланды (рәисе –* ***Альберт Борһанов****). Хәзерге вакытта җирле, район оешмаларын төзү эше бара, көзен исә төбәкчеләрнең икенче Россиякүләм корылтае узачак. Шулар нигезендә, төбәк тарихын язу эшен җайга салу өчен, дәүләтнең махсус программасын булдыру, финанслау мәсьәләсен дә хәл итү уйланыла. Авыл, бистә һәм калалар тарихы турындагы китап 5 том булыр, дип фаразлана.*

Шул уңайдан редакциябездә Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының баш фәнни хезмәткәре, тарих фәннәре докторы, БТКның этнологик мониторинг үзәге җитәкчесе **Дамир Исхаков**, Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының Болгар-татар цивилизациясе үзәге җитәкчесе, «Безнең мирас» журналының редколлегия әгъзасы, археолог **Альберт Борһанов**, тарих фәннәре док-

*Фоторепортажны сайттан карарга мөмкин: beznenmiras.ru/tobek-tarikhyn-ojjrenucheler-jyeny/

торы, КФУ профессоры **Рәмзи Вәлиев**, «Татарстан» радиосының шеф-мөхәррире, журналист, төбәкне өйрәнүче **Нәсим Акмал**, ТР Милли музееның фәнни хезмәткәре **Флюра Дәминова**, Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының керәшеннәрне һәм нагайбәкләрне өйрәнү бүлеге фәнни хезмәткәре **Рөстәм Әминов**, Теләче районы Баландыш авылы мәктәбенең директоры, тарих укытучысы **Йосыф Хуҗин**, Саба районы Юлбат авылы мәктәбенең тарих укытучысы **Илдар Сафин**, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррир урынбасары **Марат Закир**, тарих һәм текстология бүлеге мөхәррире **Ленар Гобәйдуллин** катнашында «түгәрәк өстәл» оештырылды.**

Марат Закир:

– Моннан егерме еллар чамасы элек чыккан «Мирас»та бик әйбәт бер сәхифә бар. «Татар авыллары тарихы» дип атала ул. Күренекле әдип, журналист һәм галимнәребез үзләренең туган авыллары тарихын, кешеләрен, нәсел-нәсәп шәҗәрәләрен бәян кылганнар. Оренбургтагы Габдрахман авылы турында Мөсәгыйть ага Хәбибуллин, Балтачтагы Карадуганны Рәфыйкъ ага Шәрәфиев, Нурлаттагы Кычытканлыны Тәлгать ага Галиуллин, Биектаудагы Ашытны Фирдәвес апа Гарипова язган. Бу күркәм гамәлне «Безнең мирас» та яңартып җибәрде. Нәсим Акмалның туган авылы Катыш-Каран, Нәкыйп Каштанның Кыр Бикшиге турындагы әтрафлы язмалары дөнья күрде. Менә шулай, авылларыбызны берәмтекләп барлый-барлый, татар тарихын да тулыландырабыз түгелме?

Дамир Исхаков:

– Әйе, милли тарихтан башка төбәк тарихы да бар. Татар тарихы җиде томлы булса да, анда күп нәрсә язылып бетмәде, бу мөмкин дә түгел. Шуңа күрә төбәк тарихын белергә, аның белән милли тарихны баетырга, өстәмәләр кертергә була. Архив, китапханәләрдә сакланмаган күп мәгълүмат халык хәтерендә бар. Мин, этнограф буларак, үз гомеремдә 550гә якын татар авылында булдым, күп картлар белән сөйләштем. Чынлыкта, халык бик күп нәрсәне белә. Кызганыч, без аны үз вакытында җыйнап-туплап бетерә алмадык, әмма мәгълүмат буыннан-буынга күчә.

Бүген дөньяда 4300ләп татар авылы бар. Юкка чыкканнары да бик күп. Аларның да тарихын язарга кирәк. Тарихчылар белән төбәкне өйрәнүчеләр берләшсә генә, бу эшне ерып чыгып була. Милләттәшләребезнең 30%ы гына Татарстанда, ә калганы республикабыздан читтә яши. Төбәкне өйрәнүчеләрнең җирле оешмалары татарлар күпләп урнашкан һәр районда һәм эре шәһәрдә дә булырга тиеш. Шәһәр, андагы бистәләр халкы тарихы да төбәкчелекнең аерылгысыз бер өлеше. Мәскәүне генә алыйк. Күпләр, биредәге татар тарихы XIX гасырдан башлана, ди. Ә үткәнгә күз салсак, Алтын Урда, аннан соңгы дәверләрдә дә биредә милләттәшләребезнең саны ишле булган. Авыллар, бистә-калалар тарихын язып чыксак, татарның Россиядәге урыны бик ачык күренәчәк.

Альберт Борһанов:

– 1994 елда Татарстанга кайту белән, авыллар тарихын ныклап тикшерергә кирәк, дигән фикергә килдем. Ми-

** «Түгәрәк өстәл»дән фото һәм видеорепортажны beznenmiras.ru сайтыннан карарга мөмкин.

нем коллегаларым – археологларның күбесе авылда эшләми, нигездә шәһәрләрне казу белән генә шөгыльләнә. Дөрес, Николай Калинин, Альфред Халиков, Равил Фәхретдинов эшләгән чорда авыллардагы археологик, эпиграфик истәлекләрне өйрәнү буенча махсус программа бар иде, китаплар да күп басылып чыкты. Ләкин аларның материаллары искерде, кайбер хата-төгәлсезлекләре дә ачыкланды. Эшне Казан артыннан башлап җибәрдем...

Дамир Исхаков:

– Шунысын да әйтергә кирәк: Казан артындагы беренче фәнни-гамәли конференция 1998 елда Биектау районы хакимияте башлыгы, хәзерге Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханов ярдәме белән оештырылды.

Альберт Борһанов:

– Конференция «Казан арты: тарих һәм мәдәният проблемалары» дип аталган иде. Заманында бу юнәлештә өч китап та чыгарырга өлгердек. Шуннан соң Тау ягы, республикабызның көнчыгыш районнары җентекләп тикшерелде, ә соңрак Киров һәм Оренбург өлкәләре, Чуашия Республикасы аз-маз өйрәнелде.

Казан шәһәренең 1000 еллык юбилеена әзерләнгән елларда нигездә Казан Кремле өйрәнелде. Ә бит «Казан» милли-мәдәни үзәге янындагы Иске шәһәрлек, Елан Тау, Архиерей дачалары – Кабан, Боровое Матюшино шәһәрлекләре дә бар. Хәтта Иске Казан да тиешле дәрәҗәдә өйрәнелеп бетмәде... Әлеге олуг юбилейны үткәрү алдыннан кайбер галимнәр махсус бу шәһәрлекләрне күрмәскә, аларга игътибар итмәскә тырышты. Аңа өлгерә дә алмадылар, чөнки катлаулы проблемалар килеп чыгарга мөмкин, ә Казанның меңьеллыгын тизрәк үткәрергә кирәк иде.

Ни өчен бу мәсьәләне күтәрәм? Татарстанга яңа килгән митрополит Феофан республикабыздагы элекке чиркәү биналарын тергезеп, аны дин әһелләренә кайтару эшен дәвам итә, хәтта ныклап тотынды. 1997 елда Кабан шәһәрлегендә казу эшләрен оештырдык. Һәммәгезгә мәгълүм, анда Әби патша заманында төзелгән чиркәү бар. Совет чорында аның бинасына авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институты урнаштырылды. Без күптән түгел генә Кабан шәһәрлегенә барып, анда чиркәүне яңадан торгызырга җыенуларын күреп кайттык.

Елан тау шәһәрлеген заманында татар археологлары тикшерә алмый калды. Дөрес, бер-ике галим барып, анда татар материалы юк, дигән нәтиҗәгә килде. Шуның белән Елан тау татар археологиясеннән, тарихыннан төшеп калды.

Дамир Исхаков:

– Ә чынбарлыкта Елан тау турында татар халык риваятьләрендә шактый кызыклы мәгълүматлар бар. Халык Иске Казаннан күчкән вакытта әүвәл Елан тауга күчеп торган, ә аннары гына бирегә, хәзерге башкалабызга килгән. Әгәр дә халык телендә гасырдан-гасырга ниндидер мәгълүмат сакланган икән, ул, әлбәттә, археологик җәһәттән һәм башка тарихи чыганаклар белән дә җентекләп тикшерелергә тиеш.

Альберт Борһанов:

– Безнең дәүләт кануни нигездә чиркәүдән аерылган, ә чиркәү – дәүләттән. Әгәр дә чиркәү Кабан шәһәрлеген үзенә яңадан ала икән, Елан тау кебек вазгыять кабатланачак, әлеге тарихи үзәк милләттәшләребез кулыннан китәчәк һәм анда бер генә археолог та көрәк тотып казу эшләрен башкара алмаячак. 1997 елгы казу эшләре вакытында без анда 1360 елда җирләнгән аксөякнең каберен таптык. XIV гасырда яшәгән Борак хан исеме сугылган акча да килеп чыкты. Алтын Урданың кера-

мика калдыклары һәм башка табышлар да булды. Мәрҗани язуынча, андагы каберлектә 1281 елгы таш та сакланган. Воскресенский соборы төзелгән вакытта (XVIII гасырда) аның нигезенә гарәби язулы татар кабер ташлары салынган, хәзер алар штукатур белән капланган. Парк урынында урта гасырлардагы татар зираты булып, кабер ташлары да сакланган иде. Бу ядкярләр «Казан» милли-мәдәни үзәгенә алынды. Әлеге җирләр чиркәүгә кайтарыла калса, әлбәттә, татар тарихы читтә калачак.

Без бу җирне музей-тыюлыкка әйләндерергә тиешбез. Әгәр дә христианнар үзләренең татар кабер ташларыннан салынган гыйбадәтханәләрен күтәрәләр икән, аның янәшәсендә мәчет тә төзергә кирәк. Толерантлык кебек матур сүзләр шушы эштә дә чагылыш табарга тиеш. Миңа Николай атакай болай дип сөйләде: «Менә, тарихи дөреслекне торгызырга кирәк!» Мин аңа: «Әгәр дә тарихи дөреслекне торгызырга телибез икән, эшне Болгар, Алтын Урда катламын торгызудан башларга кирәк. Без рус-чиркәү компонентын инкяр итмибез, бу – төрки-славян ядкяре», – дидем.

Авылларны өйрәнгәндә археология, эпиграфика чыганаклары искиткеч мөһим роль уйный. 2009 елгы «Татарстан археологик ядкярләренең тупланмасы» дигән китапта төгәлсезлекләр шактый. Мин килгәнче, 1999 елда Кукмара районында ике археологик һәйкәл бар иде. Хәзер аларның саны 36га җитте. Ел саен бер районга археологик разведка оештырсаң гына да (монда әле казу эшләре турында сүз бармый), музейларда булсак, халык белән аралашсак, күп нәрсәләр ачыклана. Кукмара районында оештырылган конференция вакытында гына да шактый кеше килеп: «Биредә шундый нәрсә бар, тегендә шул табылды», – дип безгә хәбәр итте.

Теләченең үзәгенә килеп керсәгез, аңа 1650 елда нигез салынган, дип язылган истәлек билгесен күрәсез. Ләкин Теләченең үзендә, Олы Нырсы, Иске Җөридәге археологик, эпиграфик ядкярләр әлеге авылларга 1320 елларда, Алтын Урда дәверендә, ә бәлки аңа кадәр үк нигез салынганын дәлилли. Шуңа күрә казу, өйрәнү эшләрен дәвам итәргә кирәк.

Дамир Исхаков:

– Дөрес, археологлар төп игътибарны зур, башкала-шәһәрләрне өйрәнүгә бирә. Ә бит Казан ханлыгында гына да аерым кенәзлекләрнең үз башкаласы булган. Мәсәлән: Алат, Арча, Җөри, Чаллы... 1912 елда Сәет Вахиди Саба районының Мамалай авылында Сәхипгәрәй хан ярлыгы тапкан. Ярлык теләсә кайда табылмый, димәк, монда урта гасырларда зур феодаль үзәк булган. Шул ук Саба районындагы Аккүл-Бигәнәй авылы янында, риваятьләргә караганда, хан кызлары яшәгән, дигән мәгълүмат бар. Димәк, бу да үзенә күрә бер тарихи үзәк.

Татарстаннан читкә чыгып та эшләргә кирәк. «Түләк һәм Сусылу» дастаны барыгызга да мәгълүм. Дастанда тасвирланган шәхес, атаклы Габдулла ханның бабалары яшәгән урын – Балкан тау. Ул Бәләбәйдән ерак түгел, Аслы күл янында. Халыктан ишетүемчә, анда элек кабер ташлары да булган, бәлки алар авып, җиргә күмелеп кенә ята торганнардыр. Бу – Алтын Урданың Болгар вилаятенә турыдан-туры бәйле урын. Шуңа күрә безгә аны да ныклап өйрәнергә кирәк.

Биләрдәге Изгеләр чишмәсе янына да күренекле шәхесләр җирләнгән. Алар исә Алтын Урданың исламлашуы белән нык бәйләнгән. Әйткәнемчә, халык хәтерендәге мәгълүмат – милли тарихыбыз өчен бәһасез хәзинә.

Йосыф Хуҗин:

– Без борынгы, тарихи төбәктә яшибез. Тарих белән кызыксынуым, әлбәттә, балачактан башлана. Авылыбызның китапханәчесе шагыйрь Әнәс Кари-

да белем алуы белән горурлана иде. Ул безне – китапханәгә килгән үз укучыларын яңа кайткан китаплар белән даими кызыксындырып торды. Еш кына китап укучылар конференциясе оештырды. Әби-бабайларның сөйләгәннәреннән дә күпне тыңлап-ишетеп үстек. Исемем Йосыф булгач, әбиләр кич утырырга җыелалар иде дә, мине алларына утыртып, «Кыйссаи Йосыф»ны җырлап-көйләп укып җибәрәләр иде. 1970 елларда Фирдәвес апа Гарипова авыллар тарихын өйрәнеп йөрде. Без аңа да ияреп, елга, күл, авыл исемнәре тарихы белән кызыксынып киттек. Әгәр дә ул вакытта хәзерге акылым булса, ишеткән, күргән һәм белгәннәремне теркәп-язып барган булыр идем. Кызганыч, бу эшкә бик соң тотындык.

Тарих укытучысы буларак, балаларга әллә кайдагы Гарәп хәлифәлеге, Гуситлар хәрәкәте турында сөйлибез, үзебезнең төбәк тарихы читтә кала. Дөрес, балалар бераз кызыксына: «Абый, бу болай булган, бабай минем шулай сөйләде әле», – дип, күп кенә мәгълүматны туплап барабыз, әмма алар язма, археологик, тарихи чыганаклар белән җитди дәлилләнмәгән. Әлбәттә, киләчәктә дә бу эшне дәвам итеп, авылларда яшәүче өлкән кешеләр ярдәмендә борынгы мирасны саклап каласы иде. Кызганыч, мәктәп программасында тарих укытуны шактый кыстылар.

Марат Закир:

– Әле моннан егерме еллар элгәре, белүемчә, Кукмара мәктәпләрендә балаларга «Кукмара районы тарихы»н укыталар иде...

Дамир Исхаков:

– Россия кануннары буенча, безнең мәктәпләрдә Ватан тарихы укытылырга тиеш. Анда җирле тарихка бик аз урын бирелә. Һәр төбәк буенча аерым дәреслекләр булу зарур. Себер татарлары буенча югары уку йортлары һәм мәктәпләр өчен төбәкчелек рухында язылган дәреслекләр бастырып чыгардык. Шундый әсбапларны да булдыру – безнең әһәмиятле бурычларның берсе.

Йосыф Хуҗин:

– Тарих дәресләре өчкә бүленгән. Берсе – чит илләр тарихы, икенчесе – Ватан тарихы, өченче кисәк – ун сәгать – Татарстан тарихы. Бу вакытта балаларга нәрсә генә өйрәтәсең?!

Илдар Сафин:

– Моннан 3-4 ел элек ТР Мәгариф министрлыгы үзе акча биреп, район тарихы дәреслекләре төзетте. Без – Саба районының 6 укытучысы бу китапны тиз арада язып төгәлләдек. Дөрес, дәреслек китап буларак басылып чыкмады, аның электрон варианты файдаланыла. Чистай, Мамадыш, Балык Бистәсе кебек районнарда да шундый дәреслекләр төзелде. Ә Чистайда исә аерым предмет итеп укыту бәхетенә дә ирештеләр.

Альберт Борһанов:

– Районнардагы хакимият башлыкларының аң-гыйлем дәрәҗәсе төрле. Зыялы җитәкчеләр үзләре үк экспедиция, фәнни-гамәли конференцияләр оештырырга, төбәк тарихы буенча китаплар чыгарырга ярдәм итә. Тиздән Теләче районы оешуга 25 ел булачак. Шул уңайдан, анда фәнни-тикшеренү эшләрен алып бару һәм китаплар чыгару нияте бар. Чөнки халык тарихка сусаган, алар галимнәрне көтә. 10-15 галим, җирле хакимият, җәмәгатьчелек, мәктәп укучылары, студентлар, музей хезмәткәрләре берләшеп гамәл кылсак кына безнең эш алга китәчәк.

Марат Закир:

– Соңгы вакытта бер кызыклы вә позитив яңалыкны күзәтеп киләм. Хәер, инде хәзер яңалык та түгел: яше-карты

интернетта утыра һәм туган авылының, төбәгенең сайтын булдыра, тарихын, кызыклы шәхесләрен ачыклап, кемдә нинди фоторәсемнәр бар – шуларны туплап, бөтен дөнья буйлап (!) авылдашларын барлый. Күркәм, мәгънәле күренеш!

Дамир Исхаков:

– Әйе, һәр авылның үз сайты булырга тиеш. Кемдә нинди мәгълүмат яки чыганак бар, шунда куя ала. Бер авыл турында бөтенләй дә уйламаган, читтәге бер кеше кулында материал булуы ихтимал. Кайчандыр аның ата-бабасы шул төбәктән күчеп киткән булырга мөмкин...

Һәрбер авылда, район үзәкләрендә музейлар бар. Иң әһәмиятлесе – анда матди хәзинә, археологик табылдыклар саклана. Шуңа күрә безгә ул әйберләрне дә барларга һәм фәнни әйләнешкә кертергә кирәк. Мин хәзерге вакытта Казан шәһәренең 15 нче татар гимназиясендә музей төзү белән мәшгуль. Кызганыч, балалар үзләре яши торган җирлекнең, укый торган уку йортының тарихын белми. Алардан: «Бишбалтаның нәрсә икәнен беләсезме?» – дип сорыйм. Берәү дә әйтә алмый. Музейлар һәм андагы эшне оештыру белән дә төбәкчеләр шөгыльләнергә тиеш. Түгәрәк ярдәмендә эшләү, әлбәттә, иң уңайлы ысул. Һәрбер мәктәптә дә туган якны өйрәнү түгәрәген төзергә мөмкин. Моны бернинди канун да инкяр итми, бу, киресенчә, хуплана гына.

Илдар Сафин:

– Мин 33 ел буе тарих укытам. Әйе, түгәрәкләр, музейлар ярдәмендә күп эш башкарып була. Ләкин безнең мәктәп расписаниесендә «Саба районы тарихы» дигән махсус предмет булырга тиеш. Дөрес, РФ Мәгариф министрлыгы төбәк тарихы буенча региональ компонент дип дәрес сәгатьләре бирә. Бу вакытны БДИга әзерләнү максатыннан сарыф итәргә мәҗбүр булабыз. Түгәрәк һәм музейларга бөтен бала йөрми бит... Бишбалта тарихын белмиләр, дип әйтәсез. Әгәр дә мәктәптә район тарихы предмет буларак укытылса, балалар, һичшиксез, күп нәрсәне белер иде. Бу мәсьәлә хөкүмәт дәрәҗәсендә хәл ителергә тиеш. Татарстаныбыз төзелүнең йөзьеллыгы алдыннан бу аеруча актуаль. Бер елда каралган ун сәгать дәрестә без Татарстан тарихын укытыйкмы, районныкы турында сөйликме? Үзебезнең авыл тарихы да бар бит әле...

Флюра Дәминова:

– Үземнең тәҗрибәмнән чыгып шуны әйтәсем килә: мәктәп музейларының әһәмияте чиксез. 2000 елда Арча район хакимияте башлыгы урынбасары Ринат абый Фазлыйәхмәтов Гөберчәк авылында Мөхәммәт Мәһдиевнең музеен төзегәндә шактый күп материал белән ярдәм итте, эшнең башында да ул торды. Авылдагы мәктәпнең бер классы сирәк очрый торган экспонат белән тулган иде һәм без аларны мемориаль музей төзегәндә файдаландык. Шулай ук, экспедициягә чыгып, Мөхәммәт Мәһдиевнең әйберләрен эзләп йөргәндә безгә зираттан казып алынган китапларны да тапшырдылар. Шул ук елны Әтнә районының Комыргуҗа авылында да Шиһабетдин Мәрҗани музеен ачтык.

Марат Закир:

– Сүз башымда әдипләребезнең туган авыллары хакында язуын әйткән идем. Хәер, монысы бер хәл. Хәзер бит кем иренми – шул авыл тарихын язарга алына. Чын галимнәр иләге аша үтсен иде аларның язмалары...

Дамир Исхаков:

– Әлбәттә, бу җәһәттән бер бүлек булырга тиеш. Басылып чыгасы китапны бәяләмәсез Татарстан китап нәшрияты бастырып чыгармый. Авыллар тарихын



Республикакүләм татар төбәк тарихын өйрәнүчеләрнең корылтаенда оештырылган китаплар күргәзмәсе

ничек язарга дигән методик кулланма да эшләнде. Чыганаклар табу – һәвәскәр тарихчыларны борчыган мәсьәлә. Аларның читтәге архивларга барырга, аннан документларның күчерелмәләрен алырга мөмкинлеге юк. Шунлыктан, бу эшне дә үзәкләштермичә башкарып булмый...

Чынлыкта Татарстаннан, чит төбәкләрдәге авыллардан да кулъязмалар һәм башка кызыклы әйберләр табарга мөмкин. Әгәр дә шәһәрнең борынгы, бай гаиләләренә керәсез икән, аларда иске фоторәсемнәрнең шактый икәнлеген күрәсез. XIX гасыр азагы-XX йөз башы фоторәсемнәре – үзенә күрә кызык тарихи чыганак. Элек ничек киенгәннәр? Кыяфәтләре нинди? Байларча яшәү рәвеше ничек булган? Бу мәгълүматлар да төбәк тарихы буенча китапларны язганда гаять әһәмиятле. Без – этнографлар экспедиция вакытында андый фотоларны халыктан еш кына ялынып-ялварып ала идек. Хәзер институтыбызның коллекциясендә төрле төбәктән алып кайткан 500гә якын татар фотографиясе бар. Фәнни эшләр язганда аларны кулланырга мөмкин.

Халыкта яшерен материаллар да бар. Күптән түгел Себердә берничә шәех һәм сәетләрнең нәсел шәҗәрәсе табылды. Агач сапка уралган шәҗәрә Мөхәммәт пәйгамбәрдән (с.г.в.) башлана. Аны теләсә кемгә күрсәтмиләр. Әгәр дә халык арасында ышанычлы кеше түгелсең икән, аны күрмәячәксең, чөнки һәрбер шәҗәрәнең сакчысы бар.

Рәмзи Вәлиев:

– Без озак еллар үз авылыбызның үткәнен белмәдек. Бабайларыбыз тарихи документларны яшереп саклаган, безгә бу турыда берни әйтмәделәр. Карашәм шәҗәрәсе дә – шундыйлардан. Аны табып, өйрәнгәне өчен без Марсель Әхмәтҗановка бөтен авылыбыз белән рәхмәтле. Ш.Мөхәммәдьяров Тау ягы халкының 1552 елгы сугышларда катнашмавы турында язып калдырды. Аның фикере соңрак басылып чыккан «Татарстан тарихы»нда кабатланды. Бу – ялган. Ә авылдан табылган шәҗәрәдә минем Габделкасыйм бабам, аның энесе Габделхалик бабаның иртән торып, намаз укып, сугышка китүе, ястүгә кире кайтулары турында язылган. Анда бит ике ир-ат кына түгел, ә бөтен авыл халкы күтәрелеп, төркем булып барган, дип

уйларга кирәк. Бу аяусыз сугышны без белмәдек. Габделкасыйм бабабыз Ислам авылындагы изгеләр каберлегенә җирләнгән. Авыл халкы ел саен андагы чишмәне, каберлекне карап, чистартып тора, тирә-якка агач утырта. Кыскасы, авыл халкы үзе белән бик күп мәгълүматны, язма документларны яшереп саклаган, аны эзләргә, табарга гына кирәк.

Йосыф Хуҗин:

– Республикабызда мәктәпләрнең кыскартылуы-ябылуы сәбәпле, бушаган урынга авыл советы, балалар бакчасы, китапханә кереп урнаша. Мондый очракта элекке мәктәп бинасында музейларга урын табылмый. Шулай итеп музей бетерелә, андагы материаллар да юкка чыга...

Дамир Исхаков:

– Һичшиксез, мәктәп музейларында саклана торган тарихи ядкярләрнең хисабы булырга, алар сакланырга тиеш. Тарихи чыганакларны теләсә кая ташлап йөрергә ярамый, бу бит – безнең газиз мирасыбыз!

Альберт Борһанов:

– Әлбәттә, мондый проблема да бар. Мәктәпләрне кыскартып, андагы музей бүлмәсенә бөтенләй чит оешманы китереп тыгалар. Шул сәбәпле, шактый бай археологик табыш юкка чыга. Мөслим районы хакимияте башлыгы Рамил Муллинга, авыллардагы бар булмыш табылдыкларны район үзәгендәге төбәкне өйрәнү музеена туплагыз, исәпкә һәм контрольгә алыгыз, дип аңлаттым. Скиф кылычы кебек шактый бай, борынгы әйберләр саклана торган бу музей ташландык хәлдә иде. Нәтиҗә дә озак көттермәде: район үзәгендә затлы музей ачылды һәм Мөслимнең брендына әйләнде. Шул сәбәпле, район, авыл музейларындагы һәр әйберне хисапка алырга кирәк. Алар мәктәптә саклансын, әмма исәпкә алынсын, кызыксынган һәр кеше кайда, нәрсә бар икәнен белеп торсын. Мөслим һәм Минзәлә районнары чигендәге бер татар авылының мәктәп директоры пенсиягә чыккач, музейдагы бөтен әйберне үзе белән алып киткән һәм сатып бетергән. Кызганыч, мондый ямьсез күренешләр дә юк түгел.

Рөстәм Әминов:

– Совет хакимияте оешканнан соң, элекке Казан губернасының күп кенә авыллары Татарстаннан читтә калды. Хәзерге Чуаш Республикасының Козлов районында Әлмән, Кармыш (Янгилде) авыллары бар. Элек алар Казан губернасында булып, хәзерге Яшел Үзән районы авыллары халкы белән тыгыз элемтәдә яшәгән, чөнки үзара күрше, бер милләт, бер дин вәкилләре. Яңа административ-территориаль бүленештән соң, мондый татар авыллары галимнәребез игътибарыннан читтә калды. Андагы җирле хакимият түрәләре дә бу татар авыллары белән шөгыльләнергә теләми. Безнең төбәк белгечләре моңа да игътибар итсен иде.

Нәсим Акмал:

– Еш кына, аеруча мәктәпләрдә шуны ишетәсең: авыл исемен чуаштан, маридан яки мукшыдан килеп чыккан, дип әйтергә яраталар. Кайбыч районындагы Морза Бәрлебашы авылының исеме килеп чыгышын кызыксынып тикшерә башладым. Авыл халкы аңлатуынча, «берлинга» мукшы телендә колмак дигән сүз икән. Яр буенда колмак күп үскән дә, шул сәбәпле елга, соңрак авыл Бәрлебаш дип аталган, имеш. Эзләнә торгач, Украинада да Бәрлебаш авылы бар икәне ачыкланды. Украин сүзлегеннән белдем: «бәрле» – борынгы төрки телдә авыр кылыч дигәнне аңлата икән. Аңлашыла ки, заманын-

да татар, өстен халык буларак, башка халыкларның теленә йогынты ясаган. Татар теле сүзләре күрше халыкларга кереп, безнең көнгә кадәр сакланып калган. Безнең халык исә күп атамаларны гарәпнекенә алмаштырган яки Казан ягыннан әдәби тел нормалары үтеп кергән.

Чүпрәле районында Кәкерле авылы бар. Зариф Бәшири язуынча, мишәр белән чуаш һәрвакыт дус-тату, тел-лөгать алмашып яшәгән. Чуаш телендә «кәкер» сүзенең кычкыртып сигнал бирер өчен кулланыла торган быргы икәнлеге ачыкланды. Гомәр ага Саттаров, Тау ягындагы авыл исемнәре чуаштан кергән, дип яза. Чынбарлыкта бу исемнәрнең күбесе чуашның үзенә татардан кергән. Авыл тарихын язганда боларга да игътибар итсәк иде.

Марат Закир:

– Юкка чыккан авылларның да тарихын язарга кирәк, дип, Дамир әфәнде бик хак әйтә. Быелның февраль аенда Курган өлкәсендәге алты татар районына сәфәр кылырга туры килде: Әлмән, Сафакүл, Целинный, Шадрин, Шумиха һәм Шатров... Борынгы тарихлы авылларыбыз биредә хәттин ашкан булган. Иң аянычы шул – алар юкка чыга баралар...

Дамир Исхаков:

– Татарстандагы татар авыллары тарихын өйрәнгәндә, бер үк вакытта рус һәм башка авылларның да тарихын язарга кирәк, дигән карарга киленде. Чөнки республикабызда яшәгән урыс үзенең монда кайчан килеп урнашканын, кемнең җирле халык икәнен яхшы белергә тиеш. Бернинди пропаганда да алып барырга кирәкми, тарих язылса, барысы да ачык күренәчәк.

Альберт Борһанов:

– Авыллар тарихын өйрәнү һәм саклау өчен җирле халыкниләр эшли ала соң? Беренчедән, табигать һәйкәлләрен өйрәнергә кирәк. Икенчедән, тарихи-мәдәни мирасны, археология ядкярләрен барлау. Өченчедән, авыллардагы архитектура объектларын, фабрика, кибет, бай складларының биналарын, музейларны, андагы материалларны саклау әһәмиятле. Тарихи чыганакны гамәли яктан файдалану, фәнни-популяр китапларга, туристик маршрутка кертү, укыту-тәрбия эшләрендә куллану да актуаль.

Курган өлкәсенең Әлмән районында юкка чыккан авылларга куелган истәлек ташы

Дамир Исхаков:

– Хезмәтләрне язганда татар авылларындагы элекке тормыш-көнкүрешне дә күрсәтергә кирәк. Андагы кайбер матур үрнәкләрне хәзерге яшәешебезгә кертеп җибәрү дә зур тәрбияви әһәмияткә ия. Яшьләр авыл Сабан туеның элек ничек булганын белми. Ә бит әлеге милли бәйрәмебезнең асыл рухы елдан-ел югала бара. Борынгылар нинди уеннар уйнаган? Аулак өйләр ничек узган?.. Боларның барысы турында да язарга кирәк. Тарихны бәян иткәндә шулар да истә тотылырга, авылдагы көндәлек тормыш та тасвирланырга тиеш.

«Түгәрәк өстәл» утырышы барышында яңгыраган чыгышларны, фикер-тәкъдимнәрне басмага Ленар Гобәйдуллин әзерләде. ■

БЕЗ НИНДИ МИРАСКА МОХТАҖ?

Мирза МӘХМҮТОВ, академик:

– «Мирас» журналы... Нигә кирәк булды әле бу? Әллә башка журналларда чын сүз әйтергә урын да калмадымы? Әллә аларда буш сүзләр күбәеп киттеме? Йәисә галимнәр эзләнүе безне халык бер дә белмәгән мәгълүматка ия иттеме? Мондый сорауларны күп итеп куеп була һәм аларга уңай йә тискәре җавап та эзләп торасы юк. Сер нәрсәдә соң?

Совет чорында гасырга якын вакыт татар халкы үзенең чын тарихын өйрәнә алмыйча килде. Халык тарихы урынына без Татарстан АССР дигән харитада (картада) карандаш белән уратып алынган, чикләнгән бер җирнең, кечкенә бер территориянең тарихын өйрәнү белән мәшгуль булдык. Анда яшәгән халыклар турында алар большевиклар җитәкчелегендә революция ясадылар, колхозлар төзеделәр һәм коммунизмга таба баралар, дип өйрәтелде.

Татар халкының бер мең дүрт йөз елга якын тарихы барлыгын да юньләп белмәдек, аның үзенчәлекле рухи дөньясы, аның хыяллары, уй-фикерләре турында бөтенләй диярлек әйтелмәде. Шушы халыкның монгол-татарлар килгәнче үк алты йөз ел үз дәүләтләрендә яшәгән дәвер турында нәрсә белдек соң? Ә бит шул дәүләт Көнчыгыш Европада заманасына күрә иң зур, бай һәм көчле ил булган, күршесендә шулай ук көчле Киев Русе – бердәнбер славян дәүләте белән тыгыз мөнәсәбәтләрдә яшәгән.

Вакыт үтү белән кешеләр дә, илләр дә үзгәрә. Кайчандыр чиксез көчле һәм мәһабәт Рим дәүләте ярты дөньяны биләп, күрше халыкларны тетрәндереп торган. Аннары яңа мәдәниятқә, христиан диненең яңа юнәлешенә нигез салучы Византия барлыкка килгән һәм русларга да мәҗүсилектән христиан диненә күчәргә ярдәм иткән. Шәркый якта әллә ничә эреле-ваклы дәүләтләр йөзәр еллар яшәп юкка чыкканнар. Рим һәм Византия дәүләтләренең «туе узып, туны тузгач», Византия җирләрендә Төрек империясе мең елдан артык яшәп ала. Хәзерге Италия белән Төркия аларның пыяла ватыклары шикелле ялтыравыклы тарихи калдыклары гына.

Шулай да мондый илләрнең тарихта эзләре бик тирән. Әмма борынгы грекларның фабрикалары, җитештерү ысуллары, җир казып металл җиткерү юллары кайда соң? Алар йә бик нык үзгәрә, йәисә юкка чыга. Ә инде адәм баласының теге яки бу стильдә фикер йөртү ысуллары, дөньяга карашлары, табигать күренешләренә үзенчәлекле бәя бирү методлары, әдәбият һәм сәнгатьнең, рухи дөньяның асылына нигез салу юллары мәңгегә кала. Философ Аристотель, шагыйрь Эсхилларның әсәрләрен һаман да укыйбыз. Халыклар бер-берсеннән өйрәнеп, бер-берсенә ияреп, кыргыйлыктан бердәм көч белән алга, югары мәдәни хыялларга таба бара.

«Мирас ул – буыннан-буынга күчеп килә торган байлык. Матди байлык ул – фани, бетә торган, вакытлы нәрсә, ә рухи байлык, фикер байлыгы, акыл көче белән хасил булган дөньяга караш, кешеләрнең үзара инсафка нигезләнгән мөгамәләсе, гореф-гадәте – бакый, мәңгелек. Мирасның иң кадерлесе – халыкта сакланып килгән азатлык рухы, хөррият хыялы».

Безнең татар халкының да шулай үсеп барган тарихы бар. Ул да, Рим һәм Византия кебек үк булмаса да, дөнья мәдәниятенә үзенең өлешен керткән. Менә шул тарихны без бик тә аз беләбез. Аны өйрәнер өчен галимнәребез дә әлегә бик аз.

Нигә алар аз, нигә җитәрлек түгел?

Бу сорауга ап-ачык бер җавап бар: изелгән халыкларның тарихы язылмый, аларның биләре, ханнары, патшалары турында язарга түгел, сөйләргә дә хаким халык һәм аның җитәкчеләре тарафыннан ирек бирелми. Шуңа күрә дә безнең бабаларыбыз кайсы Киев кнәзе кайсы елда тәхеткә утырган, кайсы рус шәһәре нәрсә җитештергән, кайсы рус патшасы нинди җирләрне үз халкыннан «азат» иткәнне, ягъни яулап алганны беләләр, әмма үзләренең кайдан чыкканлыгы, кайсы бабадан туып кем булганлыгы турында сүз әйтә алмыйлар...

Мирас ул – буыннан-буынга күчеп килә торган байлык. Матди байлык ул – фани, бетә торган, вакытлы нәрсә, ә рухи байлык, фикер байлыгы, акыл көче белән хасил булган дөньяга караш, кешеләрнең үзара инсафка нигезләнгән мөгамәләсе, гореф-гадәте – бакый, мәңгелек. Мирасның иң кадерлесе – халыкта сакланып килгән азатлык рухы, хөррият хыялы.

Андый мирас аерым шәхестә булмаса да, бербөтен халыкның гомуми җанына сеңеп кала, аның телендә, әдәбиятында, иҗатында, әдәп-тәртибендә, гореф-гадәтендә, фикерләү сәләтендә, буыннан-буынга күчеп килгән риваятьләрендә саклана. Азатлыкка, читлектәге кош кебек канат кагып иреккә чыгарга омтылу – татарларга ата-бабадан калган мирас ул. Һәртөрле золымга булган күңел каршылыгы ачы сүзләр булып бүген мәйданнардан күккә күтәрелә... Бай мирасыбызны өйрәнеп, үстереп киләчәк буыннарга түкми-чәчмичә генә тапшырасы иде. «Мирас» журналы нәкъ менә халкыбызның тарихи, рухи байлыгын саклап калу, аны халыкка яңадан кайтару өчен кирәк.

Әбрар КӘРИМУЛЛИН,
академик:

– Кемгә-кемгә, безнең татар халкы өчен бу журналның чыга башлавы аерата кадерле һәм кирәк. Кыска вакыт эчендә телебезнең графикасын ике тапкыр көчләп алыштыру аркасында, безнең бай мәдәни, фәнни, әдәби мирасыбызны халыктан аердылар. Мирасыннан аерылган халыкның киләчәге шикле. Әдәби мирас ул – халыкның рухы, җаны, дөньяны тану формасы, үткән гасырларның тәҗрибәсе, табышы һәм ачышлары, киңәш һәм уйланулары, уй һәм фикерләре, хыял һәм теләкләре, киләчәк буыннарга васыяте. Рухи мирасыннан аерылган халык – чиксез далада адашкан, кыйбласыз халык ул. Без моның нәрсәгә китергәнен совет чорында күрдек инде.

«Мирас» дигән журнал менә шул халык хәтерен кире кайтару өчен оештырылган, дип уйлыйм. Әлбәттә, күләме белән 100 биттән генә торган бу журнал әдәби, мәдәни, фәнни, рухи мирасыбыз әсәрләрен укучыга җиткерсен өчен берничә гасыр кирәк булачак. Менә шуннан чыгып, мин бу журнал үзенең эшчәнлеген, иң беренче чиратта, халкыбызның күңеленнән төшеп калуга барып җиткән, яшь һәм урта буын өчен бөтенләй билгеле булмаган әдәби җәүһәрләрдән иң асылларын басудан башларга тиеш, дип саныйм.

Мин журнал битләрендә, беренче чиратта, түбәндәге материалларны күрергә теләр идем:

1. Революциягә кадәр яшәгән һәм иҗат иткән әдип, галим, мәгърифәтчеләр, милли азатлык өчен көрәшүчеләр, күренекле татар педагоглары турында хезмәтләр һәм аларның аерым хезмәтләре. Теге яки бу зыялы турында язганда, аның тормышы һәм

иҗатын яктырту белән бергә, барлык әсәрләренең библиографиясен һәм аның турында чыккан әдәбиятны бирүне әһәмиятле, дип саныйм.

2. Аерым чорларда теге яки бу темаларга басылган китапларның исемлеген биреп бару әһәмиятле булачак. Әйтик, XIX йөзнең беренче яртысында нинди «кыйсса» китаплары, нинди «матур әдәбият әсәрләре», нинди «уку китаплары» чыккан. Бу материаллар фәнни обзор белән бирелсә, яхшы булыр иде.

3. Революциягә кадәр чыккан аерым татар газета һәм журналлары, аларның юнәлеше, тоткан юлы, авторлары, халык мәдәниятенә керткән өлеше турындагы мәкаләләр.

4. Патша һәм совет цензурасы тегермәне аркылы үтә алмаган һәм шул тегермәннәр аркылы үтү аркасында, «аксак» чыккан әсәрләрнең тулы яңа басмалары.

5. Дөнья күрми калган, өлешчә китапханә һәм аерым кешеләр кулларында саклана торган кулъязма китапларга фәнни күзәтүләр.

6. БДБ һәм чит ил китапханәләрендә сакланучы татар китаплары һәм кулъязма китаплар турында күзәтүләр.

7. Татар археографларының эшчәнлеген чагылдыру, алар турында тематик бүлекләр.

8. Татар халкының язмышы, тарихы, әдәбияты буенча чит ил галимнәре язган хезмәтләргә күзәтүләр.

9. Әдәби, фәнни мирас басма китаптан башка яши алмаган. Шуңа күрә журналда татар китабы наширләре, типографлары, китап белгечләре турындагы хезмәтләргә дә урын бирелергә тиеш.

10. Элек СССР дип аталган илдә татар халкының үткәне, гореф-гадәте, әдәбияты, сәнгате турында кара ягып чыккан хезмәтләргә эзлекле рәвештә

«Мирасыннан аерылган халыкның киләчәге шикле. Әдәби мирас ул – халыкның рухы, җаны, дөньяны тану формасы, үткән гасырларның тәҗрибәсе, табышы һәм ачышлары, киңәш һәм уйланулары, уй һәм фикерләре, хыял һәм теләкләре, киләчәк буыннарга васыяте. Рухи мирасыннан аерылган халык – чиксез далада адашкан, кыйблασыз халык ул. Без моның нәрсәгә китергәнен совет чорында күрдек инде».

анализ, тиешле бәя биреп тору шулай ук гамәлгә кертелергә тиеш.

Кыскасы, күптән көтелгән бу журналны мин халкыбызның милли аңын, тарихи хәтерен, рухи хәзинәләрен торгызучы орган булыр, дип өметләнәм.

«Мирас» № 2, 1992 ел.
Баш мөхәррир – Флүн Мусин. ■

Ишмөхәммәт хаҗи кыйссасы

Гали Гатауллин

Октябрь революциясеннән соң коммунистлар мәчет һәм мәдрәсәләрне җимерә, яба башлый, милли китапларны өеп яндыралар, зыялыларны, үз фикере булган галимнәрне милләтче, халык дошманы дип сөргенгә сөрәләр. Дин әһелләре дә аяныч язмышка дучар ителә, аларның күбесе репрессия корбаны була. Коммунистлар динне бетерергә, буыннар бәйләнешен өзәргә, Исламга хезмәт иткән шәхесләрнең исем шәрифләрен халык хәтереннән җуеп ташларга тырышалар. Исеме тарих төпкелендә калдырылып, онытылуга дучар ителгәннәр арасында Ишмөхәммәт Заитов та бар. Заманында Ишмөхәммәт Заит (Заһит) улы Идел-Урал төбәгендә, Ислам дөньясында киң танылу алган күренекле һәм абруйлы шәхес булган. Аның бөек мәгърифәтче Шиһабетдин Мәрҗанидән югары бәя алуы, Ислам гыйлеме галиме, мөфти Ризаэддин Фәхреддиннең Ишмөхәммәт хаҗиның дини эшчәнлеген җентекләп тикшерүе һәм өйрәнүе генә дә күп нәрсә турында сөйли.

Ишмөхәммәт 1750 елда Оренбург губернасы Бәләбәй өязенең Күбәк авылында (бүгенге Башкортстанның Бүздәк районы) туган. Шиһабетдин Мәрҗани «Мөстәфадел-әхбар фи әхвәли Казан вә Болгар» (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланган хәбәрләр) исемле әсәрендә тарихи вакыйгаларда нинди дә булса роль уйнаган тирән белемле руханилар турында язганда китабының икенче томында Ишмөхәммәт Заитовка да аерым туктала һәм аның шәҗәрәсен дә китерә: *«Ишмөхәммәд бине Заид бине Бикмөхәммәд бине Әлмөхәммәд бине Алуш бине Урманчы бине Чытырман бине Аяз бине Бишмәт әл-Кибәки».*

«Биредә Ишмөхәммәднең унбер бабасы телгә алына. Аларның сигезе, ягъ-

ни: Бишмәт, Аяз, Чытырман, Урманчы, Кызылбай, Колаш, Кулыш һәм Алуш – саф төрки исемнәр, ә инде Әлмөхәммәд, Бикмөхәммәд, Ишмөхәммәд исемнәре – төрки катыш гарәп, Заһид исә – саф гарәп исеме. Димәк, Ишмөхәммәднең әтисенең бабасы яшәгән чорда гына бу нәселдә (Ишмөхәммәд үзе 1750 елда туа, ата-бабаларына һәркайсына уртача 30ар ел чигергәндә, 1650 еллар тирәсендә) гарәп исемнәре кушыла башлаган. Ә аңарчы кушылган исемнәр буенча бу нәсел кешеләре яшәгән урыннарда урманлык-чытырманлык булган, дип фараз кылырга мөмкин. Чөнки төрки халыкларда да, Көнчыгыштагы башка халыклардагы кебек үк, җир-су, күк йөзе, табигать күренешләренә бәйле исемнәр киң таралган булган һәм ул традиция XVII-XVIII гасырларгача сакланган». (Мөстәфаделәхбар... Баш сүз. Я.Г.Абдуллин, Ә.Н.Хәйруллин. – Казан, 1989)

Шиһабетдин Мәрҗани язмасындагы «әл-Кибәки» сүзе Ишмөхәммәтнең акбабасы Бишмәтнең туган төбәген – Кибәкне күрсәтә. Кибәк авылы бүген Татарстанның Питрәч районына карый. Чал тарихлы әлеге авыл Казан ханлыгы чорыннан ук билгеле.

Мәгърифәтче, галим, дин белгече Ризаэддин Фәхреддин дә үзенең «Асар» исемле хезмәтендә Ишмөхәммәт хаҗиның дини эшчәнлеген ихтирам белән искә ала, аның тирән белемле дин белгече, галим, мөдәррис һәм мөгаллим икәнлеген раслый.

Р.Фәхреддин Ишмөхәммәт Заитовның тормыш юлын, дини эшчәнлеген өйрәнгәндә Кубәк авылына да килә. *«Бу шәҗәрә, нәсел-нәсәбенең кулында булган берничә нөсхәсеннән күчереп бу җирдә язылды*, – дип күрсәтә ул «Асар»да. – *Бәләбәй өязендә Кубәк авылында имам вә мөдәррис булып, 100 яшендә, 1256 елның зөлхиҗәсендә (1841 ел) вафат булган. Кабере өстендә булган ташы югалганга, яңадан икенче таш куелып, болай язылган: «Хаҗи, ахун Ишмөхәммәд Заидов, вафат булды 95 яшендә (Кәмәрия (Ай) ел хисабы белән 100 яшь ахыры була), 1 февраль, 1841 елда, яздым мин Габдеп латыйф Ишмөхәммәд угылы 1870 ел 3 сентябрьдә».*

«Ишмөхәммәд хәзрәтләре яшь вакытында укый-яза белгәннәрдән булмый, – дип дәвам итә Р.Фәхреддин. – *Авылдагы гади халык балалары илә берлектә вакытында эшләп, вакытында рәхәт чигеп, көн уздыра торган булган. Җырларга маһирлыгы сәбәбеннән, һәртөрле мәҗлесләргә чакырылып, төрле кешеләрнең кәефләрен күтәрә торган булган. Кыска вакыт эчендә скрипка уйнарга өйрәнеп, үзе кебекләр арасында кызыгырлык бу ике һөнәрне бергә туплаган. Шушы хәлендә яшәгәндә өйләнгән вә 22 яшендә, көннәрнең берендә, авылдан югалган».*

Нигә Ишмөхәммәт, һич көтмәгәндә, беркемгә берни әйтми, туган авылы Кубәктән чыгып киткән? Ни кергән аның җырга, моңга бай күңеленә? Ишмөхәммәтнең һич көтелмәгән әлеге адымы сәер бер хәл була. Кубәк, пошаманга төшеп, шым кала – егетнең моңы авыл өстенә сирпелми, скрипка кыллары күңелләрне сызмый инде хәзер.

Р.Фәхреддин: *«Биография – кешенең тормыш юлын яктырту ул. Ләкин шул ук вакытта һәр шәхси биография тарихыбызның бер бите булып тора»,* – дип әйткән. Шушы фикергә нигезләнеп, Ишмөхәммәтне авылдан чыгып китәргә этәргән алшартларны аңлау, ачыклау өчен, соңыннан аның күренекле шәхескә әверелеп китүенә булышлык иткән Русиядәге тарихи-сәяси мохитне искә төшерик.

***

Ислам дине мөселман халкында иң дәрәҗәле урын биләгән, ә 1552 елда Иван Грозный Казанны яулап алгач, мөселманнар күргән золымлыкларның иге-чиге булмый: бөтен җирдә суештерeш, канга батырыш өстенә дингә каршы да сугыш игълан ителә: мәчет, мәдрәсәләр җимерелеп, алар урынына

чиркәү һәм монастырьлар салына, Изге Коръән, башка дини китаплар өеп яндырыла.

Явыз Иван явы кылган вәхшилек турында халкыбызның бөек шәхесе Әхмәт Зәки Вәлиди түбәндәге сүзләрне язып калдырды: *«Иван IV динсез дип фикер йөрткән мөселман ханнарының каберләрен туздырып, сөякләрен алып ташлатты. Мөселманнарның, казанлыларның үз диненә каршы дип тапкан гыйльми әсәрләрен, китапларын, язуларын – берсен дә сәламәт көйгә алып калмады. Ул заманда белем җәһәтеннән бик түбән урында торган рус гаскәре, динсез дип уйланган казанлыларның әсәрләрен бер дә кызганмады. Шулай итеп, Иван Грозныйның дини фанатизмы тәэсирендә безгә тарихыбызны, үткәннәребезне күрсәтерлек бернәрсә дә сәламәт калмады»*. (Р.Фәхретдин. – Казан ханнары. Казан, 1995. 174-175 б.)

Казан ханлыгында тарихның кара битләре язылган дәвердә үз диненнән, иманыннан ваз кичәргә теләмәгән Ишмөхәммәтнең борынгы бабалары, туган төбәкләре Кибәкне калдырып, башкорт ягына күченәләр һәм Күбәк авылында тамыр җибәрәләр. Ишмөхәммәт Заитов рәсми язмаларда, «башкорт, типтәр даирәсеннән», дип искә алына.

1740 елда чукындыру конторасы оештырыла, ләкин әлеге сәясәт көткән нәтиҗәләрне бирми, моңа каршы халыкның ачуы гына кабарып, күп урыннарда дин байрагы астында баш күтәрүләр дә булып тора.

Вакыт үтү белән патша хөкүмәте бу сәясәтеннән чигенергә һәм мөселман руханилары белән уртак тел табу юлларын эзләргә мәҗбүр була.

1762 елда Рәсәй тәхетенә Софья Фредерика Августа – Екатерина II утыргач, мөселманнар тормышында азмы-күпме уңай үзгәрешләр күзәтелә башлый:1764 елда чукындыру конторалары ябыла, дәүләт мөселманнарның дини оешмалары эшенә катышмый башлый.

1767 елның яз, җәй айларында Екатерина II Идел буйлап сәяхәткә чыга һәм Болгарда, Казанда була.

Патшабикәнең рөхсәте белән, 1771 елда Казанда Апанай мәчете ачыла. Екатерина IIнең 1773 елның 17 июнендә игълан ителгән указы нигезендә Рәсәй империясендә яшәгән халыкларның үз дини йолаларын үтәүләренә архиерейларның катышуларына чик куела, анда, һәр халык үз динен тотарга ирекле, Алла җирдәге бөтен динне дә кабул итә, дип әйтелә.

Екатерина II хакимлек иткән чорда дин тотучы мөселманнарга бирелгән мөмкинлекләр Ишмөхәммәткә ныклы карарга килергә булышлык иткәндер дә инде – күңеле белән Исламга тартылган Ишмөхәммәт Исламның бер баганасы булган хаҗ кылу сәфәренә җәяүләп чыгып китә.

***

Ул чорда хаҗ сәфәре җиңелдән бирелми, хәтта берничә елга сузылган ул, булачак хаҗиларга төрле куркынычлар да янаган.

Ишмөхәммәт, күп михнәтләр кичереп, Сәмәрканд, Бохара аркылы Әфганстанга барып җитә. Кабул, Пешавар һәм Бомбейны үткәч, Кызыл диңгезне пароходта кичеп, Җиддә шәһәренә килә. Монда хаҗга баручыларны «әмир әл-хаҗ» – махсус юл күрсәтүчеләр көтеп торган. Алар җитәкчелегендә хаҗ кылучылар, кәрвән белән Мәккәгә юл тоталар һәм ун сәгатьтән соң килеп җитеп, ялга тукталалар. Ялдан соң кәрван Мәдинәгә юл тота. Изге җиргә кадәр янә дә ун көнләп барырга кирәк булган.

Чүлдә ком бураны котырган чакларда адашып та йөриләр алар. Авырлыкларны күтәрә алмыйча һәм төрле йогышлы авырулардан интегеп юлда үлеп калучылар да була...

Мөселманнар өчен Хаҗ кылу гамәле барлыкка килгәннән бирле, аның тәртибе, үтәлеше үзгәрмәгән. Аерма бары тик хаҗга бару ысулларында гына. Элек җәяүләп җиде мең чакрым юл

үтеп, Ишмөхәммәт мөселманнарның Изге җиренә барыпирешсә, бүген инде анда автобусларда, самолетларда очып кына баралар. Булачак хаҗилар өчен бар уңайлыклар да тудырылган. Вәләкин барыбер хаҗ гыйбадәте авыр, мәшәкатьле, әмма әҗер-савабы күп булган гыйбадәт булып кала.

Гомерен ислам диненә хезмәт итүгә багышларга ниятләгән Ишмөхәммәт, хаҗ кылгач, сигез ел Каһирәдә яши һәм мөселман уку йортлары арасында иң күренеклесе булган Әл-Әзһәр мәдрәсәсендә укый.

Әл-Әзһәр мөселман руханилары, шәригать нигезендә эш итүче казыйлар, мәдрәсә мөгаллимнәре әзерләгән. Әлеге мәдрәсәдә гыйлем алган кешенең абруе дин тотучылар арасында ифрат зур була.

Ишмөхәммәт хаҗи мәдрәсәдә укыганда, бик өлгер, җитез акыл йөртүче фикер иясе һәм Коръәнне үзенчә матур итеп көйләп укучы буларак, шөһрәт казана.

Шәкерт чагында Ишмөхәммәт күп вакытын китап күчереп язуга багышлый. Аның каллиграфиясе бик матур булганлыктан, күчергән китапларына да сорау зур була. Ул күп акыл ияләренең, тарихчыларның хезмәтләре белән таныша, аларны өйрәнә. Гарәпчә, фарсыча һәм төрекчә иркен сөйләшә башлый.

Ишмөхәммәт хаҗи туган якларына үзе күчереп язган, моңа кадәр сирәк очраган «Әл-миркате шәрхел-мишкят» китабын алып кайта. Алты кисәктән торган әлеге китапны мөфти Шаһингәрәй улы Сәлимгәрәй Тәвкилев сатып ала һәм файдаланыр өчен Килем авылы мәдрәсәсенә бирә.

1897 елның 12 маенда булган янгында әлеге китап янып юкка чыга.

Ишмөхәммәт хаҗи үзе кулланган «Фәтавый» китабы Уфа Диния нәзарәтендә саклнган. Әлеге китапның бер битенә, Ишмөхәммәтнең үз кулы белән: *«1823 елның 13 гыйнварында казага калган намазларымны янәдән каза кылырга башладым, мин фәкыйрь хаҗи Мөхәммәд, гәрчә сәфәр йөргәндә үтәгән булсам да»*, – дип язылган.

***

Хиҗазда кайсыбер шәехләргә ышаныч китереп, суфыйлыкта рөхсәте булса да, Ишмөхәммәтнең мөрид (рухани җитәкчесенең әзеннән баручы) тәрбияләүгә теләге булмый һәм ул, Әл-Әзһәр мәдрәсәсен тәмамлагач, Бохарадагы Күгелдаш, Сәмәркандтагы Хуҗа Әхрар мәдрәсәләрендә шәкертләрне Коръән уку серләренә төшендерә.1783 елда Казан шәһәренең беренче мәчете каршындагы мәдрәсәдә укучыларга сабак бирә. Әлеге мәчет Екатерина IIнең махсус указы белән салына, ул Казан шәһәренең тарихына, халык язмышына аерылгысыз рәвештә бәйле, ул үзендә бик борынгы хатирәләрне саклый. Әлеге мәдрәсәдә эшләгән чорында Ишмөхәммәт хаҗи Коръәнне матур итеп көйләп яттан укуы, матур язуы һәм тирән гыйлеме белән зур абруй казана.

«Коръән уку гыйлемендә остаз булган кебек, тавышы чиктән тыш гүзәл, башкаруы дөрес, язуы тиңдәшсез яхшы булганга, бу мәмләкәт олуглары хозурында мәртәбәсе югары булган», – дип яза Ризаэддин Фәхреддин «Асар» хезмәтендә.

Бу мәчеттә соңыннан, 1849-1889 елларда, имам булып Шиһабетдин Мәрҗани хезмәт итә. Әлеге көндә Казандагы ул мәчет «Мәрҗани» исемен йөртә.

Ишмөхәммәт хаҗи, Казан шәһәренең байлар мәхәлләсендәге мәчет (бүген – Апанай мәчете) каршындагы мәдрәсәдә укытканнан соң, акбабаларының туган төбәге Кибәк авылы мәдрәсәсендә шәкертләрне Коръәнне дөрес һәм матур итеп көйләп укырга өйрәтә.

Кибәктән Ишмөхәммәт хаҗи, мәдрәсә җитәкчесе Габделгалләм хәзрәтнең чакыруы буенча, Иж-Бубый авылы мәдрәсәсенә (бүгенге көндә Татарстанның Әгерҗе районына карый) эшкә килә. Ул заманда Вятка губернасының Сарапул өязе составындагы Иж-Бубый авылында ачылган мәктәп соңыннан мәдрәсә итеп

Казан шәһәренең беренче мәчете (бүген – Мәрҗани мәчете)

Казан шәһәренең байлар мәхәлләсендәге мәчет (бүген – Апанай мәчете).

«Виды Казани, рисованные с натуры» альбомыннан алынды. Э.Турнерелли рәсеме. 1839 ел

үзгәртелә. Вакыт үтү белән әлеге уку йорты мөселман мәгърифәтчелегендә бик кирәкле үзәккә әверелә. Белемгә омтылган яшь егетләр, Русиядән генә түгел, Польшадан, Литвадан, Себердән, Төркестаннан бәләкәй генә авылдагы шушы мәдрәсәгә укырга киләләр. Уку 12 ел дәвам иткән. Программага алгебра, геометрия, тригонометрия, физика, биология, Русия һәм Шәрык тарихы, география, француз, рус, төрек, гарәп телләре кергән. Коръәнне өйрәнүгә, аны дөрес һәм матур итеп укуга аеруча нык игътибар бирелә.

Габделгалләм хәзрәтнең өлкән улы Габдулла Буби, атасының мәдрәсәсен тәмамлагач, аңа ярдәмче мулла булып урнаша. Ул мөселман гыйлемендәге яңа юнәлеш белән мавыга һәм үзе дә китаплар яза. Аның язуы буенча, мәдрәсә тарихында Коръәнне Ишмөхәммәт хаҗи кебек матур һәм дөрес итеп укыган, аны шәкертләр күңеленә үтеп керерлек итеп аңлаткан, искиткеч матур каллиграфияле мөгаллим моңа кадәр булмаган.

Шиһабетдин Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар фи әхвәли Казан вә Болгар» әсәреннән өзек китерү урынлы булыр. Анда Ишмөхәммәт мөгаллимнең эшчәнлеге бәян ителә: *«Таһир хәзрәт. Тумышы белән Сембер өлкәсе Кормыш өязенең Бәтракс карьясеннән. Казан иленә килгәч, башта Мәчкәрәдә мелла Мөхәммәдрәхим ахун мәдрәсәсендә белем ала, Саба карьясендә мелла Габдерәшид бине Габделкадыйр хозурында да укый. Ахырда Ишмөхәммәд бине әл Кибәкидән Коръәнне яттан уку гыйлемен ала һәм*

Әл-Әзһәр мәдрәсә-мәчет ансамбленнән бер күренеш

аның фатихасы белән Малмыж өязенең Адай карьясендә имам хатыйп була һәм Коръәнне дөрес һәм күрмичә уку дәресләре бирә. Озак гомер сөреп, күбәүләргә остаз булды.

Гадәттән тыш матур тавышлы, киң күкрәкле, озын буйлы кеше иде. Һәртөрле мәкамнәр белән укытты. Кайберсен хәрәмин көе, кайберсен коддыс көе дип атап, үзе дә төрле көйләр чыгара һәм шул көйләр белән укый иде. Әлеге көйләрдән максат – җыр-музыка калыбына салу һәм шәригатькә сыймаган көйләү түгел, ә матур тавыш белән җиренә җиткереп уку иде. Үзе Ишмөхәммәд хаҗиның шәкерте булса да, ә соңгысының укуы яхшы һәм тавышы матур булса да, мелла Таһирның өстенлеге һәм осталыгы ачык иде. Үзем аның шәкерте булмасам да, укуына гаять сокланучылардан һәм дә бик тә яратып тыңлаучылардан идем. Үзе: «Башлангыч кыйраәтне Мәчкәрәдә Мөхәммәдрәхим ахуннан алдым. Соңыннан Ишмөхәммәд хаҗидан укыдым, ә ахырда Багдади хаҗидан гыйлем эстәдем. Хаҗи Багдади минем укуымны хуш күреп укыта иде», – дип сөйли иде. Ләкин биргән иҗазәтнамәләрен фәкать Ишмөхәммәд хаҗига бәйләп яза иде, – дип бәян итә Шиһабетдин Мәрҗани. – *Ишмөхәммәднең шәкертләре: Таһир бине Сөбхан әл-Адайи, Габделлатыйф бине Сөбхан әл-Кыйрчый, Хәбибулла бине Габделваһаб әл-Чакмагышый, Таҗетдин бине Габдрәшид әл-Иштирәки, Тавабил бине Сабак әл-Йөгәмеши, Нурмөхәммәд бине Ибраһим әл-Казаный һ.б».*

Ахыры бар ■

Әсәр филология фәннәре докторы, профессор РИФКАТЬ ӘХМӘТҖАНОВның шигъри тәрҗемәсендә бирелә.

КУТАДГУ БИЛИК

(Котайткыч белем)

Йосыф Баласагуни (Йосыф Хасс-Хаҗиб)

Атаң үлде мәгәр, әйтте үгет-фал,
Шуны тотсаң, шикәр көнең булыр бал.

Бу бапта бардыр бик шәп шундый бер сүз
(Ул сүз, аңлый белсәң, күңелеңә күз):

«Атаң нинди чорда үлгән булса да,
Шуны әйткән: – Углым, юньле булсана!

Китәм инде, каладыр сиңа чират,
Тырыш, затыбызның данын тулылат».

Атаңның-анаңның үлеме үзе
Угыл-кызга гыйбрәт, тыңла бу сүзне.

Эләктерде үлем атаң-анаңны,
Сине генә кемдер йолып каламы?

Алар да күп күрде дөнья җәфасын,
Аңа каршы син ни кыла аласың?

Гомерең аз дип бел – кирәклене кыл,
Кешегә хәер бир, гөнаһтан тыел.

Кичәр көн эчендә иң кирәген ал,
Һәм иң кирәк эшне генә эшләп кал.

Җыелган ач бүре хәзер янында,
Куйларың, илеңне сакла, хөкемдар.

Күтәрдең шулкадәр син бу илеңне,
Азакта егылма – иплә йөр инде.

Илеңдә бер кемсә калса кичен ач,
Җавап алыр синнән Алла, күзең ач!

Бүген син янасың – зур шәмгә тиңсең,
Тик нурың ятларга төшә бит синең.

Тереклегең үчеп[1], яшең җиткәндә
Ни файда китерер сиңа ул бәндә[2]?

Үзеңне утка атма ят өчен син,
Үзеңне көйдермә, кысып тешеңне.

Олуглык, бөеклек, бу бийлек – ханлык
Калыр, үлем килеп ачса капкаңны.

Туры бул, тугры бул, гадел түрә бул,
Гаделлек исеме сакта торыр гел.

Ни изге сүз әйткән борынгы белкә –
Идарә ит шуны куеп гамәлгә:

Хакимлек нигезен ныгытып тор,
Гаделлек коралын – канунны нык тот».

Теге дөнья гамен күрсәң, иң элек,
Шул ук бер сүз әйтәм тагы: гаделлек.

Күкрәгең киерсәң «мин бәкмен» диеп,
Яныңа киләдер үлемең көлеп.

Бу дөньялыкка син күңел баглама:
Кыланышы кылтык, өмет юк аңа!

Үземнеке дигән урын – урда, ул
Сиңа кунакханә, шуның утавы[3].

Гомерең аз дип бел һәм кирәкне кыл,
Кешегә хәер бир, гөнаһтан тыел.

* Дәвамы. 2013 елның 10 нчы санында басылып килә.
[1] Үчү – сүнү. Оригиналда шулай һәм татар сөйләшләрендә дә бар.
[2] Нинди бәндәгә ишарә – аңлашылмый.

Синнән элек күпләр кунып киттеләр,
Уянмыйча, шунда йоклап, күчтеләр.

Сиңа тиде инде бу урда-урын,
Күчеңне озат син үзеңнән борын.

Бүген монда төзмә карши[4]-сәрайлар:
Бик үк күп калмаган сиңа еллар-айлар,

Үзең ятыр урын, шаять, билгеле,
Шуны бизәт, гүя, борынгы көлек.[5]

Үземнеке, дисең бу сәрай бүген,
Дөресен әйткәндә, ул алай түгел.

Ишет, нәрсә әйтә бер урда ире
(Дөрес – чынны әйтә ул, баһадирым):

«Мине минеке, дип әйтәсең, менә
Нигә син алай дип әйтәсең, нигә?
Синең варисларың күңелләреннән
Сиңа: – Кит, кит, – диләр, – бу калсын миңа».

Бу дөнья бер зиндан, и, җиһангирем,
Һәм анда һични юк, сагыштан кире.

Сөенче тапмассың зиндан-төнәктә,
Сөенеч-юаныч бары җәннәттә.

Бу бозгын ләззәтне ләззәт, димә син,
Белеп тор бик тиздән үтеп китәсен.

Кайчан кулыңнан ил-дәүләт алынса,
Шундук чәчеләчәк җыйган малың да.

Теге дөньяң – мәңге яшәрлек урын,
Бу дөньяны куеп, тик шуңа борыл.

Теләк, кот, ләззәтең мәңгелек булсын,
Бу мәңгелек өчен михнәт – эш кыл син.

Ходай фазыйләтен уйлап карасаң,
Ничәмә изгелек кылды, назар сал.

**Кайчан кулыңнан ил-дәүләт алынса,
Шундук чәчеләчәк җыйган малың да.**

Бу халык өстеннән бирде хакимлек,
Сүзең, боерыгың – йөрде хөкемең.

Синнән ким булмаган Тәңре колларын
Сиңа баглы кылды, күрәсең, барын.
Моңа шөкер итү кирәк, илбигем,
Тәңре колларыңа яхшы бул, иплем.

Тугрылыкка сине Тәңре күндерде,
Тугры бул, тугрылык өчен тор инде.

Акыл илә эшлә барча эшеңне,
Бастыр хафалану, минлек хисеңне.

Рәхим-шәфкатьле бул барча кешегә,
Гадел бул олыга һәм дә кечегә.

---

[3] Утау — «бизәүле тирмә, зөффаф бүлмәсе; кунакханә номеры».
[4] Карши – Кремль.
[5] Көлек — «борынгы төрки сәргаскәр». Монда сүз балбаллар куюю турында түгелме икән?

Саранланма – илгә мал өләш, ашат,
Саран бийләр бөлер, алыр яманат.

Ни дигән бер инсан – белеме диңгез:
«Белем илә эшлә, кызармасын йөз».

Иге булсын, дисәң, әгәр улусың,
Үзен иге бул син, илдә олысың.

«Бар болганчыкларны сөзим», – дисеңме,
Үзеңне сөз тәүдә, аннан соң – илне.

Бийләр, бәкләр илдә кай якка барса,
Шуларга иярер шул якка барча.

Һәм халык бозылса, бийләр төзәтер,
Әмма бий кәкрәйсә, кемнәр сүз әйтер?

Төзәт үз холкыңны, кылмышларыңны,
Шуннан ил төзәлер, тынычланырсың.

Максат үсеш бирмәк булса эшеңә,
Начар эштән үрнәк алма һич кенә.

Наданга катылма, фәсәттән саклан,
Караер йөзең шул ике холыктан.

Явызлыкны үзең үз итмә һич тә,
Яраксыз эш кылма – кисәтеп әйтәм.

Шәһвәткә кол булма һәм дә эчкегә,
Бу ике – ташкын су һәм юк кичүе.

Холкың туры булсын, кыланышың да,
Белем белән киңәш, булсын ушың да.

Күңел-телең булсын ирдәмле, олы,
Үзеңне онытып, югалтма юлны.

Көязләнмә, борын күтәрә күрмә,
Гаскәрем күп, дип үк күкрәкне кирмә.

Ничә горур, батыр, көяз кешене
Үлем җиргә күмде, туфрак ишерде.

Ничек шәп әйткән бер белекле кеше
(Белекленең сүзен тоту килешер):

«Хәзинәм ишле, дип, малга куанма,
Гаскәрем көчле, дип зурдан кыланма.

Көченә масаеп күкрәк киергән
Бирәлми бер әмер хәтта чебенгә».

Пошынсаң, тик йөрмә – эшеңә йомыл,
Үпкәләсәң, тагы уйлан да, шым бул.

Ашыгып эшләмә (мәгәр дин эшен
Калдырма). Уңмый ул ашыккан кеше.

Шулай да хөкемне чыгар тиз генә,
Әмма ярсынмыйча җиткер җиренә.

Эшеңдә һәм сүзеңдә килмә тыр-пыр,
Асылзатлар сабырланган сабырдыр.

Саранланма – илгә мал өләш, ашат,
Саран бийләр бөлер, алыр яманат.

Бик иркен сөйләнмә, нык тот үзеңне,
Тупас сүз суыта һәргиз күңелне.

Сөчек сүз әйтсәң дә телең сынмастыр,
Ачык йөзең белән ил күңлен яктырт.

Илдә сайланмышсың, холык, юрыгың
Исемеңә лаек булсын – саф, тугры.

Кара халык иге булса, игелек
Аның тик үзенә була, ил биге:

Әмма илбик иге булса кылыкта,
Сөенече бөтен илдә, халыкта.

Илбикнең уе сай, кылмышы исәр
Икән, акыл бетәр, исәрлек үсәр.
Исәр булма – исәр атың җәелер,
Исәрләрне кысар булсаң, хәерле.

Исәрлек агуын эчкән кеше кем?
Шул инде сүндерә яшәү тибешен.

Кем акыллы булса, тот шуны якын,
Сүзен тыңла, хөрмәт ит, хакла хакын.

Бөтен чын һәм изге атлы затларны
Җаваплы эшләргә куеп шатландыр.

Бу алдакчы дөнья юлсыз, кичүсез:
Сакланып бармасаң, батарсың бик тиз.

Бизәнеп, кыланып гашикъ итәр ул,
Күңел бирдең исә качып китәр ул.

Үлемне онытып, батма дөньяга,
Тик гамьсез дә булма илбашы ага.

Гафил булып, илбик, оема бер дә,
Ләкин бийлегеңнән бер дә исермә.

Бүгенге ләззәткә мәз бетмә[6], саклан,
Ахирәт бәхетен телә ки Хактан.

Шатлыгы, ләззәте күптер дөньяның,
Дингә дә яравын кара син аның.

Хәләл шатлык сора, ләззәтен белеп,
Тиенгән нигъмәтең булсын мәңгелек.

Ни ди, ишет, әнә белек белгән ир,
Белем белән илдә мәшһүр булган ир.

«Ходай бүләк итсә, бәхеткә чик юк,
Кабул ит, рәхәтлән, рәхмәтләр укып.

Горурлык соңында хурлык килә. Соң
Ничек ул хурлыкка тәкать тотарсың?»

И, илбик табипка охшаш син бүген,
Чирле халык сиңа сөйли зар-моңын.

Кайсы авырган һәм тайган бар көчтән,
Кайсы фәкыйрьлектән чыгалмый һич тә.

Кайсы ач һәм кайсы ялангач икән,
Кайсы ярдәм көтә – кайгысы бүтән.

Сиңа баглый һәркем имен һәм гамен,
Дәвала, дару бир, бул имче-камы.
Әгәр тапмасаң һәрберенә им-ут,
Халык өчен, гүя, булырсың яу-йот.

[6] Мәз бетү – рәхәт исереклектә булу.
[7] Рәвәнҗан – үлгән кешенең өенә кайтып йөргән җаны, гомумән, бу образ мәҗүсилектән килә.

Агызма кан, һәркемгә булма дошман –
Бу ике гөнаһтан үксер рәванҗан.

Теге дөньяда да сорарлар синнән,
Изге атың булсын җавап бирергә.

Гомер үтә бик тиз, тик ханлыгың бар,
Мөмкинлек бар изге дан калдырырга.

И, илбик, бу дөнья шундый басу-кыр,
Ни чәчсә кемсә, нәкъ шуны урыр, күр.

Чәч изгелек, димәк, һәм изгелектә,
Изге даның калачак мәңгелеккә.

Ни дигән әнә бер ирдәм бәк илче,
Бийлек эшен дә бик белгән белекче:

И, бий, илдә абруй казаныйм, дисәң,
Күңел-телең тыйнак булуын күрсәт.

И, бий, идарәче булыйм, дидеңме,
Һәр эштә алга куй, димәк, белемне.

Ниләр эшләсәң дә, син эшлә белеп,
Шулай гына килер эш күреклеге.

Гомер үтәр – китәр, югалыр эзең,
Истәлеккә калсын изге бер эшең.

Дөнья фани, үлә һәрбер тумыш зат,
Һәрберсеннән кала яхшы-яман ат.

Исәргә катылма, исәр – тиген ул,
Изгеләрдән генә калган иге юл,

И, илбик, тырыш һәм һәрчак уяу бул!
Гафиллекләр җиңүне дә җуя ул.

Идарә нигезе – саклык, уяулык,
Теге дөнья өчен дә нәкъ шулай ук.

Гафил бийнең көче китәр кулыннан,
Һәр ике дөньяда ялкау уылдар.

Агызма кан, һәркемгә булма дошман –
Бу ике гөнаһтан үксер рәванҗан [7].

Дәвамы бар ■

ЧЫҢГЫЗХАННЫҢ АК БОЛЫТЫ

Романга бәян

....

Чыңгыз Айтматов
(1928-2008)

– Асыл достар! (Кадерле дуслар!) – дип башлый подполковник, шул ук вакытта үзенә тулы, җитди игътибар таләп иткән кебек, өстәл тирәли утырганнарны мәһабәт карашы белән капшап чыга. – Үзегез түсенесиздер (төшенәсездер), бүген минем йөрәгем мөлдерәмә – бәхетем диңгез кебек тулышкан. Түсенесиздер. Минем дә бер сүз әйтәсем килә. Бүген минем сәгатем сукты һәм минем сүз әйтәсем килә... – Подполковник тиешенчә каралмаган көзге юлдан баручы иске машина кебек батып калырга чамалый, әмма сер бирми, барыбер сүзен дәвам итә. – Түсенесиздер. Мин һәрвакыт имансыз булдым. Комсомолда үстем. Мин – какшамас большевик. Түсенесиздер. Һәм шуның белән бик горурланам. Алла – минем өчен буш урын. Алланың юклыгы һәркемгә, һәр совет мәктәп баласына билгеле. Ләкин минем бөтенләй башка нәрсә турында әйтәсем килә, түсенесиздер, дөньяда алла бар бит ул! Бер генә минутка сабыр итегез, мыек астыннан көлемсерәргә ашыкмагыз, кадерлеләрем... Кара син аларны! Мине сүземдә тоттык, дип уйлыйсыз бугай. Юк, бер тамчы да ялгышмадым! Түсенесиздер. Мин инкыйлабка кадәр эшче халыкны изеп яшәүчеләр уйлап чыгарган алланы күздә тотмыйм. Безнең алла – гәзитләрдә язылганча, үз ихтыяры белән Җир шарында тулы бер дәверне башлап, адым-адым тормышка ашыра торган һәм безне җиңүләрдән җиңүләргә, коммунизмның дөньякүләм тантанасына алып баручы хакимият иясе; ул даһи җолбасшыбыз, түсенесиздер, кәрван башлыгы иң алдагы дөянең нуктасын тоткан кебек, дәвер өзәңгесен нык кулларына алган, ул безнең Иосиф Виссарионович! Һәм без аның артыннан ияргәнбез, кәрванны ул иъртеп бара, ә без аның артыннан – бер үк сукмактан. Һәм бездән аермалы уйлаучы яки безнеке булмаган идеяләрне күңелендә йөрткән берәү дә безгә тимер Дзержинский васыять итеп калдырган, аяусыз җәзага тартучы чекист кылычыннан качып котыла алмаячак. Түсенесиздер. Дошманнарга без соң чиккәчә көрәш игълан иттек. Аларның нәселе, гаиләсе һәм аларга теләктәшлек белдерүчеләр, пролетариат эше хакына, түсенесиздер, көз көне бер кучкә җыеп утта яндырылган сары яфраклар төсле юк ителәләр. Чөнки идеология бер генә була. Түсенесиздер, бүтән бернинди идеология була алмый. Менә без сезнең белән җирне идеологик дошманнардан – буржуаз милләтчеләрдән һәм шуның ише башка чүп-чардан арындырабыз, түсенесиздер, дошман кайда гына яшеренсә дә, кем булып кына кыланса да, аңа бернинди шәфкать күрсәтү юк. Һәркайда сыйнфый дошманны фаш итәргә, дошман агентурасын ачыкларга, түсенесиздер, иптәш Сталин өйрәткәнчә, дошманны кыйнарга, халыкларның рухын ныгытырга – менә безнең девиз. Бүген, минем хезмәтемне югары бәяләгәндә, вакыты җиткәнче үк яңа дәрәҗә бирү турында боерык укылган чакта, мин алга таба да, һичкая тайпылмыйча, Сталин сызыгыннан барырга, түсенесиздер, дошманны эзләргә, табарга һәм аның җинаятьчел ниятләрен ачарга ант итәм. Түсенесиздер, төп милләтчеләрне

Башы журналның 8 нче санында. Тәрҗемәче – Мөдәррис Вәлиев.

без инде коралсызландырдык, әмма институтларда һәм редакцияләрдә аларга теләктәшлек итүчеләр посып калды әле. Ләкин бер дошман да бездән беркая китә алмас һәм аларга һичнинди рәхим-шәфкать булмаячак. Ничектер, сорау алу вакытында миңа бер милләтче әйтә, түсенесиздер, барыбер, ди, сезнең тарих тар тыкрыкка – тупикка керәчәк, һәм сезгә, мөртәтләргә, иблис ялчыларына, ләгънәт төшәчәк, ди. Түсенесиздер?!

– Андыйларны шул урында ук атып үтерәсе иде! – дип, түзмичә, сүз кыстырды Тансыкбаев һәм хәтта, ярсып, урынынннан ук тора башлады.

– Дөрес, майор, мин дә шулай эшләгән булыр идем, – дип аны хуплаган булды подполковник, – тик әле ул тикшерү эшләре өчен кирәк иде, һәм мин аңа әйттем, түсенесиздер: без тар тыкрыкка кергәнче, син, бәдбәхет, күптән инде бу дөньяда булмассың! Эт өрә, ә Сталин кәрваны алга бара...

Барысы берьюлы шаркылдап көлеп җибәрделәр, теге, тузан бөртегедәй вак милләтчене урынына утырткан зирәк җавапны хуплап, кул чәбәкләделәр, әзер бокалларын сузып, барысы бергә урыннарыннан купты. Бер тын алдылар да: «Сталин өчен!» – дип, һәммәсе дә, әйтелгән сүзләрнең хаклыгын һәм аларга тугрылыклы булуларын раслагандай, бушаган бокалларын бер-берсенә күрсәтеп, дәррәү эчеп куйдылар. Аннары да бу фикерне дәвам итүче тагын күп тостлар әйтелде. Һәм бу сүзләр, яңадан туып, ишәя-ишәя көч алган, агулы һәм күп булуларын тойганлыктан усаллана барган, үзләренә яшертен ачу һәм ярсу туплап, тузгыган кыргый шөпшә күчедәй, монда җыелган кешеләрнең баш очында әле озак әйләнделәр.

Тансыкбаевның күңелендә исә, үзенең фикерләрен кузгатып, аның тәвәккәллеген ныгытып, кайнар дулкыннар бөргәләнә иде һәм бу – әлегедәй сөйләнүләр аның өчен яңа булганлыктан түгел, һич юк, киресенчә, аның бөтен гомере, шулай ук күпсанлы хезмәттәшләренең яшәү рәвеше, аларның күзаллавын чолгап алган җәмгыять тормышы көнмә-көн нәкъ шул өрөзлексез камчылап тору, «сыйнфый» дип аталган һәм шунлыктан бөтен яктан тулысынча аклана торган ярсулы көрәш мохитендә кайный бит... Ләкин монда яшерен бер мәсьәлә бар. Көрәшне даими кыздырып торыр өчен корбаннарның яңадан-яңасы, фаш итүләрнең моңарчы булмаган юнәлешләре кирәк; чөнки күбесе инде чәйнәп төкерелгән: тулы бер халыкларны Себер һәм Урта Азиядәге һәлакәтле сөргенгә озату ише кайбер алымнары балы суыртылган кәрәз кебек бушап калган; шуңа күрә әлеге «оя»лардан яңа уңыш җыеп алу, әйтик, ил читендәге милли төбәкләрне буржуаз-феодаль милләтчелектә җиңел генә гаепләү дә торган саен кыенрак була бара. Ачы тәҗрибә тупланган саен, теге яки бу затка идеологик яктан шик ташлап кечкенә генә яла ягудан да аның үзен харап итүләрен һәм шунда ук якыннарыннан үч алыну ихтималын истә тоткан кешеләр инде хәтәр хаталардан башларын саклыйлар, милләтчелек чагылышы дип талкырга мөмкин булган берни дә сөйләмиләр һәм язмыйлар. Киресенчә, күпләр кирәгеннән артык дәрәҗәдә сак һәм алдын-артын карап эш итә башладылар ки, инде теләсә нинди милли байлыклардан, бөтен кеше ишетерлек-күрерлек итеп, ачыктан-ачык баш тарталар, туган телләреннән йөз чөерүгә кадәр барып җиттеләр. Бар, син аны тотып кара, ул бит бары тик Ленин телендә генә сөйләшкәнен һәм уйлаганын адым саен тукып-тәкрарлап тора...

Һәм нәкъ менә шул, вакыйгаларга ярлыланып киткән, яңа яшерен дошманнарны ачыклау буенча көрәшне алга таба үстерү кыенлашкан бу дәвердә майор Тансыкбаевка, очраклы гына булса ни, барыбер бәхет елмайды бит әле. Беркемгә билгесез диярлек кечкенә Буранлы станциясеннән Әбүталип Куттыбаев өстеннән килгән әләк

– аның кулына әһәмияте белән әллә ни искитәрлек булмаган, җитди тикшерүдән битәр танышып чыгар өчен генә бирелгән бер мәгълүмат кыйпылчыгы иде югыйсә. Әмма Тансыкбаев үзенә тиешлене казып чыгара алмыймы, ә чыгарганнан соң кулыннан ычкындырамыни соң! Сиземләве алдамады. Иренмәде Тансыкбаев, урында ачыклыйм әле, дигән булып, шул якларга барып кайтты һәм инде менә беренче карашка гади генә күренгән эшнең дә, тиешенчә борып җибәрә белсәң, шактый саллы булып китүе мөмкин икәнлегенә көннән-көн ныграк ышана бара. Һәм, димәк ки, бөтенесе дә кирәгенчә, ягъни ул теләгәнчә барып чыкса, өстәгеләрнең бүләкләре, тәгаен, аны да әйләнеп узмас. Бу мәлдә әлеге табын янында, шундый зур тантана шаһиты булып, Алла-Хакимияткә бөтен күңеле белән бирелгән һәм шунлыктан өстәлдәге, түшәмдәге бәллүр ялтыравык-юанычлар эчендә ләззәтләнә торган, үзенә яхшы таныш бу кешеләр арасында тиккә генә утырамыни, мондый эшләрнең ничек әвәләнгәнен белмимени ул?! Әмма да ләкин Алла-Хакимияткә илтүче юл бер генә, ул – йөзләрен битлек астына каплаган дошманнарны ачыклау һәм фаш итүдә, кара тиргә батып, армый-талмый, аңа хезмәт күрсәтү.

Ә дошманнар арасыннан, кем әсирлектә булып кайткан, шуларга бигрәк тә уяу шымчылык итәргә кирәк. Алар – маңгайларына пуля җибәрмәүләре белән үк җинаятьчеләр, чолганышта калсалар да, кулларын күтәрмәскә, үләргә һәм, шуның белән, уңга-сулга тайпылмауны – үлсәң, үл, әмма әсирлеккә төшмә, дип таләп иткән Алла-Хакимияткә чиксез бирелгәнлекне исбатларга тиешләр иде. Кем дә кем әсирлеккә төште, ул – шул ук мизгелдән җинаятьче, һәм моның өчен котылгысыз җәза бирү һәркемгә, бөтен заманнарга, барча буыннарга кисәтү булып хезмәт итәргә тиеш. Юлбашчының – Алла-Хакимиятнең күрсәтмәсе шундый. Тикшерү өчен кулга алынган Куттыбаев исә – нәкъ менә элеккеге хәрби әсирләр сафыннан, шуның өстенә аның эшендә гадәттән тыш мөһим, әле зур хаҗәте чыгасы бер ябышыр төш, бик кирәкле «сөял» беленеп тора; әгәр Куттыбаевтан шул «сөял»не куптарып ала алсаң, әллә ни әһәмиятле факт та булмасын, ди, тик аның, тиешле урынга кагып куелган кечкенә кадак сыман, зур эшне беркетүдә – Сталин хуплавыннан башка гына Югославиянең аерым үсеш юлына дәгъва кылучы Тито -Ранкович ревизионистлар өеренең баштан ук сатлык уй-ниятләрен фаш итүдә кирәге чыгуы бар... Кара син аларны, нәрсә кырмакчы булалар! Әле сугыш кайчан гына бетте, ә алар инде аерылырга маташалар. Барып чыкмас! Сталин бу идеяне, көлгә әйләндереп, җилгә очырыр. Һәм менә шулчакта, бәләкәй генә фактка таянып та, Югославиядәге сатлык ревизионист идеяләренең инде күптән – сугыш елларында ук партизан командирларында туганлыгын һәм Англия махсус коткы тарату хезмәтләренең турыдан-туры йогынтысыннан килеп чыкканлыгын тагын бер мәртәбә исбатлау һич артык булмас иде. Ә Әбүталип Куттыбаев язмаларындагы югослав партизаннарының ничек итеп англичаннар белән очрашуы турындагы истәлекләр... – һәрхәлдә, хәзерге мәлдә аңардан ни сорала – шуны теленнән тартып әйттерү өчен менә дигән нигез бар. Шәт, шулай икән, моңа ничек кенә булса да ирешергә кирәк. Ярылсаң сигезгә ярыл, әмма бу Сарүзәк кәгазь кортыннан бөтен кирәкле сүзне сытып чыгар. Сәясәттә җил искән уңайга оча торган бөтен нәрсә дә ярап куя. Һәр вак-төякнең хаҗәте чыгуы бар, идеяләр бугазга бугаз килгәндә, дошманның башын тишәрлек ташка да әйләнергә мөмкин алар. Шуңа күрә, хәтта чуерташ хәтле генә булса да, аны табып алырга кирәк, тапкач та аны, символик рәвештә, әмма чын йөрәктән Алла-Хакимиятнең үз учына саласың, ул исә әлеге ташны, үзе атмаса, тиешле кешесенә тоттырыр да, гәзитләрдә язылганча, мәче

косыгы кебек җирәнгеч ревизионист Тито һәм аңа тагылган Ранковичның куштан койрыкларына тондырырга әмер бирер. Ә инде бөтенләй эшкә ярамаса, ташың ваграк, дип әйтсәләр, барыбер тырышлык исәпкә алынмый калмас... Күрерсең дә торырсың, бу өстәл тирәсендә утыручыларның һәммәсе әле аңа да килер, менә шулай, бик шәп вакыйганы билгеләп үтәр өчен, аның өендә утырышырлар. Яшәүнең мәгънәсе – бәхеттә, ә бәхетнең башы – уңыштыр!

Әлеге чакырулы кичәдә шоңкар күзле Тансыкбаевның башына менә шундый уйлар килде, һәм, табын янындагы гәпләшү вакытында башкалар белән сүз атышкан булып утырганда да, ул, дәрьяның ургылына чумудан ләззәт алган оста йөзүчегаувас сыман, артканнан-арта баручы дәртле омтылышлары һәм көчле теләкләре дулкынында тирбәлә иде. Ирен яхшы белгән хатыны Айкумис кына аның, төнлә ауга чыккан һәм инде табышының исен сизеп котырынган кыргый җанвардай, ниндидер көчле кичерешләр белән көрәшүен сизде. Ул моны иренең күзләрендә, вакыт-вакыт әле боз кебек каткан, әле кайнар дулкынлану белән эреп алган, керфек тә какмый торган лачын карашында күрде. Шуңа күрә ул аңа: «Моннан бүтәннәр белән бергә чыгабыз да бары тик өйгә генә кайтабыз», – дип пышылдады. Тансыкбаев теләр-теләмәс кенә ым кагып җавап бирде. Кешеләр алдында каршы әйтәсе килмәде, бәлки, әйтергә дә ярагандыр. Аның башында яңа, тагын да колачлырак хәрәкәт планы өлгереп килә иде. Куттыбаев белән бергә югослав партизаннары янында башка күп әсирләр булган бит, алар бүген илнең төрле почмакларында качып утыралар, димәк, алар да нәрсәдер белергә, искә төшерергә мөмкиннәр, Куттыбаевны үз эшләре арасыннан аеруча активларын атарга мәҗбүр итү әллә ни кыен булмастыр. Ни бар мәгълүматны күтәрергә, иртәгә үк тиешле урыннардан соратып мөрәҗәгать итәргә кирәк. Йә инде үзенә мөмкин кадәр тизрәк башкалага барырга, ачыкларга, казып чыгарырга һәм аннары Куттыбаевны кирәкле исемфактларны расларга мәҗбүр итәсе генә булачак. Ә шуннан соң, имештер, аның күрсәтүләренә таянып, Югославиядә сугышкан элеккеге әсирләрне гаепләргә, ул затларны, бер-берсен әләкләмәгәннәре, Советлар Союзына кире кайтару комиссиясен узганда хыянәтчел ниятләрен яшергәннәре өчен яңадан җавапка тартырга кирәк. Мондый төр кешеләр йөз яки мең генә дә булмаска мөмкин, соңыннан бу халыкны лагерьларга куып ябарга һәм шуның белән барысына да нокта куярга! Әлеге шәп идеяне, мөгаен, югарыга яшерен хат рәвешендә җиткерергә туры килер.

Төрле аш-су һәм коньяк рюмкалары тезеп куелган табын янында кинәт кенә башына суккан бу фикердән күңеле күтәрелгәнен сизде Тансыкбаев, аның тагын эчәсе килде, тагын кабымлык йотасы, гомумән, үз-үзеннән канәгатьлек кичереп, тормышында ниндидер яңа борылыш буласын алдан тоеп, җырлыйсы һәм күршеләренең «сакалы белән уйнап», алардан көләсе килде. Янәшәсендә утырганнарны серле ялтырый башлаган күзләренең рәхмәтле карашы белән айкап алды: мондагыларның һәркайсы аңа туганы кебек үз, якын, барысы да бер тавык чебиләре кебек бит һәм шунлыктан бу мәлдә алар белән шундый рәхәт, ә менә ул мәхлуклар аңарда ниндидер бөек идеяләр туу мизгелегендә катнашуларын сизмиләр дә. Боларның һәммәсе Тансыкбаевның болай да кызган башына кайнар кан йөгертә һәм тантана итүче йөрәген шатлыктан шауларга, еш-еш дөпелдәргә мәҗбүр итә иде.

Күңеленә килгән уй-ният аны хезмәт буенча өскә үрмәләүнең шактый чынга ашардай буласына өметләндерә, бу – акылга һәм мантыйкка да муафыйк лабаса: посып торган дошманнарны никадәр ныграк таптасаң, үзең шулхәтле биегрәк үсәсең. Ниятләгәненең уңыш белән төгәлләнәчәге бүгеннән үк күңеленә канат-

лар куя иде, һәм ул, эченнән генә булса да, беркадәр әтәчләнеп уйлады: «Акыллы кешеләр үз эшләрен менә шулай оештыралар! Мин дә, бу күпмегә генә төшсә дә, ярты юлда туктап калмам!» Кичекмәстән хәрәкәт итәсе – хәзер үк гараждан машина чакыртып барасы һәм Әбүталип Куттыбаев утырган, тикшерү изоляторы дип атала торган, тәрәзәләренә рәшәткә кагылган ярымподвалга йөгереп керәсе дә, вакытны әрәмгә уздырмыйча, эшкә тотынасы иде – шунда, камерада ук, сорау алуны башлап җибәрергә һәм шундый итеп куркытырга ки, тегенең җаны эчәкләреннән савылып авызына килсен. Шулай итсәң, эшнең барып чыгуы турында һич тә ике төрле сөйләшеп тору юк: Куттыбаев гаебен таный, англичаннар белән югославлар кушканны үтәргә алынуын раслый, аның белән бергә партизанлыкта булганнарның барчасын да исемләп атый, шуннан соң, 58 нче статьяның 1 нче б пункты белән, 25 ел лагерь мөддәтенә хөкем ителә; әгәр инде гаебен танымаса, ватанга хыянәт иткәне, чит ил махсус службалары белән агентура хезмәттәшлеге урнаштырганы һәм җирле халык арасында идеологик җимерү эшләре алып барганы өчен аны атачаклар. Әйдә, ныклап уйласын.

Тансыкбаев күп кенә нәрсәләрне: сорау алу вакытында сөйләшүнең ни рәвешле барасын, Куттыбаевның ничек үҗәтләнеп каршы торасын һәм аны сындырыр өчен нинди чаралар күрергә туры киләсен дә алдан чамалап тора иде, әмма ул шунысын да белә – тегесе барыбер беркая китә алмас, яшисе килә икән, аның бүтән сайлар юлы юк. Билгеле, аяк терәп акланырга тырышыр, имештер, бернидә дә гаепле түгел, әсирлек хурлыгын, кулына корал тотып, югослав партизаннары белән бергә иңгә-иң торып сугышканда каны белән юды, сугыш беткәч, илгә кайтару комиссиясен узды, сугыштан соң намуслы хезмәт итте һәм башкалар, һәм башкалар, ә бит боларның барысы да – буш сүз. Үзенең мондый сыйфатта түгел, ә бөтенләй башка максатта хаҗәт икәнлеген һәм тиздән, әгәр барысы да Тансыкбаев уйлаганча барып чыкса, дәүләтнең әлегә кайдадыр посып ятучы дошманнарын төбе-тамыры белән корыту эшендә коточкыч бер пәри туенның үзәгендә буласын мәхлук Куттыбаев кайдан белсен инде. Ул бу хәтәр чылбырда үз артыннан бөтенесен тартып-ияртеп китәрлек беренче буын буларак кына кирәк. Дәүләт мәнфәгатьләреннән өстенрәк ни була ала? Кайберәүләр уйлый, кеше тормышы, дип. Диваналар! Дәүләт – бертөрле генә ягулык-утын – кешеләр тормышы белән дөрли торган мич ул. Дәүләт – һәрдаим янып торучы мич! Утын өстәп тормасаң, бу мич сүнә башлаячак һәм аның кирәге дә калмаячак. Әмма шул ук кешеләр үзләре аның авызына керәләр, чөнки дәүләттән башка яши алмыйлар. Ә яндырып торучылар (кочегарлар, ягъни мәсәлән) мичкә утынны берөзлексез өстәп-биреп торырга тиешләр. Дөньясы шуңа корылган.

Мул табын янында хатыны белән янәшә утырганда уйларын аңардан яшерүе кыен кебек тоелса да, Тансыкбаев әңгәмәдәш күршеләренә баш кагып һәм аларның сүзен җөпләп өлгерә, берара партия мәктәбендә укып йөргәндә классик тәгълиматлар турында кайбер нәрсәләр колагына чалынып калганга, боларның һәммәсе уңаеннан үз-үзе белән эченнән фәлсәфә куерта һәм, шым гына, кешенең нинди әкәмәт зат булуы белән хозурлана. Менә, мисал өчен, бу компаниядә, чакырылган кунак булып утыра ул, шушы мизгелләрнең мәгънәсенә баштанаяк һәм тулаем мөкиббән киткән кыяфәт ясый, ә үзе бөтенләй башка нәрсәләр турында уйлый. Йә, кем күз алдына китерә ала: кая төбәлгән бу адәмнең игътибары, башында нинди уй-ниятләр җитлегеп килә?! Тыныч кына өстәл янында утыргач та, әлегә беркемнең дә аның ихтыярына гына бәйле кырып-җимереп бетерерлек, котылгысыз куәте булган нәрсәдер бар икәнлеге хакында, әлеге яшертен уй-

ниятләренең көче гамәлгә аша калса, бәндәләрне – аның алдында, ә аның аша Алла-Хакимиятнең үз алдында да мүкәләп йөрергә мәҗбүр итәчәге турында хәбәре юк һәм бу бәйләнештә Алла-Хакимиятнең котларны алып торган тәхет баскычына таба илтүче күптин-күп, шулай да санаулы адымнар арасында берсе нәкъ менә ул булып торуын аңлау, аңарда, тәмле ризыктан авыз итүне яки шашынып өегешүне алдан тоеп-көтеп зарыккандагы шикелле, җисми ләззәт, хозурлык һәм сабырсызлану хисләрен уята. Чираттагы һәр рюмкадан соң бу әсәрләнү арткан-нан-арта һәм, бөтен тәнен мәмрәтеп, кан тамырлары буйлап тарала, аның барлыгын били, инде бу халәттә тыелып торуы да кыен, уйлаганын тормышка ашырырга иртәгәдән соңга калмый башлаячагын, әле барысына да өлгерәчәген үз-үзенә тукыр өчен аңа шактый көч куярга туры килә.

Алдында торган эшнең аерым кисәкләрен аңында берәмтекләп аралый торгач, Тансыкбаев үз ниятләренең төпле булуыннан, фаразларының мантыйкка тап килүеннән тирән канәгатьлек хисе кичерә. Шулай да нидер җитмәгән кебек бер тойгы калды әле, тагын нәрсәнедер уйлап бетерү таләп ителә, кайсыбер җинаять эзләренең төбенә төшми калынган кебек.

Мисалга, Куттыбаевның маңкорт турындагы язмалары арасында барыбер нидер яшеренеп ята бит. Маңкорт! Зиһене томаланып, анасын үтерүгә барган маңкорт! Әйе, әлбәттә, иске риваять бу, әмма аны язып алган Куттыбаев бер-бер максатны күздә тоткандыр, мөгаен?! Бөтен иген-җиген китереп, тырыша-тырмаша, очраклы рәвештә һәм тиктомалдан гына язып алмаган лабаса ул тарихны. Шулай, маңкорт, маңкорт... Ни яшерелгән монда, әгәр инде читләтеп әйтелгән икән, нәкъ менә нинди фикер соң ул? Һәм иң мөһиме, Куттыбаев маңкорт фәлсәфәсен үзенең коткы тарату максатында файдаланырга җыенган, дисәк, – ничек итеп? Маңкорт турындагы риваятьтә идеологик яктан шикле ни-нәрсәдер барын элемчалым гына сиземли Тансыкбаев, мәгәр әле аны анык кына аңлый да, катгый итеп раслый да алмый, тәгаен фаш итәсенә тулысынча ышанып та җитми. Менә әгәр әлеге риваятьне, мондый очракларда тиеш булганча, халыкка каршы дип атап булса һәм шуның өчен җаваплылыкка тарттыра алсаң иде кана, тик ничек итеп? Бу эшкә Тансыкбаевның теше үтми, ул моны үзе дә белә. Берәр галимгә сүз катып карасаң инде. Менә бүген «юып» утырган вакыйга – буржуаз милләтчеләрне фаш итү дә – шул юл белән уңышка иреште ич: башта нинди дер төркемне казып чыгардылар, аннары бер яктагы белгеч-галимнәрне икенчеләренә каршы өсләттеләр, тегеләре инде үз ишләрен милләтчелектә, Сталинның социализм төзү дәверенә зыян салу максатында үткәннәрне мактауда гаеп ташларга әзер тора иде, һәм, тегермән ташы тәүлекләр буе әйләнә башласын өчен, шул җитә калды... Ә шулай да Куттыбаевның маңкорт тарихын ничек җентекләп язып алуында бер-бер хикмәт яшеренеп ята бит, ята! Аны яңабаштан дикъкать белән, һәр сүзенең төбенә төшеп уку кирәк, әгәр кечтеки генә ябышыр урыны табылса, их, риваять язмасын да эшкә җигәргә, гаепкә бөгәргә, «эш»кә теркәргә мөмкин булачак.

Моннан тыш, Куттыбаев кәгазьләре арасында тагын бер риваятьнең кулъязмасы табылды әле, анысы Чыңгызхан заманнарыннан калган, «Сарүзәктә җәзалап үтерү» дип исемләнгән иде. Тансыкбаев бу борынгы тарихка ни өчендер башта ук игътибар итмәгән икән һәм әле генә шул хакта уйга калды. Исәпләп карасаң, анда бит нинди дер сәяси ишарә күрергә була...

Дәвамы бар ■

Фатих Әмирхан.
1912 ел

ҺӘР ӘСӘРЕ – КАМИЛЛЕК ҮРНӘГЕ!

Ландыш Тимерова

Күп кенә галимнәр тарафыннан XX йөз башы татар әдәбияты «алтын дәвер» буларак билгеләнә. Бу чорда әдәбиятыбыз һәм тематика, һәм сәнгатьчә эшләнеш ягыннан яңа баскычка күтәрелә. Кешенең рухи дөньясын, кичерешләрен, иҗтимагый омтылышларын, җәмгыять тормышындагы урынын билгеләүдә зур үзгәрешләр күзәтелә, шуңа күрә бу еллар әдәбияты җентекләп өйрәнүне таләп итә.

(ИБРАҺИМ НУРУЛЛИН ТӘНКЫЙТЕНДӘ – ФАТИХ ӘМИРХАН ИҖАТЫ)

Хәзерге татар әдәбияты фәнендә XX йөз башы – актив яктыртылган әһәмиятле чор. Бу дәвер әдәбиятын өйрәнүдә совет чорында М.Гайнуллин, Г.Халит һәм И.Нуруллин аеруча актив эшләде. Бүген дә әлеге өлкәдә эшләүчеләр бар, әмма, ни кызганыч, төрле сәбәпләр аркасында аерым бер әдипләр иҗаты икенче планга калдырыла бара. Шулар арасында Ф.Әмирханны да телгә алырга туры килә.

«Һаман әле Фатих Әмирханны белүебез җитәрлек түгел. Бу зур фигураның, иңен-буен үлчәп, әдәбиятта тоткан урынын билгеләп бетергәнебез юк. Сәбәбе – ваемсызлык һәм тарихыбызга битараф мөнәсәбәт булса кирәк. Бүгенге бурычларны хәл итү өчен үткәндәге казанышлардан файдалана белү дә җитенкерәми», – дип язган Ибраһим Нуруллин 1988 елда ук[1]. Вазгыять аннан соң да үзгәрмәде.

Галим үзе «Фатих Әмирхан» китабында («Атаклы кешеләр тормышы» сериясеннән) язучының прозасын бәяли, күпмедер дәрәҗәдә башка төр эшчәнлегенә дә игътибар итә. Аталган хезмәттә И.Нуруллин тарафыннан әдипнең күп кенә әсәрләре бәһаләнә, уңышлы яклары, әдәбиятка алып килгән яңалыклары күрсәтелә.

Фатих Әмирхан «Әлислах»ның һәр санына баш мәкаләләр, берничә рецензия һәм фельетон өстенә «Авырулар галәмендә» исемле зур күләмле очерклар язган. Анда шундый юллар бар: *«Кайда китте бу озын, аристократически бөгелә-сыгыла белә торган фигураң (камәтең), зәкявәтең белән шәһадәт бирә торган ачык маңлаең, бик матур таралган кара сачларың, ачык, аркылы үтәрлек итеп карый торган күзләрең белән, әллә нинди фәрештә шикелле кызларның күңелләрен аулап, йөрәкләрен каты селкенергә мәҗбүр иткән чакларың?»*[2] Әлеге сыйфатларның, билгеләрнең Фатих Әмирханның үзенә бәйле язылганлыгын искәртеп, И.Нуруллин болай ди: *«Фатихның үзе турында ич бу! Студентның үткәнен, үзе күргәндәй, күз алдына китереп бастыру өчен урыс карчыгының бер-ике җөмлә сүзе генә җитмәс иде, югыйсә»*[3]. Әсәрнең ахыргы җөмләләрендә дә автор позициясе искәртелә: *«И таң, ат инде тиз генә! Мин сине көтәм һәм тиздән булуыңа ышанам!» Менә әсәрнең соңгы аккорды. Оптимистик аккорд. Ләкин бу гади оптимизм гына түгел, бәлки ныгып җиткән дөньяга карашка нигезләнгән оптимизм»*[4].

И.Нуруллин әлеге әсәрнең жанрын «нәсер-очерк» дип билгели. Чыннан да, «Авырулар галәмендә» бер-берсенә шактый ерак торган ике форманың төп сыйфатларын берләштерә; димәк, автор яңача – синкретик форма рәвешендә оешкан калыпта иҗат итә.

«Авырулар галәмендә» нәсер-очеркы башыннан ахырына

[1] Нуруллин И. Фатих Әмирхан. – Казан: Тат.кит. нәшр. – 1988. – 277 б.

[2] Шунда ук. – 107 б.

[3] Шунда ук. – 107 б.

[4] Шунда ук. – 109 б.

чаклы «капма-каршы янәшәлек» дип атарга мөмкин булган алым кулланып язылган. Төньяктан исә торган җил һәм мәрхәмәтсез язмыш, урмандагы агачлар һәм кешеләр арасындагы тигезсезлек, тәгәрмәчле креслога баглы яшь кыз һәм сау-сәламәт аристократ карчык төп образлар буларак билгеләнә.

И.Нуруллин Ф.Әмирхан прозасыннан тулаем канәгать һәм аның һәрбер әсәрен камиллек үрнәге буларак бәяли.

И.Нуруллин «Гарәфә кич төшемдә» хикәясен Ф.Әмирханның беренче оригиналь әдәби әсәре дип атый. Буржуаз милләтчелек юкмы монда, татар милләтен бүтән милләтләргә каршы кую юкмы? И.Нуруллин шундый сораулар куя һәм үзе үк җавап бирә: *«Бу вакыттагы дөньяга карашын яхшы белгәнгә, кистереп җавап бирә алабыз: юк, һич юк! Беренчедән, болар яңа гына күзе ачылган шәкерт хыяллары. Икенчедән, яшь автор, героеның уй-тойгыларын беркадәр уртаклашса да, милләтне милләткә каршы куймый, мәгърифәтче буларак (әйе, ул мәгърифәтче дә бит әле), татарларны алга киткән милләтләр дәрәҗәсенә күтәрү турында хыяллана»*[5].

Ф.Әмирхан сурәтләү объекты итеп иске тип татар сәүдә буржуазиясенең аруырак вәкилен сайлап алган, бик үк карага буямый гына, үзенчә яшәргә, үзенчә гамәл кылырга юл куйган, героена карата антипатиясен сиздерми генә, акрынлап эчке дөньясын ачып биргән, дипраслый тәнкыйтьче. И.Нуруллинның һәр бәяләмәсе, һәр мөнәсәбәте гадәттән тыш төгәллеге белән аерыла.

Ф.Әмирханның «Замана хикәяләре» җыентыгы хакында И.Нуруллин тарафыннан түбәндәгечә сүз йөртелә: *«Замана хикәяләре»нең беренчесендә без эчкә яшерелгән сатира күрдек. «Милләт тәрәккый иттерү» – ачыктан-ачык сатира. «Танымаганлыктан таныштык» хикәясендә дә без тышы яңа, эче иске булган байбәтчәнең колоритлы сатирик образы белән очрашабыз. Моннан соң ул, тагын менә дигән берничә сатирик хикәя бирү белән бергә, «Фәтхулла хәзрәт» исемле сатирик повестен дөньяга чыгарып дан казанды».*

Күргәнегезчә, галим Ф.Әмирхан әсәрләренең формасын атау-дәлилләү белән генә чикләнми, беррәттән аларга карата бәяләмәле җөмләләр дә язып үтә. Шунысы игътибарга ташлана: И.Нуруллин Ф.Әмирхан прозасыннан тулаем канәгать һәм аның һәрбер әсәрен камиллек үрнәге буларак бәяли.

Ф.Әмирхан иҗатында юмор һәм сатираның зур урын тотуы ни белән аңлатыла соң? И.Нуруллин бу сорауга да дәлилле,

[5] Шунда ук. – 120 б.

төгәл җавап бирә. Ул аны, барыннан да элек, әдипнең табигате, характеры белән бәйләп карый. *«Тумыштан зирәк, үткен һәм тапкыр; гыйлем-мәгълүматы тиз артуга бәрабәр рухи яктан да тиз өлгерде; болай да үчекләүгә, ирештерергә, мыскыл итүгә һәвәс үсмер, тора-бара үзенең өстенлеген тоеп, искелек күренешләренә, аның тәрәккләренә ачы көлү, ирония белән карарга күнегеп китте. Икенчедән, тормыш үзе, тарихи барыш аны сатира каләмен эшкә җигәргә кушты»*, – дип яза галим «Фатих Әмирхан» китабында [6].

1909 елның язында «Фәтхулла хәзрәтнең үлгәч терелүе» исемле 24 битле китапчык басыла. Озакламый «Фәтхулла хәзрәтнең гает көне» исемле икенче кисәге дә нәшер ителә. *«Соңгы кисәкләре 1910 елда чыга. 1911-1912 елларда инде тагын бер кисәк өстәлеп, димәк, биш китап булып, әсәрнең икенче басмасы дөнья күрә»*, – дип искәртә И.Нуруллин[7]. Әлеге повестьтагы Фәтхулла хәзрәт образы да тормыштан алынган, прототибы – Йосыф хәзрәт, дип билгели ул.

Ибраһим Нуруллин китабында Фатих Әмирхан драматург буларак та ачыла. Драматургия өлкәсендәге беренче омтылышы ук Фатихка уңыш китерә. Гаҗәеп тере һәм тормышчан персонажлар, кискен һәм шулай ук тормышчан конфликт... Авторның яшьтән үк театрга якын торуы, урыс классик драматургиясен тырышып өйрәнүе бушка китмәгән, күрәсең.

«Яшьләр» пьесасы, һичшиксез, татар тормышына И.С.Тургенев иҗаты, бигрәк тә аның «Аталар һәм балалар» романы йогынтысында туган[8]. И.Нуруллин драмадагы типик образларга характеристика да биреп китә. Әйтик, «Кемнәр соң алар – иске тормышны яклаучы аталар?» дигән сорауны куеп, шуның аша Рәхимҗан, Хөсәен, Фәхерниса кебекләргә бәя бирә. Печән базары сәүдәгәре Рәхимҗан – типик «дин-мәгыйшәт айгыры»: үтеп чыккан кире, надан, бозык. Аныңча, һәр «иске – изге». Икенчесе – Хөсәен. Аваз методы белән укытуны яклый, шәригать мөмкинлек биргән дәрәҗәдә яңалыкны кабул иткән, улларын «адрес язарлык» һәм «гәзитә укырлык» кына урысча укытырга да риза булган. Кыскасы, бу – җәдидче татар купецы. Хатыны Мәрьям һәм кызы – Рәхимҗанның хатыны – Фәхерниса да шушы «лагерь»га керә. «Милләтче» дип тәкъдим ителгән Зыя яше, өс-башы, сөйләшүе һәм аралашу даирәсе ягыннан «яшьләр лагере»на карый кебек, әмма бу – тышкы охшашлык кына.

Пьесада күтәрелгән тагын бер проблема – хатын-кыз хокуксызлыгы мәсьәләсе дә шул рәвешчәрәк хәл ителә. Әсәр «политик азатлык һәм социаль тигезлек яулап алу өчен мәгърифәт коралы гына җитмәгән кебек, хатын-кызны коллыктан коткаруда да бу корал үзе генә көчсез», дигән фикергә китерә[9].

Типик характерлар иҗат итеп, аларны типик хәлгә куеп күрсәтү, мәгълүм булганча, җитлеккән реализмның төп сыйфаты, дип билгели И.Нуруллин.

«Фатих Әмирхан» китабының «Кояшлы һәм болытлы

[6] Шунда ук. – 125 б.

[7] Шунда ук. – 125 б.

[8] Шунда ук. – 130 б.

[9] Шунда ук. – 132 б.



«Һаман әле Фатих Әмирханны белүебез җитәрлек түгел...»

көннәр» дип аталган бүлегендә татар кызы турында сүз бара. Әдипнең күп кенә әсәрләрендә татар кызы үзенә генә хас гадәт-фигыле булган шәхес рәвешендә «хәрәкәт итә». «Рәхәт көн» (1910) хикәясендә аның дүрт стена эчендә ир көтеп утырган чагы. Кара көч Гайниҗамалның фикер даирәсен шулкадәр зурайткан һәм зәвыгын тупасландырган ки, укымышлы Закирга күңеле төшкән булса да, татлы телле приказчикны ир булырга кулайрак саный. «Кадерле минутлар» хикәясендә (1912) аны яңа гына ир йортына бикләп куйганнар. Элек сөеп йөргән егете белән күрешергә үзендә көч тапкан Хөршид җанлы курчакка әверелеп җитмәгән әле. Әмма бу – соңгы тыпырчынуы аның. Галим «Яшьләр»дәге (1909) фәрештәдәй Фәхернисаның еллар үткәч надан, зәһәр һәм килделе-киттеле хатынга әверелүен таный.

«Габделбасыйр гыйшкы» хикәясендәге төп герой – социаль тип кына түгел, бәлки психологик тип та, икесен аерылмас берлектә алсак, ул тиңдәшләре Хлестаков белән Обломов һәм бүтән төргә караган Молчанин, Манилов, Гамлет, Тартюф, Головлев һ.б. кебек үк, И.Нуруллин тарафыннан гомумкешелек тибы буларак билгеләнә.

«Фатих Әмирхан» китабында әдипнең балалар өчен язган әсәрләре хакында да әйтеп үтелә. Бу – язучының һәрьяклап талантлы шәхес булуына басым ясау максатыннан күрсәтелә. *«Ул үксез бала шул» – күздән яшь китерерлек хикәя. «Корбан» исемле әсәрдә безгә кечкенә, ә балага зур булып күренгән драматизм ята: малайның назлап үстергән бәрәнен корбанга чалалар. «Нәҗип» хикәясендә автор, маңгайга бәреп әйтмичә генә, тырышлыкны, хезмәт сөючәнлекне һәм һөнәр белүне пропагандалый. «Балалар атавы» исемле хыялый повестьта дуслык, туганлык, хезмәттәшлеккә корылган җәмгыять тасвир ителә. Ф.Әмирхан драматург буларак та балалар өчен берничә әсәр яза башлаган, ләкин никтер тәмамламый калдырган»*[10].

«Тигезсезләр» пьесасы А.П.Чехов драматургиясе рухында язылган һәм «Акчарлак» пьесасын бик нык хәтерләтә, дигән фикер әйтә И.Нуруллин. Икесендә дә, Чехов әйтмешли, «пот ярым» мәхәббәт, икесендә дә танылган язучы яшь кызда мәхәббәт кабынуга сәбәпче була, бүтән персонажларның мөнәсәбәтләренә, үзе дә сизмәстән, нииндидер үзгәреш кертә. Башка кайбер охшаш ситуацияләр, охшаш характерлар да күзәтелә.

[10] Шунда ук. – 177 б.

Ф.Әмирхан «Тигезсезләр»е белән татар драматургиясендә яңа этап ача, дисәк, ялгышмабыз. Галим «Г.Камал А.Н.Островский принципларын тормышка ашырган булса, Әмирхан драматургияне Чехов стадиясенә күтәрә», дигән фикердә[11].

Әлеге әсәр үз заманында күп кенә тәнкыйди язмалар, рецензияләр язуга сәбәп булып тора. «Тигезсезләр»гә карата әдәби тәнкыйтьтә капма-каршы ике фикер барлыкка килә. Инкыйлабтан соң, бигрәк тә егерменче елларның икенче яртысында, утызынчы елларда тискәре мөнәсәбәт өстенлек алып һәм тагын да тирәнәя барып, әсәр бөтенләй начар, дип бәяләнә башлый[12].

Фатих Сәйфи-Казанлы тәнкыйть мәкаләсендә Рөкыя образын, ясалма, табигый түгел, дип әйтә: *«Казан татары баеның гаиләсендә Рөкыя кебек нәфис, нәзакәтле чәчәкнең үсүе өчен һава да юк, зәмин дә юк, дип әйтәсе килә... Шуның өчен тип дөрес түгел, бу бары хәятне әдәбиятта матурлатыр өчен уйланган мөхәррирнең ясалмасы, дип әйтәсе килә»*[13].

Бу мәсьәләгә И.Нуруллин үз чоры ноктаи назарыннан торып та үзгәрәк бәя бирә: *«Идеаллаштыруга бәлки Рөкыя мисал була алыр? Әсәрдәге ир-егетләрнең барысы да бу кызга гашыйк булган кебек, автор үзе дә аңа соклана. Матур ул, саф, дәртле, сәләтле һәм туры сүзле. Беркатлылык белән кушылган аек акыл һәм романтик ашкынлык та бар аңарда. Хәтта кимчелекләре – чытлыклана белүе, иренчәклеге һәм җыйнаксызлыгы да ничектер килешеп тора. Кыскасы, Рөкыяга тоташ көмештән коелган бөтенлек хас»*[14].

Әлеге әсәрне тәнкыйтьче тема-проблематика ягыннан торып та бәяли: *«Тигезсезләр» драмасының үзәгендә кеше бәхете, кеше язмышы мәсьәләсе. Башлыча ул мораль-психологик планда хәл ителә. Әмма, күзгә бик үк бәрелеп тормаса да, социаль сәбәпләрне дә чамаларга мөмкин. Чөнки әсәрдә сүз гомумән кеше бәхете хакында түгел, бәлки буржуаз җәмгыять шартларындагы кеше бәхете турында бара»*[15].

Ибраһим Нуруллин Ф.Әмирхан иҗатын үз чорында киң таралган карашлар биеклегеннән дә, үзе ирешкән фәнни югарылыктан да торып бәһали. Аның әдәби тоемы да соклангыч.

Әдипнең иҗатын, биографиясен, эшчәнлеген яктырту «Фатих Әмирхан» китабында югары сәньгатьлелек белән башкарылган. Сигез бүлектән тора ул. «Эпилог дисәң дә ярый» дигән соңгы өлештә И.Нуруллин Ф.Әмирханның бөек шәхес булуын, аның Г.Тукай белән берлектә искә алынырга тиешлеген ассызыклый.

Билгеле, И.Нуруллинның Ф.Әмирхан әсәрләренә үз чоры ноктасыннан торып бәя бирүе, төпле анализ ясавы игътибарга һәм ихтирамга лаек. Язучының иҗатын, шәхесен өйрәнүгә күп көч куйса да, галим өйрәнү переспективаларын да күрсәтеп калдыра. Гаҗәеп талантлы һәм үзенчәлекле каләм иясенең И.Нуруллин дикъкатеннән читтә калган әсәрләре байтак, аларны да алга таба өйрәнергә кирәк. Киләчәктә бу эш, һичшиксез, башкарылыр дигән ышанычта калыйк. ■

[11] Шунда ук. – 186 б.

[12] Шунда ук. – 190 б.

[13] Шунда ук. – 190 б.

[14] Шунда ук. – 192 б.

[15] Шунда ук. – 193 б.

Атилла Расих һәм Әминә Сафиуллина Казан телестудиясендә. 1960 нчы еллар

МИН ШУЛАЙ ӨМЕТЛӘНЕП ЯТАМ...

Укучы игътибарына тәкъдим ителгән бу язма – 1995 елның 14 сентябрендә күренекле язучыбыз Атилла Расих (1915-1996) белән булган радиоинтервьюның кәгазьдәге күчермәсе. Әңгәмәнең үзенә күрә тарихы бар. Шулай бервакыт абыем Нияз Акмал миңа эш кушты: «Ишеткәнсеңдер, Атилла аганың сәламәтлеге нык какшаган. Беркем дә мәңгелек түгел. Аның тавышын радио өчен яздырып, үзе турында сөйләтеп калырга кирәк иде», – диде. Әле «Казан утлары»нда эшләгән чагында абый язучының «Ишан оныгы» романының редакторы булган, әйтүләренә караганда, әсәрне җиренә җиткерү өчен бик күп тырышлык куйган. Шуннан бирле алар бер-берсен хөрмәт итеп, дус булып яшиләр иде.

Алдан шалтыратып, киттем Атилла абыйларга. Дәрвишләр бистәсендәге йортларына килеп кердем. Ишекне хәләле Зәкия апа ачты. «Энем, хәле әйбәт түгел, җайлап кына сөйләшерсең

инде, яме», – диде. Җайлап кына сөйләшү шул булды: Атилла аганың ютәл өянәге башланган вакытларда миңа берничә тапкыр кухняга чыгып утырып торырга туры килде. Бәхеткә, андый өянәкләр озакка сузылмады, Зәкия апа: «Кер, энем, абыең көтә», – дип янә залга чакырды.

Авыруы каты булса да, аның йөзе без әдәбият дәреслекләрендә күреп үскән Атилла Расих рәсеменнән әллә ни аерылмый иде. Үзен егетләрчә саллы тота, җор сүз әйтергә, форсаты белән шаярткалап алырга да җай таба иде.

Әлеге нәни генә интервьюның язмасы Татарстан радиосында саклана. «Безнең мирас»та да бер мирас булып калсын. Тагын шул: кәгазьгә күчергән чакта җөмләне «төзекләндерү», редакцияләү артык булыр дип таптым, әдипнең сөйләм рәвеше дә бер үрнәк булып саклансын, дидем.

Нәсим Акмал

– Атилла абый, Сезгә килер алдыннан беркадәр мәгълүмат тупларга тырыштым, китаплар да актардым, барлык чыганакларда да Сезне 1916 елгы дип теркәгәннәр. Нияз абыйдан ишеттем: Сез 1915 елда тугансыз икән, димәк, берсекөнгә – туган көнегез, 80 яшь. Мондый буталчыклык каян килә, аның сәбәбе нәрсәдә?

– Шулай килеп чыкты инде, энем, Сез бәлки укыгансыздыр, минем «Казан утлары»ның 90 нчы елның башында чыккан «Ишан оныгы» дигән бер истәлекне. Шунда мин бу турыда язып чыктым. Әлбәттә, бөтен кешегә дә барып җитмәве ихтимал аның – анда язганнарның. Шуна күрә мин хәзер кабатларга мәҗбүр инде. Ни өчен мин уналтынчы елгы түгел, ә унбишенче елгы? Вакыйга болай була. Мин үзем унбишенче елның 16 сентябрендә туганмын. Моны мин ышанып әйтәм, чөнки әниемнең көндәлек дәфтәрләрендә һәм истәлегендә бу бик ачык итеп язылган. Нинди көнне, кайчан мин дөньяга килгәнмен? Дөньяга килгәнмен мин Истанбул дигән шәһәрдә. Төркиядә. Өйләнешкәннән соң эти белән әни 1914 елны, сугыш башланыр алдыннан гына, сәяхәткә һәм шул ук вакытта хаҗ кылу исеме астында Төркиягә китәләр. Төркиядән Гарәбстанга баралар, ул вакытта Гарәбстанның бөтен җирләре Төркия кулында. Хаҗ кылалар. Кайталар. Ул арада сугыш башлана һәм, шулай итеп, алар кайта алмыйча калалар. Бу сәяхәт 1918 елга кадәр дәвам итә. Ә мин инде 1915 елда туганмын, шулай итеп, минем туган көнем унбишенче елның 16 сентябрендә дип исәпләнергә тиеш.

– Ә ни өчен 1916 ел дип язылган соң ул?

– Күрәсең, эти белән әни соңрак җибәргәннәрдер хатны Троицкига, минем тууым турында. Аның өстенә әле сугыш вакыты, хатлар бик әкрен йөри. Шулай итеп, минем бабама – Зәйнулла ишанга ул бик соң килеп эләккән булуы ихтимал – шулай дип уйлыйм үзем. Аның өстенә, бабайның ялгышуы да ихтимал, ул 1915 ел урынына 1916 дип үзенең метрикә кенәгәсенә язып куйган. Минем документым 1916 ел булып чыкты. Ләкин мин моны теге вакытта берничек тә әйтә алмадым. Чөнки, дөресен генә әйткәндә, мин үземнең Төркиядә туганымны да яшерергә мәҗбүр булдым.

« Мин, мәсәлән, Муса Бигиевне күреп белә идем. Муса Бигиевләр Казанда иде әле. Без еш кына әни белән, кайвакытны өчәүләшеп әти белән дә Казанга килә идек. Чөнки әни Казан кызы, башта Казанда була, аннан Чистайга бара идек. Инде Муса Бигиевкә килгәндә, әни аны җизни дип йөртә иде, чөнки Муса Бигиевнең хатыны Әсма апа – әнинең туганнан-туган апасы.».

Беләсез замананы ул вакытны, әйе. Шуның аркасында минем туган елым рәсми рәвештә 1916 ел булып килде. Ләкин инде заманалар үзгәрде, хәзер инде дөресен әйтергә була. Шуңа күрә мин әнә теге истәлекләремдә бөтен дөреслекне ачык итеп язып чыктым. Менә шул аның вакыйгасы. Шулай итеп, мин быел сентябрьдә үземнең 80 яшьлегемне уздырам. Ул бәлки рәсми рәвештә узмас, шулай да минем өчен факт кадерлерәк.

– *Бабагызны Сез хәтерлисезме, ачык хәтерлисезме?*

– Юк. Без – әти белән әни һәм мин – 1918 елны кайтканбыз. Ә ул 1917 елны вафат булган. Аның турында Риза Фәхретдиновның китабы бар. Зәйнулла ишан турында. Махсус. Ул аның турында бик җылы итеп яза, аның прогрессив кеше икәнлеген. Чөнки Россиядә ул яңа уку алымнарына беренче булып фатиха биргән кеше. Аның турында еш кына язган безнең зур галимебез Гаспралы. Менә шуңа да, һичбер оялмыйча, бабам турында җылы итеп яздым. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә бина салганда беренче кирпечне кую өчен бабамны махсус чакырып китергәннәр Троицкидан. Ә «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең прогрессив бер мәдрәсә булуын һәм аннан бик күп галимнәр, зыялылар чыкканын сез белә торгансыздыр инде.

– *Сезгә шул заманның күренекле кешеләре белән аралашу насыйп булган, дип ишеткән идек...*

– Мин, мәсәлән, Муса Бигиевне күреп белә идем. Муса Бигиевләр Казанда иде әле. Без еш кына әни белән, кайвакытны өчәүләшеп әти белән дә Казанга килә идек. Чөнки әни Казан кызы, башта Казанда була, аннан Чистайга бара идек. Инде Муса Бигиевкә килгәндә, әни аны җизни дип йөртә иде, чөнки Муса Бигиевнең хатыны Әсма апа – әнинең туганнан-туган апасы. Алар беренче очрашкан вакытларда – 1907 елларда әле Муса җизни (мин дә шулай дип әйтим инде) Тукайлар белән бергә «Әл-гасрел җәдит» журналханәсе бинасында квартирда яшәгән. Шуңа күрә еш кына, Тукай янына килгәндә, Муса янына да керә торган булганнар әниләр үзенең апасы Бәдриҗиһан белән.

Безнең совет чорындагы язучыларның, олыларның барысын да беләм. Аралаштым. Кави Нәҗмине, мәсәлән, Алишны... Абдулла Алиш мин заводта эшләгәндә әдәбият түгәрәгенә килеп йөри иде. Без аның белән бик озаклап сөйләшеп, әңгәмәләшеп кайта идек. Күп вакытны трамвай да йөрми иде. Әнә шул Вахитов заводыннан «Кольцо»га хәтле, мин ул вакытта Арча кырында тора идем, җәяүләшеп, сөйләшеп кайта идек. Әле ФЗУда укый идем ул вакытны, беренче повестемны яздым. Алиш абый бик күтәреп алды аны, ай-йай, бик әйбәт, дип, бастырырга кирәк, дип. Соңыннан аны «Кызыл Татарстан»га да әйткәннәр, анда басмакчы булганнар. Ләкин бер «ләкин» килеп чыккан: кем соң ул, нинди кеше? Фамилиясе Рәсүлов. Нинди Рәсүлов? Теге Троицки Зәйнулла ишанның нәселеннән түгелме? Һәм, шулай итеп,

тынды, минем беренче повестем басылмады. Күп вакыйгалар булды инде утызынчы елларда, 1932 елны, дөресен генә әйткәндә. Һәм мин аңа шат та, чөнки ул өйрәнчек әйбер иде әле, беренче әсәр. Аның басылмавы хәерлерәк тә булды, дөресен генә әйткәндә. *(Көлә)*.

Әти дә мулла булган кеше. Әйе, мулла малае, ишан оныгы, как же так безнең совет язучылары арасына аны кертергә?! Хәер, менә сугыш елларында мин фронтта бик күп яздым. Мактана, дип уйламагыз, миннән күп язган бер язучы да юк фронт шартларында. Ул вакытны мин бик мактавдым инде. Чыгышыма игътибар да итмәделәр ул кадәр. Белмәделәр дә, күрәсең. Ләкин кайткач, кинәт мине «фаш» иттеләр инде, кем икәнлегемне белделәр һәм шуннан төрле вакыйгалар башланды инде, минем газаплануларым, язган әйберләремне бастыра алмыйча азап чигүләр... Мәсәлән, «Дустым Мансур» дигән романны мин алты ел бастыра алмадым. «Язгы авазлар» дигән әйберне шулай ук биш-алты ел бастыра алмыйча азапланып йөрдем, сугышып. Хәзер «Казан утлары»нда истәлекләремнең өченче китабы ята. Әнә шунда мин ул кичерешләремне, ул вакыйгаларның барысын да тулы итеп яздым.

– Атилла абый, без мәктәп программасыннан фронтовик язучыларның сугышчан юлларын шактый өйрәндек. Ә менә Сезнең сугышта катнашуыгыз турында, нишләптер, беркайда да язылмаган...

– Мин бик шатланып киттем сугышка. Фин сугышы вакытында. Мин ул вакытны Наркомземда эшлидер идем. Наркомземда ветеринария институтын тәмамлаган белгеч идем. Яшь белгеч. Чакырып алдылар партия оешмасына безне – яшь белгечләрне. Һәм әйттеләр: «Менә сугыш башланды, сугыш бара, кем ирекле рәвештә сугышка китәргә риза?» – диделәр. Мин риза булдым. Минәйтәм, китәм сугышка обязательно, ничек инде бармаска?! Мине комсомолга студент вакытта алдылар. Институттан куып чыгарганнар иде. Чыгышыңны яшергәнсең дип, ләкин мин Мәскәүгә барып, ходатайлап йөреп, восстановиться итеп кайттым һәм, шулай итеп, иптәшләрем белән институтны бетердем, кем белән бергә кергән булсам, шулар белән бергә бетердем дә. Бетердем с отличием, тырышып укыдым, миңа тырышмыйча ярамый иде. Әнә шулвакытны мине комсомолга да алдылар.

Шулай итеп, мин ризалык бирдем ирекле рәвештә фронтка китәргә. Бераздан алдылар да. Без Харис Якуповлар белән бергә киттек, бер эшелонда. Кузнецки дигән шәһәргә барып, запасной полкта хезмәт итә башладык. Фин сугышына әзерлиләр. Яз айларында сугыш бетеп калды. Шуннан безне кадровый частьләргә озаттылар. Һәм мин Куйбышев шәһәрендә хезмәт итә башладым. Ләкин, инде кайтам, ниһаять, өйгә кайтам, әдәбият белән ныклап шөгыльләнү вакыты житә, дип шатланып торганда гына бу сугыш башланды. Мине октябрь аенда жибәрделәр фронтка. Фронтка барып төшкән шәпкә, безнең инде анда блиндажларфәләннәр юк, окопта ятабыз. Бервакытны минем дустым – татар егете Гыйлемханов авырып китте. Мине санинструктор итеп билгеләгәннәр иде, мин старший сержант – шундый звание белән киттем мин фронтка. Теге авырып киткәч, миңа әйтәләр инде командирлар, санбатка илтергә кирәк, диләр. Мин алып киттем аны медсанбатка. Көне буе йөрдек эзләп, медсанбатны тапмадык. Шуннан инде әйләнеп кайттык без. Тегенең хәле начар иде. Янибызда гына авыл. Авылдагы бер өйгә керт син аны, шунда ятып торсын, диделәр. Керттем мин аны, ят-

кырдым. Бераздан, бер көннәнме, ике көннәнме, немец һөҗүм итә башлады. Киләләр, төрле яктан аталар, минометлардан сиптерәләр, үлеш-кырылыш. Мин инде булдыра алганча ярдәм итәм, бәйлим яраларын. Кинәт безнең взвод командиры әйтә: «Чигенәбез!» – ди. Ә мин әйтәм: «Нури Гыйлемханов нишли?» «Бер солдатны ал да, йөгер, аны алып чыгыгыз!» – ди бу. Бер солдатны эләктереп алдым да, чаптым. Тирә-якта шартлый миналар. Кычкыралар миңа: «Сержант, ты куда? Пропадешь ведь, пропадешь ведь!..» Мин әйтәм: «Ничего, не пропаду!..» Шулай итеп, теге өйгә бардык, кердек, ята Нури. «Давай, киен, киттек тизрәк, чигенәбез!» Ул торды, әкренләп киенә башлады, ниһаять, киенде, без аны култыклап алып чыктык теге солдат белән. Чыгуыбыз булды, «Һайт!» – безгә мылтык төзиләр. Шулай итеп, мин пленга эләктем. Ул маҗараларны хәзер язсаң буладыр инде. Ну, һәрхәдә бер биш көн юлда булдык без. Коточкыч шартларда. Бар уем: качып китү, качып чыгу. Көннәрдән беркөнне безне алып киттеләр, яңгыр сибәли шулай, кычкыралар нимесләр, сугалар таяклар белән читкә чыккан кешеләргә, артта калган кешеләргә эләгә инде күбрәк. Халык ач, бер биш-алты көн, артыгы белән инде, ашамаган алар. Әкрен генә баралар, шуннан без инде, күрәсең, тиешле җиргә барып җитә алмадык. Бер ашлык киптерә торган, яңа гына тактадан салынган бер бина янында туктадык. Шулкадәр күп иде пленныйлар – бер дивизия кадәр халык. Ким дигәндә. Бер ягыбызда безнең бик шәп уңган бодай җире, икенче ягыбызда үр, үр артында чокыр, юл буйлап сузылган буерак. Мин аңарга игътибар итеп килгән идем. Ерым дип әйтергә була инде аны. Текә ярлы түгел, яссы ярлы. Без инде Нури белән аерылыштык, ул әллә кайда, артта калды. Мин бөтенләй таныш булмаган кешеләр белән. Мин әйтәм: «Егетләр, качыйк без. Качарга мөмкинлек бар, чөнки охранада этләрфәләннәр юк, әйдә, шуны оештырыйк әле...» Өч егет, берсе Калинин дигән, Берсе Королев, берсе Пахвостов. Пахвостов дигәне без шулай качарга дип сөйләшә башлагач, мин хәзер киләм, диде дә, китте дә барды каядыр. Анда пленныйлар инде җимерделәр сушилканы, такталарыннан улаклар ясадылар, шунда бодайны уып пешермәкче булалар, мескеннәр. Без дә пешереп карадык, пешереп булмый икән аны алай.

Без шулай сөйләштек: өстә калку урында киндер чүмәләләре бар, без шунда качабыз. Айлы төн. Ләкин кинәт килеп чыкты кара болыт, бөтен күкне каплады. Әйдәгез, хәзер качсак, кача алабыз, юкса, кача алмыйбыз, дидем. Айны болыт каплаган арада яр астына йөгереп төштек һәм чаптык жан-фәрманга. Йөгердек, йөгердек, йөгердек... Анда нәрсә булды артта – ишеткән дә юк, белгән дә юк. Ниһаять, хәлсезләнеп егылдык өчебез дә. Бу арада, карасам, теге кара болыт киткән, күк йөзе ачылган, тулган ай бөтен җиһанны яктыртып тора. Чукынырга тотындылар тегеләр икесе дә. Калинин: «Сержант, – ди, – син мине коткардың», – ди. Киткәндә, мин әйтәм: «Туп-туры барабыз, барабыз көнчыгышка!» Минем кесәдә кыйбланамәнең угы ятадырие. Кайчандыр шунда берсе ватып ташлады да кыйбланамәсен, шуны салып куйган идем, кирәге чыгар әле дип. Шул кыйбланамәне инәгә утыртабыз, ул күрсәтә кайсы якка барырга кирәклеген. Менә шулай итеп, без биик саклык белән, юлсыз-нисез киттек. Юлга чыгарга ярамый. Киемнәрне алыштырдык бер авылда, шулай итеп киттек.

Инде хәзер, фронтның чигенә – алгы сызыкка килеп житәр алдыннан минем ике иптәшем миннән качтылар. Ничек

итеп качтылар? Һәр авылда тулып ятадыр иде камалыштан чыгып, йә булмаса пленнан качып киткән кешеләр, ирләр, алар барысы да шул тол хатыннарга иягәшеп, шулар белән яшиләр иде. «В зятья пристал», – дип әйтәләр иде аларны. Болар алгы сызыкка житәр алдыннан миннән сораша башладылар: ничек соң, син крестьян эшләрен беләсеңме, фәләнме, төгәнме, дип. Чабата ясый беләсеңме, жир сөрә беләсеңме? Болар нидер серләшә башладылар. Ә без һәр авылга житкән саен, син менә бу өйгә кер, мин бу өйгә керәм, теге бу өйгә керә, дип бүлешәдер идек өйләрне. Керәбез дә, алар безгә бәрәңге бирәләр, икмәк бирәләр, шулай итеп тамак ялгап чыгадыр идек. Бу юлы да шулай булды. Ашап чыктым, бәрәңге ашадым, икмәк бирделәр миңа. Теге күршеләргә кердем: сездәме теге фәлән? Юк. Тегесен эзләп керәм, сездәме? Юк. Шуннан аңладым: алар калганнар... Шуннан мин төкердем дә аяк астына, киттем берүзем. Менә шулай итеп, берүзем килеп чыктым мин үзебезнең якка. Бер кечкенә генә шәһәрчек дип әйтимме, бистә дип әйтимме инде, менә шунда барып чыктым. Райвоенкоматка кердек инде без. Бер чуваш егете белән очраштым мин. Лейтенант. Ул, машина була, ди, бергәләп китәрбез частька, ди. Ул үзе куркып беткән, мескен. «Немесләр ничек, нинди хәлдә?» – бик коты алынып миннән сораштырды инде. Ул арада машина килеп житте. Без машинага утырып китеп бардык. Шулай итеп, мин инде эләктем распределительный пунктка. Андагы хикмәтләр күп булды инде, и-и-и...

Хәзер Мышинскига һөжүм итәбез. Мышински – елганың теге ягында. Менә дигән егетләр морской пехотадан килделәр – бөтенесен кыра да сала, кыра да сала. Мылтык белән, бернинди артподготовка-фәлән юк, пулеметлары да юк хәтта. Әнә шунда эләкмичә, анда да белгечлегем ярдәм итте, бәхет булгандыр инде үз белгечлегем буенча армиядә калуым. Алай да, минем иптәшләр дә күп кырылды, бомбежка вакытында, минага ялгыш басып төрле хәлләр булды инде.

«Шулай итеп, теге өйгә бардык, кердек, ята Нури. «Давай, киен, киттек тизрәк, чигенәбез!» Ул торды, әкренләп киенә башлады, ниһаять, киенде, без аны култыклап алып чыктык теге солдат белән. Чыгуыбыз булды, «һайт!» – безгә мылтык төзиләр. Шулай итеп, мин пленга эләктем...»

– Атилла абый, бүгенге чорга нинди бәя бирер идегез?

– Бүгенге яңадан кору чорын бик шатланып, зур өметләр белән каршы алдым. Ләкин менә хәзерге чорда шундый бернәрсә күрәм: теләкләргә ирешә алмадык. Һәм нindидер ялгыш юлга кереп китте, минемчә, хакимият. Илнең хакимияте. Нindидер бер шовинизм исе килә. Нindидер Жириновскийлар баш күтәрәләр, хужа булып йөриләр. Аларның хакимият башына менеп утырулары, президент булулары да ихтимал. Менә бу мине бик борчый, куркыта. Ләкин шул ук вакытны безнең үзебезнең халыкның – татар халкының милли аңы туды, әле юк иде ул, туды һәм үсә башлады. Ул мине куандыра, менә минем бөтен өметләр баглаган нәрсәм әнә шул. Ниһаять, без шундый мөстәкыйльлеккә ирешербез. Һәм татар халкы, цивилизациясе күтәрелү аркасында, Европа халыклары дәрәҗәсенә житәр. Аларны да узып китәр, дип, мин шулай өметләнеп ятам. ■

Мәгъсум абый сөлгесе

Вакыйф Нуриев

1980 ел. «Яшь ленинчы» газетасы редакциясендә эшли башлаган чагым. Яшь чак, көчле чак, җүләр чак... Бер селтәнүдә бар дөньясын көл итмәкче булып йөргән чак.

Һәр атнаның дүшәмбесендә – «летучка»: үткән атнада газетада басылган язмаларга анализ ясыйлар. Кемнедер мактыйлар, кемнеңдер «кирәген бирәләр»...

Кайчакта менә шул җыелышларга читтән дә йә берәр язучыны, йә берәр галимне чакыралар иде. Бервакыт «Чаян» журналының җаваплы сәркатибе, прозаик Мәгъсум Хуҗинны чакырдылар. Сүзне аңа бирделәр.

Башта «әһем-әһем» дип тамак кырып алды ул. Беравык пауза ясап торды. Аннары акрын гына, ипләп кенә сөйли башлады, һәр сүзен уйлап, күңелгә сеңдереп әйтә. Кемнедер мактый, кемгәдер киңәшләр бирә. Минем мәкаләдә бер җөмләдә стиль хатасы киткән. Сүзләрнең урыннарын алмаштырып куйганда, һичсүзсез, җөмлә уңышлырак булыр иде. Мәгъсум абый менә шуны искәртте. Аннары сорап куйды:

– Мәкаләнең авторы Вакыйф Нуриев үзе кайда соң әле?

– Сезнең артта утыра бит, – диделәр аңа.

– Ә-ә-ә... Менә кая кереп утырган икән?! – Мәгъсум абый, борылып, беравык күземә карап торды. – Мин – җүләр баш, тормышыма куркыныч янаганын да сизмичә, аны тәнкыйтьләп торам икән бит. Шунда арттан башка берне кундырган булса...

«Әһә... Мәгъсум абый юкка гына «Чаян»да эшләми икән. Абзыйда юмор хисе бар», – дип уйлап куям эчтән генә.

Хуҗин абый (без аны шулай дип тә йөртә идек) йомшак итеп, хәтерне калдырмаслык, күңелне төшермәслек итеп әйтте әле. Әнә, «Социалистик Татарстан» газетасында басылган бер мәкаләмдә «җилем» белән «җилен»не бутаган өчен (машинистка белән корректор хатасы бит әле!) бөек әдибебез Гомәр Бәширов шул ук газетада минем тетмәмне тетте. Гомумән, ул чорда өлкән язучылар тел-өслүпкә бик җитди карыйлар иде. Сүзне урынлы-урынсыз куллану, кечкенә генә чатаклык, фальш аларны борчый, хәтта ачуын чыгара иде. Бүген газета-журналларда басылган кайбер язмаларны күрсәтсәң, радио-телевидение аша яңгыраган чыгышларны (җырларны әйткән дә юк инде) тыңлатсаң, мәрхүм әдипләребез каберләреннән сикереп торыр иде. Мәгъсум Хуҗин иҗатында да телгә бик таләпчән булды. Аның әсәрләрендә һәр җөмлә кат-кат уйланган, анда һәр сүз үз урынында.

«Чаян» журналы редакциясе Декабристлар урамындагы 2 нче йортның 9 нчы катында иде. «Яшь ленинчы» – 8 нчедә. Ике арадагы сукмакка «үлән үсми». Без дә менгәлибез, Мәгъсум абый да төшкәли. Безнең редакциягә еш кына сатирик язучы Фаил Шәфигуллин (ул да «Чаян»да эшли) белән бергә төшәләр иде алар. Ул вакытта «Яшь ленинчы» газетасының әдәбият-сәнгать бүлеге хезмәткәре, шагыйрь Зөлфәт янына. Шунда ук әдәби бүлек мөдире, шагыйрь Госман Садә утыра. Башын кыңгыр салып, Мөдәррис Әгъләм килеп җитә. Күрше бүлмәләрдән Ләбиб Лерон белән Нияз Акмал, Камил Кәрим, Атлас Гафиятов белән мин керәм. Китә сөйләшү, китә гәп. И-и ул әңгәмәләрнең

**Сәфәрдән фоторепортажны www.beznenmiras.ru сайтында карарга мөмкин.*

Әдипнең каберен зиярәт кылу.* Саба. 3 август, 2016 ел

кызыклыгы, матурлыгы, ихласлыгы!.. Ул очрашу- сөйләшүләрнең нәтиҗәсе – «Яшь ленинчы»да басылган берсеннән-берсе матуррак хикәяләр, шигырьләр. Нәкъ җырдагыча кебек, сагындыра шулчаклар... Мәрхүм Мәгъсум, Зөлфәт, Мөдәррис, Фаил абыйлар сагындыра. Сагындыра мәрхүм Нияз. Һәркайсының авыр туфрагы җиңел булсын.

Шулай бер сөйләшеп утырганда, сүз иярә сүз чыгып, Мәгъсум абый теге вакыттагы «летучка»ны тагын бер исенә төшереп куйды бит.

– «Яшь ленинчы»да чыккан хикәяңне укыдым. Энем, яз, туктама, – диде ул һәм башындагы бүреген бер якка авыштырып куйды. – Теге вакытта синең бер җөмләңә бәйләндем бит әле... Син артта гына утырасың икән. Ничек башка кундырмагансыңдыр?

– Кундырырсың, бар, – дип, мин дә шаяртып алам. – Күтәреп алырсың да тотып атарсың... Син көрәшче икән бит, Мәгъсум абый! Язучылар Сабан туенда (элек йә Аккош күлендә, йә Займищеда, Идел буенда язучылар Сабан туе үткәрә торган булган) сиңа чыкканы юк, диләр...

– Нишләп булмасын?! Бар!

– Кем?

– Хәсән Туфан!

– Хәсән Туфан?!

– Бервакыт мине шундый итеп күтәреп-кысып алды – нишләргә дә белмәдем. Ничек тәгәрәгәнемне сизми дә калдым. Ул чиста салды, мин чиста егылдым. Сөлгем дә чиста калды.

Күр әле, егылганда да чиста егылырга кирәк икән бит. Чиста, чисталык...

Телебезнең чисталыгы...

Юморның чисталыгы...

Үзара мөнәсәбәтләрнең чисталыгы...

Күңелнең чисталыгы...

Мәгъсум абый чиста, саф күңелле кеше иде. Шундый булмаса, Хәсән Туфан аның белән бил алышып та тормас иде.

Редакциядән: *3 августта Саба районының Юлбат авылы мәдәният йортында күренекле язучы Мәгъсум Хуҗин (1930-2008) турындагы истәлекләр китабын тәкъдим итү булды. Чарада Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, М.Хуҗин турындагы китапны төзүче, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон, Газинур Морат, Камил Кәримов, Фәйрүзә Мөслимова, Рәдиф Сәгъди, М.Хуҗин иҗатын өйрәнүче галимә Гүзәл Насыйбуллова, Саба муниципаль район хакимияте башлыгы урынбасары Таһир Шәрәфиев, район мәдәният бүлеге җитәкчесе Рөстәм Заһидуллин һәм башкалар катнашты. Язучылар шул ук көнне Сабадагы Үзәк китапханәдә, М.Хуҗинның туган авылы Тенекидә булдылар, әдипнең каберен зиярәт кылдылар.* ■

Бер китап эзеннән...

(Габдулла Тукайның «Мәҗмугаи асаре», 1914 ел)

Гөләндәм Давыдова,
Мамадыш шәһәренең Төбәкне өйрәнү музееның фәнни хезмәткәре

Габдулла Тукай – иң мәшһүр, иң газиз, иң сөекле шагыйребез. Ул – халкыбызның гасырлардан гасырларга җыйналып килгән кайгы-сагыш, әрнү-үкенеч, өмет-ышанычларының, күңел моңнарының чагылышы.

Тукайның кыска гына гомерендә калдырган иҗат мирасы – аны дөнья күләмендә таныткан зур байлык.

Тукай, халкын олылап, милләт өчен борчылып язган әсәрләре белән генә түгел, ә һәр гади кешегә дә аңлаешлы өр-яңа әдәби телгә нигез салуы белән дә тарихка кереп калган шәхес. Аның беренче китаплары гарәп графикасы белән басыла, тиражы да әллә ни зур булмый. Димәк, ул китаплар чын мәгънәсендә бәһасез мирас булып тора, алар бик сирәк очрый. Булганы да – галимнәр кулында, милли китапханәдә, институтларда...

Нинди бәхет, шул үлемсез китапларның бер нөсхәсе минем кулыма да килеп керде. Аны миңа Мамадыш шәһәренең Төбәкне өйрәнү музееның штаттан тыш хезмәткәре, районыбызның Югары Кыерлы авылында яшәүче Нуретдин Хисам улы Имамиев биреп торды.

Бу китап аңа очраклы гына килеп ирешә. Инде узган гасырның 80 нче елларыннан бирле тарих белән кы-

зыксынучы, төрле иске китап, документлар җыючы якташыбыз 2013 елда Киров өлкәсенең Сосновка шәһәрендә яшәүче туганнан-туган сеңлесе Роза янына кунакка бара. Роза аңа 60-70 нче елларда Сосновкада мулла булып эшләгән, 1906-1992 еллар арасында яшәгән әтисе Шакирҗанов Салихҗан Шакирҗан улыннан калган бер китапны күрсәтә. «Кечкенә вакытта озын кичләрдә, әти гел шул китаптан төрле шигырьләр, әкиятләр укый иде, без Тукай әсәрләре белән тәрбияләнеп үстек», – ди. Тик аңа ничек килеп эләгүен әйтә алмый. Салихҗан бабай чыгышы белән Югары Кыерлыдан, Имамиев Нуретдинның туган тиешлесе, ул сугыштан соң Сосновкага күчеп китә, пенсиягә чыккач, мулла булып йөри башлый. Укымышлы, дини гыйлемле була. Г.Тукайның китабын ул күз карасыдай саклый, кызына да кадерле ядкяр итеп тотарга кушып калдыра...

Әлеге китап кулыма эләгүгә үк, миндә күп сораулар туды: кайчан басылган, нинди шигырьләр кергән, ничек Сосновкага барып эләккән? Сорауларыма бераз ачыклык кертү өчен, шәһәребез мәдрәсәсенә киттем. Ярдәмгә Мамадыш мәдрәсәсендә директор урынбасары булып эшләүче Ранил Равил улы Талипов килде. Ранил хәзрәт мәдрәсәдә 2009 елдан бирле эшли. Дини белемне ул Түбән Кама шәһәрендәге «Рисәлә» мөселман мәдрәсәсендә ала. Алабуга педагогия институтының филология бүлеген тәмамлаганнан соң, эшчәнлеген шәһәр мәдрәсәсендә башлый. Телче буларак, Тукайның китабы Ранил хәзрәттә зур кызыксыну уятты, ул миңа ярдәм итәргә булды. Ранил хәзрәт үткәргән тикшерү нәтиҗәләре белән сезне дә таныштырып китәргә телим.

Китап «Габдулла Тукаевның мәҗмугаи асаре» дип атала, ягъни Габдулла Тукайның әсәрләр җыелмасы. Ул 1914 елда Казанда чыгарыла. Китапның титул бите төшкән, күрәсең, кулдан «Атаклы шагыйребез Кушлавыч авылының Габдулла Мөхәммәтгариф улы Тукаевның Мәҗмугаи асаре» дип

язылган, алгы битенә Г.Тукайның 1910 елда төшкән фотосурәте куелган. Аңа шагыйрь үз кулы белән «Кыйтга» (1913) шигыреннән бер өзек язган:

Кайтмады уч, бетте көч,
сынды кылыч – шул булды эш:
Керләнеп беттем үзем,
дөньяны пакьли алмадым.

Бу тетрәндергеч юлларда Г.Тукайның бөтен тормышы, үз алдына куелган максаты чагыладыр кебек миңа. Ул үз халкының аһ-зарын, кайгы-хәсрәтен, уй-теләкләрен йөрәге аша үткәрә, аңа ярдәм итәргә тели, әмма дә, кызганыч ки, бу авыр көрәштә аның теләктәшләре юк диярлек...

Китапта шулай ук Тукайның үләр алдыннан төшкән, өметсез күзләре белән киләчәккә (бәлки бушлыккадыр) караган фотосурәте дә урын алган.

Китап авторның үзе турында язган «Исемдә калганнар»ы белән башланып китә.

«Су анасы», «Шүрәле», «Кәҗә белән сарык», «Бала белән күбәләк», «Пар ат», «Эш беткәч уйнарга ярый» һ.б. күп кенә әсәрләренә әллә ни күләмле булмаган рәсемнәр ясалган. «Су анасы»н шагыйрь 1908 елда яза һәм «Бер авыл малае авызыннан» дип билгеләп китә, димәк, ул аны элегрәк халык авыз иҗаты белән кызыксынып авылдан-авылга йөргәндә ишеткән. Шулай ук Тукай «Пар ат» шигырен Лермонтовның «Тройка»сын укуы тәэсирендә язганлыгын әйтеп үтә.

Танылган әсәрләре белән беррәттән, «Ишек бавы», «Гашыйк», «Авыл хатынының бала тирбәткәндәге өмитләре», «Васыятем» һ.б. күп әсәрләре дә кергән. «Проповедь» («Вәгазь») шигыре русча бирелгән һәм Абдулла Тукаевтан дип язылган. Китапта шулай ук Лев Толстой сүзләренең тәрҗемәсе бар: «Кирәк анчак яшәр микъдар ашарга, кирәкми тик ашарга, дип яшәргә».

Мин Ранил хәзрәттән бу әсәрләрнең бүгенге текстлары белән ул вакытта, чын Тукайча басылуы арасында аерма бармы икәнен һәм телче буларак бәяләмә бирүен сорадым.

– Эчтәлеге, текст язылышы шул ук – диде ул, – тик кайбер сүзләр искечә язылган. Мәсәлән: моны-боны, ачты-ачыры, суккалап-сукгалап, шатлык-шадлык, җирем-йирем һ.б. гарәп, фарсы теленнән кучкән алынма сүзләр.

Ранил хәзрәтнең сөйләве буенча, китап белән эшләү аңа әллә ни авыр бирелмәгән. «Рәсилә» мәдрәсәсендә алган белем бик ярдәм итте», – ди ул. Шуның өстенә, интернеттан да файдаланган. Үзем дә төрле елларда чыккан китап, журналлардан бу китап турында күп кенә кызыклы мәгълүмат җыйдым.

Китапның йөз елдан артык элек чыккан булуы ук аның нинди кадерле, милләт тарихы, Тукайның бибәһа мирасын өйрәнүчеләр өчен әйтеп бетермәслек кыйммәтле басма икәнен күрсәтә. Ә инде китапны, үзе исән вакытта, сөекле шагыйребез Тукай турысынча үзе әзерләгәнен дә әйтсәк, бу безнең өчен хәзинәгә тиң табыш. Аны ничек әзерләве, китапка керәчәк әсәрләрен ничегрәк сайлавы турында Тукай «Уянгач беренче эшем» дигән мәкаләсендә язып калдыра. Аны татар дөньясында бик популяр булган һәм шагыйрьнең һәр язылган шигырен чыгарып барырга тырышкан «Кояш» газетасы 1913 елның 18 март санында бастырып чыгара. *«Тиз арада үзем браковать итмәгән һәм үзем яраткан шигырьләрдән җыеп, 400 сәхифәле зурлыгында рәсемле бер мәҗмуга чыгарырга карар бирдем»,* – дип яза Тукаебыз...

Ул ашыга – кабалана, ни өчен дигәндә – 1913 ел башыннан, бераз чигенеп торган авыруы көчәеп китә (туберкулезның соңгы формасы) һәм шагыйрьгә дуслары тизрәк дәваланырга кереп ятарга кушалар. Аерым-аерым басылган шигырь, әсәрләрен бербөтен басма итеп күрергә хыялланган шагыйрь бу эшне Клячкин хастаханәсенә

керер алдыннан төгәлләргә тели. Ялгыз эшләү аның сәламәтлеген начарайта, болай да хәлсез организмының соңгы көчләрен ала. «Ике-өч төн йокламыйча, мәҗмугаи асаремне тәртипкә салдым, шул мине бөтенләй эштән чыгарды», – дип сөйли ул хастаханәгә хәлен белергә килгән дусты Шиһап Әхмәровка. Хастаханәдән дәваланып чыгарга, бераз булса да яшәргә өметләнгән Тукай китабын аннан чыккач та бастырырга уйлый. Шуңа күрә, язган мәкаләсен дә «Уянгач беренче эшем» дип атый, ягъни терелеп чыккач та беренче эше итеп үз куллары белән җыелмасын чыгарырга тели. Ни кызганыч, ни үкенеч: кечкенәдән салкын тидереп үпкә авыруыннан интеккән, җирсез, өйсез, гаиләсез, салкын бер номерда яшәп, көнен-төнгә ялгап иҗат итүче Габдулла Тукай көннән-көн сула бара. Клячкин хастаханәсенә 10 мартта (искечә – 26 февраль) кереп яткан шагыйрь15 апрельдә (искечә 2 апрель) инде дөньядан китә...[1]

Габдулла Тукайның «Мәҗмугаи асаре»н – ягъни, үзе әзерләп калдырган беренче җыелмасын XX гасыр башының танылган галиме, тел белгече, тарихчы, җәмәгать эшлеклесе, Тукайның дусты Җамалетдин Вәлиди 1914 елда 463 битле итеп туплап, үзенең кереш сүзе белән, Казанның Шәрәф типографиясендә бастырып чыгара. Ул әллә ни үзгәрешләр кертми: Тукай әзерләгән әсәрләргә рәсемнәр өстәлә, шагыйрьнең берничә фотосурәте куела. Җ.Вәлиди басманы тизрәк дөньяга чыгарырга тели, ник дигәндә, шагыйрьнең үлеменә бер ел була һәм ул шул рәвешле дустының хыялын тормышка ашырырга уйлый. (1918 елда шул ук мөхәррир-төзүче тарафыннан икенче басма дөнья күрә. Монысында «Исемдә калганнар» повесте «Алтын әтәч» поэмасы белән алмаштырыла. Кереш мәкаләдә һәм 1923 елда «Мәгариф» журналының 3-4 нче саннарында басылган «Тукайның шагыйрьлеге» исемле хезмәтендә автор татар әдәбият белемендә шагыйрь иҗатын беренче мәртәбә чорларга һәм жанрларга бүлеп тикшерә һәм әдипнең гыйльми биографиясен булдыруга нигез сала. Кызганыч, гасыр башындагы күп кенә әдипләребез, галимнәребез кебек үк, Җ.Вәлиди дә репрессия корбаны була).

Китап, басылышыннан башлап, кем кулында гына булмаган! Моны бит кырыйларына язылган искәрмәләрдән күреп була: мәсәлән, Казанда яшәүче Гыйлемхан, Илдархан (төгәл адреслары бар), Айдар авылында яшәгән Дәүләтшин Гәрәйша, төрле шәһәрләрдән – Сафин, Айдарова һ.б. Башта аны Казанда 45 сумга сатып алганнар, аннан төрле елларда бәя төрлечә булган: 1947 елда кемдер 2750 сумга сатып алган, 1948дә – 3800, ә 1951 елда бәя 6550 гә җиткән. Бер битендә 1951 елның 20 гыйнварында мондый сүзләр язылган: «Мин бу китапны укыдым. Бик яхшы китап! Укымаган кешегә укырга кушам». «Укы, гыйбрәт ал», – дип гарәп имлясында язылган сүзләр дә очрый.

Китапның, безнең көннәргә ертылмыйча, чагыштырмача чиста килеп җитүе хуҗаларының аңа чынлап та ядкяр итеп, Тукайның мирасы итеп караулары күрсәтә. Рәхмәт аларга!

Гарәпчә, латинча язылган хат, китаплар, документлар керүгә, мин еш кына мәдрәсәдә эшләүчеләргә мөрәҗәгать итәм. Габдрахман хәзрәт, Рәхимә апа, Ранил хәзрәт миңа бик теләп булышалар. Барыбыз да бер өлкәдә эшлибез ләбаса: үткәнебезне барлыйбыз, изге ядкярләрне яшь буынга җиткерергә тырышабыз. ■

[1] Сөекле шагыйребезнең фани дөньядагы соңгы көннәре хакында журналыбызның быелгы 4нче санындагы «Очты дөнья читлегеннән» (72-79 битләр) дигән сәхифәдә укый аласыз.

Рейхстаг түбәсендә кызыл әләм җилферди. 1945 ел

БЕР КАТ КИС...

Азат Фәизов

Сентябрь – дөнья тарихында иң куркыныч сугыш башланган ай. Сентябрь – дөнья тарихында иң куркыныч сугыш тәмамланган ай да.

1939 елгы көзнең беренче көнендә яңгыраган туп тавышы 1945 елгы көзнең икенче көнендә тына, ниһаять.

Дөрес, Россиядә, бөтен җиһаннан аермалы буларак, бу канкоешның бер өлешен – СССР белән Өченче рейх арасындагы «низагны» «гына» аерып карау гадәткә кергән. Шунлыктан, күрәсең, Тугызынчы майны (әпәйттеки, кешелек галәме Алманиянең капитуляция көне дип Сигезенче майны санаганда) җәелеп, колачлап бәйрәм итәргә яратабыз. Җитмеш бер ел буе! Ошбу тантананы уздыру дәүләткә торган саен күңеллерәк тә, җайлырак та, борчусызрак та була барыр сыман: ветераннар көннән-көн кими... Озакламый, һичкем алдында җаваплылык тоймыйча һәм тамчы да кыенсынмыйча, фәкать күкрәк кагарга калачак: җиңдек!

Сер түгел, җиһан яңадан биполярлыкка кайтты: без вә... калганнар. Бөтен дөнья сиңа карап йөз чөергәндә фәкать үзеңә таянырга кала. Әмма бүгенең – соры, киләчәгең томанлы булган хәлдә нишләргә соң? Мондый очракта бердәнбер сыналган юл – үткәнгә мөрәҗәгать итү. Ул урындыгыңның җиргә нык ябышып торуына инан-

«Идел-Урал» легионы марш атлый. 1942-1944 еллар

«Без әле сугышырбыз!»

дыра, яңа көнгә өмет кенә түгел, май кояшыдай түп-түгәрәк ышаныч та уята. Онытмыйк: «искелекнең» «тамырын корыткан» ил, баш чүмеченә бомбалар суга башлагач, Александр Невскийларны исенә төшерде ләбаса! Тарихтан чеметем генә дөреслекне алды да, шуны кабартып-күпертеп, матур кәнфит кәгазенә төреп халкына күрсәтте: «Кылыч белән килгән кылычтан үләр!» Фильмның 1942 елгы плакатларында И.В.Сталинның сүзләре дә шәбәрешкән беләкләрне җылыткандыр: «Бөек бабаларыбызның батыр образы сезне бу сугышта дәртләндереп торсын!» Һичнинди тәэсире булмады, дип әйтергә дә ярамый бит, киресенчә, пропаганда – бик зур куәт ул; юкса, дүртбиш кешегә өч патронлы бер мылтык исәпләнгәндә дошманны үз өненә куып кертү, аны шунда штык белән чәнчеп үтерүгә ирешү – җиңел эшләрдән түгел.

Инде самимиләрчә уйлап куям: коммунистлар партиясе татар тарихын Октябрь түнтәрелешеннән башлап кына өйрәнүне шул ук максаттан чыгып гамәлгә кертмәдеме икән? Көрәшкә, батырлыкка дан яудырган «Идегәй» дастанын ВКП(б)ның махсус карары нигезендә 1944 елда тыйлар. Милләтебезнең яуда «арысландай көчле» булуы файда китерүдән битәр шөбһә тудыра башлагач тормышка ашырылмадымы икән бу кара гамәл? Сталинның плакатка үрләгән сүзләренә янә күз ташлагыз әле... Ә синең, татар,

үрнәк алырлык бабаларың да, җиңүләрең дә юк, үткәнең дә юк! Киләчәгең дә юк, димәк! Тыела! Инде Берлинга, үс!

Россия бу сугышны яхшылап һәм, ахры, бик озакка искә төшерде. Ышанам, хакимиятнең сөмсез карашында «казыныгыз!» ишарәсе чамаланып, 1941-1945 еллар афәте хакында моңарчы яшерелә килгән бик күп фактлар – тетрәндергеч саннар, җелек өшеткеч вакыйгалар, башка сыймас яңалыклар калкып чыгачак әле. Чөнки дошманың зәһәррәк, мәкерлерәк, ә аңың чыраенда йодрык кашу куркынычрак, канлырак, кешелексезрәк булган саен, җиңү эйфориясе дә ләззәтлерәк тоела...

Быелгы Җиңү көнендә мин дә Беренче май мәйданына, Җәлилебез янына ашыктым. Юк, алмаш кулмәк кигән яңа «тәре походы»н (хәзер ул «үлемсез полк» дип атала) күрер һәм анда катнашучыларны хуплап алкышлар өчен түгел, шигырь тыңларга килдем. Дөрес, һәрвакыттагыча, эш шигырь белән генә чикләнмәде – сүзләр сөйләнде, биюләр биелде, җырлар җырланды. Күз явын алырлык гүзәл кыз әби-бабасына багышлап моң түкте: «Молодые мои старики, мы еще повоюем!» Шулвакытта куырылган йөрәгемне удым мин: нишләп алай? Булган кадәресе җитмәгәнмени сугышның? Корбанның биргән кадәре җитмәгәнмени? «Их, сабый, сабый», – дип игътибарыңны читкә юнәлтеп котылыр идең дә, бәлки... Ләкин авызы тулы сыңар тешен ыржайтып кул чабып утырган карчыкларны ничек аңларга кирәк? Чал чәчле абзыйның: «Мы за ценой не постоим!» – дип гайрәт чәчүен ничек аңларга? Юньле-башлы дәүләттә кеше – иң зур кыйммәт булырга тиеш ләбаса. Ә илеңне хәрабәләрдә калдырып, утызышар миллион халкыңны утка салу – җиңүме икән әле ул, җиңелүме? Берлин операциясен бер бөртек чәче агармыйча тормышка ашырган Советлар Союзы маршалы Георгий Жуковтан Америка генералы Дуайт Эйзенхауэр: «Мина кырларын шулкадәр аз танк (тимер-томыр!) югалтып ничек кичтегез соң?» – дип кызыксынгач, булачак СССР Оборона министры гади генә: «Без анда әүвәл пехотаны җибәрдек», – дип җаваплый. Чагыштырыгыз: американнарның, һәр бөртек сугышчысын кызганып, Тын океан театрында кайнаган сугышка чынлап торып кереп китәргә базмаган көннәре бу.

Шулай, «бер мөкаддәс хис белән һәрбер кеше хәйран бүген»...

Бәйрәм! Салют! Ура!

Мәйданнан кайтканда тыгылышта («бөке» дип тә аныклыйк әле) утыруы да үзгә төрле, рәхәт иде – музейга килеп кердеңмени: машиналарга Георгий тасмасы тагылган, «Ватан сугышы» ордены, «Т-34» танкының сурәтләре чәпелгән, янәшәдә генә Баварияненң затлы «BMW X5»е, артына зур итеп «Трофей из Берлина» дип язылган, алда сумаладай куе төтен чыгаруына карамастан, табигый тәкәбберлеген җуймаган «копейка» пытырдый, сыртында – горур хәрефләр балкышы: «Спасибо деду за Победу!» Әледән-әле күзгә кергән транспорттан «халыклар атасы» (кайсы халыкларныкы икәненә генә төшенеп җитәсе бар) серле елмаюын ташлаштыргалый...

Пропаганда тегермәне үз эшен эшли: миләр тартыла, миләр тартыла, миләр тартыла...

Нәтиҗәдә – иманыбыз камил: украиннар – фашистлар, Петр Порошенко – икенче Адольф Гитлер, Көнбатыш илләре Украинаны, «Өченче рейх» урынына «асрамага» алып, яңадан «Көнчыгышка теш кайраргa» котырта... Иркеңнең буылуын, кесәңдә җилләр уйнавын, ә бәяләрнең бәйдән ычкынган эттәй котыруын уйлама. Шулай кирәк. Уяу бул! Тирә-юнең дошманнар. Ә түземлегең өчен джек-пот явачак, билгеле: без барыбер җиңәчәкбез!

Беркадәр читләшү булырмы... Мәрхүм Борис Немцов былтыр, үтерелүенә ике сәгать кала, «Эхо Москвы»га интервью биргән иде. Исегездәдер. Шунда ул,

хакимиятне бик күп гөнаһларда гаепләү белән бергә, Украина (дөресрәге, Кырым) мәсьәләсендә Россиянең Будапешт меморандумын бозуы хакында да сөйләде. Билгеле, «бусы нәрсә икән моның тагы», дип, шунда ук интернетны ачтым. Һәм шап итеп артка утырдым. Баксаң, 1994 елда Украинадан элеккеге СССРның барлык атом-төш коралы чыгарылганда, АКШ, Бөекбритания вә Россия (!) Украинаның бәйсезлеген, суверенлыгын һәм хәзерге чикләрен ихтирам итәргә, санларга (тимәскә, бозмаска!) тиеш булган икән. Әмма җилнең үзгә яктан исүе җитте... Фикер үзгәрде. Вәгъдә дә. Чикләр дә...

Украина хәзер Россияне күралмый булса кирәк. Украиннар урысларны күралмый. Һәм, ни төчеләнергә, бу хис – хыянәт хисе! – күршеләрдә мәңге сакланачак. Күпме гомер «без – бертуганнар» дип яшәлде кебек, югыйсә. Сугышта да иңгә-иң сугышылды. Хәер, әлеге фаҗигагә карата Украинаның фикере күптән үзгәрә башлаган иде инде. Грузия дә шулай. Балтыйк буе илләре – Эстония, Литва, Латвия дә... Без, әлбәттә, мәсьәләнең төбе-тамырына төшәргә тырышмыйча гына, аларга да «фашист» мөһере суктык. (Быел, җөмләдән, Мәскәүгә лояль тоелган Казакъстан да Җиңү парадын үткәрмәде.) Азатлыкка ирешкән халыкларның ми күзәнәкләреннән тоталитарлык махмыры чыгып бетүенә ышанасы килмәде. Бәлки, алар «сугышта җиңмәсәк, нишләр идек?» дигән сорауның тискәре ягын әйләндереп караганнардыр? «Җиңү безгә нәрсә бирде соң? Нәрсәгә ирештек? Нәрсә алдык? Урыслар түгел, без, нәкъ менә без – эстоннар, латышлар, литвалылар?.. Илебез бар иде, илебезне югалттык. Телебез бар иде, телебезне җуя яздык. Кансөяр империянең шул ук коллары булып калмадыкмы? Хокуклар кимегәннән-кими бармадымы? Җиңүчеләр исәбендә торып, юкса!» Алар бу мәсьәләне чишеп, үзләренчә дөрес нәтиҗә чыгара алган. Шул хакта ук «өч (бишне теләмисеңме!) йөз ел мескен булып торган» татарыбыздан да сорасаң булыр иде. Дөресе, сорадым да бугай инде. Берәр кайчан, намусы белән бергә-бер калгач, аңа да бу сорауларга җавап бирергә туры киләчәк...

Бактың исә, ни хикмәт: асылда, бу Җиңү «бердәм» совет халкын берләшергә этәрмәгән, киресенчә, туп тавышлары тынып калгач, «яраларны бәйләп яткан арада» һәркем үзен үгисетелгән сыман хис иткән түгелме соң? Украиннар, мәсәлән, Алексей Берест кебек угыллары өчен әрнегән (Кызыл байракны Рейхстагка кадаучыларның «рәсми» исемлегендә ул да бар, әлеге «операциягә җитәкчелек тә итә» әле, әмма бүләкләгәндә читтә кала), без – Гази Заһитовлар өчен... Лаек булып та, сугыш азагына таба «каһарман» исеме алмаган каһарманнар өчен. Рәнҗетелүчеләр беткәнмени? Ә чеченнар? Балкарлар? Кырымтатарлар? Берлин ишекләрен тибеп ачар вакыт җиткән көндә дуңгыз ташый торган вагоннарга дыңгычланып сөргенгә олактырылуларын ничек искә ала икән алар?

Әмма аннан да кызганычы: бу ил үзе канга батмыйча һәм башкаларны канга батырмыйча яши белми. Кайсы буынның сугыш күрми үскәне булды? Узган гасырдагы афәтләрне өстән-өстән генә санап үтик (Япония, Испания, Корея, Вьетнам, Ангола, Алжир кебек «вак-төяк» кампанияләрне исәпләмичә): бабайларның этиләре Беренче Бөтендөнья сугышында кырылды, бабайлар – Бөек Ватан сугышында, этиләр – Әфганстанда, абыйлар – Чечняда... Ә без? Ә улларыбыз? Күпме көннәр күрше-тирә тыныч түгел әнә: Донбасс, Сүрия... Безгә яу беркайчан да килмәячәк дип ант эчү самимилеккә тиң. Шырпы белән уйнарга яратучы бала берәр кайчан янгын чыгармый калмый ул... Кулына сукмасаң. Аллам сакласын! ■

Нурланыш галиме

(Ш.Ш.Ибраһимов – галим, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе)

Мурат Кәримов*

*Мәшһүр физик, техник фәннәр докторы **Шәүкәт Шиһабетдин улы Ибраһимов** (1923-1989) турында аның якыннары, укучылары һәм дуслары тарафыннан Казакъстанда байтак язылды. Әмма минем, чыгышы белән үзенә якын булган даирәгә дә аз мәгълүм мөхтәрәм шәхес, якын дустымның тормыш сәхифәсендәге кайбер вакыйгалар турында сөйлисем килә. Галим, үзе җитәкләгән институтны бөтен дөньяга таныту өстенә, күренекле җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе, милләтпәрвәр шәхес, кайгыртучан ир һәм әти, яхшы дус һәм чын мәгънәсендә затлы Кеше иде.*

ГАЛИМ

Шәүкәт Ибраһимов 1923 елның 22 октябрендә Казан каласында туа. 12 нче татар урта мәктәбен тәмамлагач, армия сафларына чакырыла һәм Оренбург артиллерия училищесына җибәрелә. Соңрак, тиф авыруын эләктерүе сәбәпле, демобилизацияләнә. 1943-1948 елларда Казан авиация институтында укый. Аннары Казан авиация заводының лабораториясендә хезмәт итә. Тора-бара фәнгә тартыла: 1952 елда Мәскәү дәүләт корыч һәм эретмәләр институтының аспирантурасына укырга керә. 1955 елда «Никель нигезендә каты эретмәләрдә структур үзгәрешләр» дигән темага диссертация яклаганда формулалар ярдәмендә кара тактаны язып тутыру белән генә чикләнми, фәнни нәтиҗәләрен институтның диварына да акбур белән төшерә башлый. Яшь белгечнең кызыксынуы, хирыслыгы, сораулар алдында каушап-югалып калмавы олпат галимнәрне шаккатыра, нәтиҗәдә диссертация уңышлы яклана. 1956 елда физика-математика фәннәре кандидаты Ш.Ибраһимовны Атом энергиясен файдалану буенча дәүләт комитетының Обнинск шәһәрендәге Физика-энергетика фәнни-тикшеренүләр институтына фәнни хезмәткәр итеп җибәрәләр. Бераздан аны биредәге лабораториягә мөдир итеп билгелиләр. 1965 елда нурланышка каршы торучан материаллар турында докторлык диссертациясен яклый.

---

* **Мурат Габделхәй улы Кәримов** – Казакъстан онкология һәм радиология фәнни-тикшеренү институты профессоры, медицина фәннәре докторы.

Сулдан уңга: академиклар Шәүкәт Ибраһимов, Анатолий Александров, Казакъстан ССРның Министрлар Советы Рәисе Нурсолтан Назарбаев, академиклар Иван Частников (арткы планда), Әскәр Кунаев

Казакъстан ССР ФАнең 1957 елда оешкан Тош** физикасы (урысчасы – ядерная физика) институтында фәнни-тикшеренү эшләре зур авырлык белән бара. Казакъстан коммунистлар партиясе ҮКның беренче секретаре Динмөхәммәт Әхмәт улы Кунаев (1912-1993), институттагы хәлне яхшырту өчен, СССР ФА Президенты А.П.Александровка житәкче-галим тәкъдим итүләрен үтенеп мөрәҗәгать итә. А.П.Александров әлеге җаваплы вазифага яшь, әмма инде галим буларак өлгереп җиткән Шәүкәт Ибраһимовны тәкъдим итә. КазССР ФАнең чакыруы буенча, 1969 елда галим Алма-Ата шәһәренә китә, институт, коллектив белән таныша һәм... директорның фәнни эшләр буенча урынбасары булып эшләргә ризалык бирә. Бу вазифада ике ел чамасы эшләгәннән соң, 1970 елда аны Тош физикасы институты директоры итеп тәгаенлиләр. Шул ук елда Ш.Ибраһимов – КазССР ФАнең хакыйкый-әгъзасы (академик), 1974 елда вице-президенты итеп сайлана.

Академик Ш.Ибраһимов һәм аның укучылары тарафыннан яңа физик күренешләр ачыла. Металл, корыч һәм эретмәләрнең нурланыш тәэсирендә ашалуы, агучанлыгы, күләм ягыннан үзгәрүе, уалучанлыгы, чыдамлыгы, сыйфатларындагы тайпылыш закончалыклары тикшерелә.

Тош физикасы институты галимнәренең металл һәм металл корылмаларның нурланыш тәэсирендә зарарлануы һәм моны булдырмый калу чаралары турындагы фәнни нәтиҗәләре атом реакторлары төзегәндә, илнең энергетика һәм халык хуҗалыгында зур роль уйнады. Шул хезмәтләре өчен Ш.Ибраһимов һәм аның хезмәттәшләре КазССРның Фән һәм техника өлкәсендә

** Тош – Р.Әхмәтҗановның 2 томлык «Этимологик сүзлеге»ндә әлеге сүзнең «тош» булуы дәлилләнә.

дәүләт премиясенә лаек булды. Академик атом-төш реакторларын фәнни-тикшерену, файдалану буенча ике, металл һәм эретмәләрдә радиацион дефект мәсьәләләренә караган дүрт Бөтенсоюз киңәшмәсе һәм Мёссбауэр эффектын файдалану турында бер Халыкара конференция уздырды. Германия, Польша, Венгрия, Һиндстан, Бельгия һәм АКШта узган Халыкара симпозиум һәм конференцияләрдә чыгыш ясады. Франция, Италия, Финляндия кебек илләргә лекцияләр укырга чакырылды, Казакъ дәүләт университеты профессоры буларак, үз белгечлеге буенча студентларга белем бирергә дә өлгерде. Ш.Ибраһимов Казакъстан өчен 32 фән кандидаты һәм 12 фән докторы әзерләде. Галимнең 250дән артык фәнни хезмәте, монографияләре басылып чыкты.

Кунаевларның да олуг галимгә хөрмәте һәм ихтирамы чиксез булды. Шәүкәт абыйга мине бертуган мәшһүр галим-академиклар Динмөхәммәт һәм Әскәр (1929-1999) Кунаевлар белән таныштырганы өчен рәхмәтлемен. Әлеге өч мөхтәрәм академик тормышымда гаять зур роль уйнады, мин алардан күп нәрсәләргә өйрәндем.

ДӘҮЛӘТ ҺӘМ ҖӘМӘГАТЬ ЭШЛЕКЛЕСЕ

Шәүкәт Ибраһимов Татарстан һәм Казакъстанның дәүләт эшлеклеләре белән даими аралашып яшәде. Мин аның ТАССР Өлкә комитетының беренче секретаре Фикрәт Әхмәтҗан улы Табиев белән дә дустанә мөнәсәбәтен яхшы беләм. Төрле сәяси сәбәпләр аркасында, СССР белән Әфганстан арасында мөнәсәбәт суынгач, СССРның Әфганстандагы илчесе итеп Ф.Ә.Табиев тәгаенләнә. Илче билгеләнгән урынга барганда Алма-Атада тукталды. Аны СССРның иң көньягындагы аэропортта Динмөхәммәт Кунаев, аның хатыны Зөһрә Шәрип кызы (татар милләтеннән), берничә министр, Шәүкәт Ибраһимов һәм мин каршы алдык. Шулвакытта ике Казан кешесенең, якташлар буларак, ихлас аралашуы, җылы мөгамәлә белән саубуллашуы исемдә калган.

Шәүкәт Ибраһимов КазССР Югары Советының ике чакырылыш (1981-1986 елларда) депутаты булды. Бу эшендә ул барлык сайлаучыларының да мәнфәгатен якларга тырышты, Тош физикасы урнашкан һәм аның хезмәткәрләре яшәгән бистәне халык өчен уңайлы итүгә, анда юл салдыруга иреште. Галим, дәүләт эшлеклесе буларак, Алма-Ата шәһәренең Фрунзе районы партия комитеты бюросы әгъзасы да иде.

1989 елда, милли сәясәттә уңай мөмкинлекләр тугач, Алма-Атада яшәүче милләттәшләребез тарафыннан татар иҗтимагый-мәдәни үзәге ачылды. Әлеге эшнең башында отставкадагы полковник Шәриф Госманов торды, без дә Шәүкәт абый белән аңа кушылдык. Тәүге җыелышларның берсендә мин академик Шәүкәт Ибраһимовтан үзәкнең җитәкчесе буларак сайлануын үтендем. Әмма ул бу фикергә Академиядә (вице-президент) һәм институтта (директор) эшләрем күп, дип каршы килде һәм әлеге вазифага, Татарстан һәм Казакъстанның дәүләт, җәмәгать һәм сәнгать эшлеклеләре белән тыгыз элемтәдә торуымны искә алып, мине тәкъдим итте. Мин җитәкче итеп сайлангач та, ул даими рәвештә безнең иҗтимагый-мәдәни үзәк белән элемтәдә торды, Татарстаннан чакырылган артистлар, язучылар катнашындагы һәрбер мәдәни чарага да килде, татар телен, мәдәниятен, мәгарифен үстерүгә бәйле утырышларда үзенең саллы фикерен әйтте.

Шәүкәт Ибраһимов татар сәнгатенә мөкиббән иде. 1973 елда Алма-Атага Татарстаннан композитор Нәҗип Җиһанов җитәкчелегендә бер төркем сәнгать әһелләре килде. Алар арасында Нәҗип абыйның хатыны – «Зөһрә» балетының либретто авторы Нина

Сулдан уңга: академик Шәукәт Ибраһимов, Наилә Кәримова, профессор Мурат Кәримов, доцент Галина Надирова, академик Надир Надиров. Нальчик, 1980 нче еллар

Җиһанова, Татарстанның халык артистлары Зилә Сөнгатуллина һәм Хәйдәр Бигичев та бар иде. Шулвакыт Шәукәт абый миннән Нәҗип Җиһановны артистлары белән үз квартирасына кунакка чакыруымны үтенде. Шәукәт абыйның хатыны Әлфия Гаяз кызы, кызлары һәм минем хатыным Наилә ханым казанлыларны татар милли ашлары белән сыйлады. Кунаклар биредә үзләрен мәшһүрләр кебек түгел, ә якын туганнарча тотты. Зилә ханымның «Җидегән чишмә» җырын һәм «Алтынчәч»тән арияне, ә Хәйдәр әфәнденең «Алтынчәч» һәм «Муса Җәлил» операларыннан арияләр башкаруы, әлеге операларның авторы Нәҗип абыйның рояльдә уйнавы күңелдә мәңгелек якты нур булып уелып калды.

Шәукәт Ибраһимовның тагын бер татар зыялысы белән мәдәни элемтәсе турында әйтәсем килә. Мәскәүдә Әхмәт Китаев (1925-1996) исемле гаять талантлы рәссам яшәде. Рәсем сәнгатен яратучыларга ул Советлар Союзы җитәкчеләре тарафыннан Белоруссиягә бүләк ителгән «Халыклар дуслыгы», Муса Җәлил турындагы «Моабит төрмәсендә» исемле картиналары һәм Кустанай шәһәрендә иҗат иткән Геройлар аллеясы белән мәшһүр. Шәукәт абый мине әлеге мөхтәрәм шәхес белән дә таныштырды, безгә рәссамның Мәскәүдәге остаханәсендә дә булырга, иҗаты белән хозурланырга туры килде. Әхмәт Китаевның оста портретчы икәнен истә тотып, Ш.Ибраһимов аны Алма-Атага, Динмөхәммәт Кунаевның портретын ясарга чакырды. Әлеге сәнгать әсәрен без дәүләт эшлеклесенең 70 яшьлек туган көненә бүләк иттек.

СПОРТЧЫ

Шәукәт Шиһабетдин улы спортны яратты. Нурланышны өйрәнүче галимгә даими хәрәкәттә булуның аеруча кирәклеген яхшы аңлады, шунлыктан, гимнастика, теннис, йөгерү, чаңгы һәм тимераякта шуу белән шөгыльләнде, балык тоту һәм альпинизм белән мавыкты. Шәукәт абый Кыргызстандагы Ыссык (Эссе) Күлгә ял итәргә дә самолетта яки машинада түгел, ә үзенең хезмәттәш һәм альпинист дуслары белән тау-кыяларны кичеп җәяү бара иде. Аның белән Күлсәй һәм Ыссык-Күлдә балык тотуларыбыз сагынып сөйләрлек якты хатирә генә булып калды . ■

Мурат Кәримовның академик Шәукәт Ибраһимов турында сөйләгән истәлекләрен **beznenmiras.ru** сайтыннан һәм редакциябезнең **www.youtube.com** дагы махсус каналыннан карый аласыз.

Нурлы сәхнәдә ижат нуры

Әхтәм Зарипов

Бик катлаулы сәяси-фәлсәфи проблемаларны автор тормышчан драма телендә җәмгыять һәм хакимият белән индивид – шәхес арасындагы фикер көрәшендә күрсәтергә тырыша.

Мөхлисәнең чын йөзе тамашачыга дин, милләт язмышы өчен зарурилыктан җаваплылыкны үз өстенә алган мизгелләрдә ачыла. Бу мизгелләр Мөхлисәнең үҗәтлегеннән дә, чаялыгыннан да, тәвәккәллегеннән дә түгел, ә мәрхүм булган милли-дини каһарманнарыбыз васыятенә тугры калудан. Мөхлисәнең яшәү мәгънәсе – дин-милләт иркендә. Шунсыз аның шәхси иреге була да алмый. Милләтнең бер канаты дин икәнлегенә шиксез инанганлыктан, ул диннең сафлыгы, саклануы өчен гомерен корбан итә.

Шушы хис-тойгыларның барысына да ышандыра Дания Нурлы. Спектакльдән соңгы алкышлар шул ышандырганы өченме? Әллә Мөхлисәгә иярүгә өндәүме? Кул чабуларга кадәр мин залда тынлык урнашып, тамашачыларның бераз вакыт өнсез утыруларын көткән идем. Кая ул!!! Тамаша залында безнең бүгенге көн милләте иде шул. Ә безнең милләт күптән инде кулына килеп эләккән секстан белән чикләвек ватучы масса... Һай, алкышларга алданабыз да, шуның белән алдыйбыз да шул. Әле шуны максатларыбызга ирешүгә саныйбыз. Чорны фаҗигагә китергән концепцияләргә оста иллюстрация күрүе белән тамашачының канәгатьләнүе максатка ирешү була аламы? Юктыр, була алмыйдыр? Тормыш ситуацияләренә заманча иллюстрациянең сәнгати образ түгеллегенә тамашачының битарафлыгы, ә артистларны кул чаптырудан гайре башка нәрсә кызыксындырмавы – куркыныч авыруның билгеләре түгелме? Сәхнәдә бер эмоция фикер тудырырга өлгергәнче, аңа икенчесе өстәлеп, фикерләр бәрелешен «томалый» түгелме? Ә бит фикерләр бәрелешендә туган эмоцияләр генә яңа фикерләргә юл ача. Театр – тормышта очрау ихтималлы охшашлыкларда төрлелек, очрар төрлелекләрдә охшашлык табып шаккаттырырга тиеш түгелме? Минем тоемлавымча, «Үлеп яратты» спектакле мул эмоцияләр тудырудан ерак узмады. Ә Дания Нурлының Мөхлисәсе соңгы вакытта татар сәхнәсендә туган иң эмоциональ персонаж образы буларак күңелләрдә озак сакланыр. Милләт җанлы тамашачы аңа һәрчак рәхмәтле булыр.

Заманыбыз – хакыйкать эзләүгә имитация ясау авыруына дучар заман.

Башы журналның 8 нче санында.

«Фатыйма Сабрый».
Кыз ролендә

«Үлеп яратты» (Р.Зәйдулла) – Мөһлисә Буби

Моңа 70 ел буена көчләп сеңдерелгән кайбер традицияләрдән һаман арына алмавыбыз да сәбәптер. Милли-дини каһарманнарыбызны «Оптимистик трагедия» комиссарына, Зоя Космодемьянскаяга, яисә башка партизаннарга – яшь гвардиячеләргә охшатырга тырышу – шул традицияләр махмыры ул.

Кайсы театрда караганымны хәтерләмим, студент чакта Мәскәүдә Жан Ануйның «Жаворонок» («Сабан тургае») әсәре буенча куелган спектакльне күрү насыйп булды. Бу спектакль минем өчен театр сәнгатендә ирешү мөмкин булган фикерләр көрәшенә үрнәк буларак хәтердә саклана. Диалоглары – талашу түгел, мантыйктан чыкмыйча фикерләр көрәше. Декорацияләре дә, киемнәре дә шартлы.

Жаннаның халкы-милләте өчен шәһит китәргә карары, үзе әйткәнчә, аңа гына ишетелүче тавышларга буйсынудан түгел, ә кошчыкның бары тик зәңгәр күктә очып кына яши алгандай, аңа да җирдә яшәү мөмкинлеге калмагач, күккә ашып, «котылу» ихтималына төшенүдән. Ягъни үз акылы, үз йөрәге, намусы кушкан эчке тавышларга буйсынудан. Ә безнең Мөхлисәнең фаҗигасе, Жанна Д'Арк фаҗигасе белән чагыштырганда, тирәнрәк тә, әһәмиятлерәк тә. Мөхлисәсе белән Дания Сөембикә-ханбикә образына мөмкин булганча якынаеп, шул шәхесне җанландыруга әзер булуын күрсәтте. Кызгандыру, елату тәҗрибәсенә өстәмә тарихи персонажларга объектив позициядән карау иң мөһим шарт булуын да аңлавына шик юк.

Бүгенге Дания Нурлы, һичшиксез, иң бәхәсле язмышларны да сәхнәгә алып менәрдәй әзерлекле актриса. Бәхәс тудыра алу үзе дә талантлыларга хас сыйфат. Нурлы Даниянең төп мәктәбе – тормыш. Кирәк урынында ул усал да, ягымлы да, хәтерле дә, онытучан да, юк-барга игътибарсыз да, күзәтүчән дә була.

Аның катнашында Галимҗан Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр»е буенча радиопостановка әзерләгән

чак хәтердә. Ул, төрле маҗараларга юлыгып, иленә кайтып егылган, алданып бозылган бай кызы Зөһрә ролен башкарырга тиеш иде. Училищенең 2 нче курсында гына укучы кыз баланың бозык хатын булып уйныйсы килмәве бер сәбәп булса, икенче сәбәп – тавыш белән генә андый образны күрсәтү чите булачагы Данияне рольдән баш тартуга этәрә. «Уйнамыйм булгач, уйнамыйм!» – ди ул һәм текстны кайтара. Ялынып-ялварулар да, үгетләүләр дә нәтиҗә бирмәгәч:

– Ә син аны бозык итеп күрсәтергә тырышма. Бәхетсез ул. Бәхетле булырга лаек икәнен белә торып, алдануына үзен-үзе гаепләүче, үзенә-үзе җәза бирүче, – дим.

– Бәхетсезлегендә үзен гаепләгән кешене мин белмим. Һәр гамәле өчен кеше үзен аклый, – диде Дания һаман үзсүзләнеп.

– Аклау – яклау түгел, ялгышуларына сәбәп эзләү.

– Рольнең адвокаты булыргамы?

Шушы соравы белән Дания Зөһрә күңеленә ачкыч табуын күрсәтте:

– Әйе, алданудан кыяфәте үзгәрсә дә, күңелләре чиста кала аларның. Җан җәрәхәтләрен иң якын кешегә генә белдерәләр. «Уйныйм! – диде ул, кинәт кабынып. – Бикә апа белән Шаха апайның тәмәке пыскытып, кеше ишетмәслек кенә тавыш белән сөйләшеп утырулары үрнәгендә яраса, – уйныйм».

Һәм уйнады Дания. Бүген шул радиопостановканы тыңлагач, ул, үз уенына үзе ышанмыйча: «Минме соң бу?» – дип утыра. Бу аның «кылануы» түгел. Спектакльдә үзеннән «ерак китеп», холык-фигылен нык үзгәрткән рольләре күп аның. Шундый образларның берсе – «Миркәй белән Айсылу» спектаклендәге Айсылуы, икенчесе – Батулланың «Кичер мине, әнкәй» әсәре буенча спектакльдәге Дилфүзә. Айсылу роленә Данияне 3 нче составка билгелиләр. Спортчылар телендә әйткәндә, «запасной игрок». Миркәйне Таҗетдинов белән Әюпов алмашлап уйныйлар. Өченче составта булганлыктан, Даниягә Әюпов белән дә, Таҗетдинов белән дә парлашырга туры килә. Беренче, икенче состав Айсылулар дәрәҗәле – исемле артистлар булсалар да, һәр ике Миркәй Дания Айсылуы белән парлашырга тырыша. Тора-бара Айсылу Даниягә генә кала. Моңа, Миркәйләр теләгеннән дә бигрәк, тамашачыларның Дания Айсылуына мәхәббәте хәлиткеч роль уйнагандыр, дип беләм.

Ә инде артистканың бу рольгә мәхәббәте кызына Айсылу дип кушуында да күренә.

Шул гап-гади татар кызы роле белән тамашачыларны һәм партнерларын гына түгел, сәхнә эшчеләрен дә гашыйк иткәнлеген күрсәткән бер «хәл»не язып узсам, инде мәрхүм булганнар рухы рәнҗемәстер.

«Миркәй-Айсылу» спектакле бара. Гашыйкларның бүләк бирешү күренеше. Кочышу, үбешү ритуалы.

Шулчакта сәхнә артына карасалар, декорацияләр монтажлаучы Ирек боларга йодрык күрсәтә. Күзләре акайган, ачуы эченә сыймас хәлгә килеп, ярсыган. Тәнәфескә чыккач, йодрык күрсәтүенең сәбәбен сорасалар, Ирекнең җавабы катгый: «Озак кочакламасыннар, аны мин яратам».

Әюпов-Миркәй: «Син аны режиссерга әйтеп, мезансценаны үзгәрттер», – ди. Ирек режиссерга әйтергә җөрьәт итми, җыелышта сүз алып әйтә: «Кеше өлешенә кермәгез!» – ди.

Аның бу чыгышын чынга алучы булмаса да, шаяртырга җай чыгуны көтеп кенә утырган Шәүкәт абый Биктимеров: «Син, Ирек әфәнде, яратуыңны йодрык күрсәтеп исбатлама, үзең дә бүләк бир, үзең дә кочакларга җай эзлә!» – ди.

Ирек: «Миңа сәхнәгә чыгарга ярамый ич...» – дип аклана.

Шәүкәт абый: «Ә син сәхнә артында, Айсылуның ярдан суга ташланган чагында тотып ал да, шунда туйганчы коч Айсылуны!

Ирек: «Марсель абый рөхсәт итәрме соң?»

Шәүкәт: «Аны син Айсылудан сора!»

Декорация сәхнә артына таба биегәеп, елга ярына охшашлы итеп төзелгән. Айсылу шул «биек ярдан суга ташланырга» тиеш. Аска, су урынына, сикерүче имгәнмәсен өчен, йомшак матраслар, матылар түшәлгән. Спектакльнең финалы – Дания-Айсылу «суга ташлана...» Әмма Ирек кочагында булып чыга. Әдәпле, итәгатьле, сабыр кеше буларак, Дания бу «ЧП»дан тавыш-гауга чыгармый, бары тик сәхнә артында елмаеп торган Шәүкәт абыйга:

– Аны шаярткан кеше үзе дә 99лы ул, – дип, грим бүлмәсенә юнәлә. Шәүкәт абыйның җавабы икенче көн спектакленнән соң булганын беркем күрми дә, ишетми дә. Аны, бу шаяруларга ничә еллар узгач, Дания ханым үзе сагынып искә ала:

– Ул кичне спектакльдән соң грим бүлмәсенә күтәрелсәм, өстәлдә зур гына катыргы тартма белән чәчәк букеты тора. Кем кертеп куюын киендерүче Наилә апа күрмәгән. Ачып карасам, тартма эчендә йөз кат газетка төрелгән сабын кисәге! Нәкъ Миркәйнең Айсылуга биргәне кебек – исле сабын. Көлсәң – көләрлек, еласаң – еларлык, юктан кызык табып шаярулар, шунда катнашкан сәхнәдәшләр сагындыра хәзер.

Бүләкләр дә, чәчәк букетлары да, котлау-алкышлар да күп булды. Аларны алу күңелле булса да, иҗатка зыян китергәннәре дә очрады, нишләргә белми аптыраган хәлләрдә калган чаклар да булды. Барысына чик куеп, гаилә корырга, кияүгә чыгарга ниятләдем. Тик сайлаганым көнчел булып чыкты. Гаилә таркалмасын өчен театрдан китеп, радиода оператор булып эшләп алдым.

Сәхнә белән сихерләнгәч, аны ташлый да, оныта да алмагач, мин дә театрга кире кайттым. Үз иткән, артист иткән коллективым белән кабат кушылдым. Бу кушылуым ирем Фәрит белән аерылышуга китерде...

Кызымны ялгыз үстердем, дип әйтү гөнаһ булыр. Ул һәрчак минем белән театрда, артистлар арасында үсте. Артист булыр, дип уйлаган идем – табиблыкка тартылды, фармацевт булды. Кызымнан калган оныгыма да «театр җене» йоктыра алмадым ахры... Гомеремнең сәхнәдә – театрга, милләтемә кирәкле булып узуы белән кешеләрнең – мине, үземнең дә кешеләрне яратуым белән бәхетлемен.

Шушы сүзләрем финал сүзләре булып яңгыраса – мин бик риза!

– Финал дигәнең белән һич тә килешә алмыйм, Дания, – «Җырланмаган әле безнең җыр!..» – диген.

– Телевидение спектакльләрендәге рольләрем аз булу күңелне борчыйборчуын, тик борчылудан ни мәгънә?!

– «Ташкыннар»дагы Зәмзәмбануың, «Намус»тагы Мәпәң, япончадан тәрҗемә ителгән «Шантаж»дагы ханымның классик рольләр булуы белән горурлана аласың.

– Әйтәм ич: мин кешеләргә кирәк булуым, алар – мине, мин – аларны яратуым белән генә горурланам. Кешене эше зур итә, мәхәббәт яшәтә. Бүген Дилфүзә кабат сәхнәгә менсә, мин үземне яшьлегемә кайткан кебек тояр идем... Үзем уйнасам.

Даниянең бу сүзләреннән соң ни язсаң да артык булуын чамаласам да, яшьлек елларыннан бер хатирәне искә төшерми булмастыр...

Узган гасырның 60 нчы еллары

«Сөясеңме, сөймисеңме» (Ф.Бүләков) – Василә роле

иде ахры, яисә 70 нче еллар башыдыр. «Әни килде» спектакле белән озын-озак гастрольләрдә Әлмәт-Бөгелмә якларында йөрибез. Барасы ара ерак булганда гостиницадан иртәрәк чыгып, матуррак урыннарда туктап ял итәбез. Ир-егетләр, автобус туктауга, урманга кереп китә, хатын-кызлар, термосларын чыгарып, чәйләргә тотына. Электрик егетебез, ни өчендер, автобустан да төшми, чәй дә эчми – тып-тын утыра. Марзыя апаның моңа ачуы чыгып:

– Бар, кеше ашаганны карап утырма, төшеп мәтрүшкә җый... – димәсенме! Тынлык урнаша.

– Әллә нигә башым авыртып, күңелем болгана, бензин исе ярамады ахры, – ди егет.

Шунда Дания аңа ниндидер дару белән стаканга чәй салып бирде. Егет даруны кабып, чәй белән йота да, рәхмәт әйтеп, төшә, урманга таба атлый. Ул төшкәч, Марзыя апа:

– Кешегә салынырга осталар, – дисә, Гәүһәр апа Даниягә карап:

– Үзебез азындырабыз, – диде.

Галимә апа эндәшми генә утыра. Сүзгә катнашуымнан куркып, мин дә автобустан төштем. Ярты сәгать чамасы юандык. Габдулла абый Шамуков белән Шәүкәт абый, мәтрүшкәләр кыстырып, мунча себеркесе бәйләгәннәр, ә теге электрик егет бер кочак сары мәтрүшкә (зверобой) җыйган.

Иң элек өлкәннәр кереп утырыштылар. Ахырда сары мәтрүшкәле егет күтәрелде.

Марзыя апа: «Менә, молодец, критиканы аңладың», – дип, аннан букетны алырга кулын сузды. Егет аңа игътибар да итмәде – букетны Даниягә биреп:

– Хәлемә кергән өчен, – диде.

Көз җитеп, сезон ачылганда ул егет күренмәгәч, сорасам – бавыры авыруыннан мәрхүм булуын әйттеләр. Колагымда аның: «Хәлемә кергән өчен» – дигән сүзе һаман яңгырый кебек.

Дания Нурлының аны нурлы иткән төп сыйфатлары: кешеләрнең хәленә керә белү, ягымлылык, ихласлык.

Нурың сүнмәсен, сүрелмәсен, Дан иясе Фидания! ■

Илаһи моң иясе

(Фәридә Кудашева моңының серенә төшенергә омтылыш)

Филүсә Арслан

Бөеклекнең тылсым серләре дә
Шушы дәртле нәфис җырдадыр.
Якуб Колмый

Бик күп язучылар, шагыйрьләр, галимнәр, сәнгатькярләр, журналистлар, музыка белгечләре Татарстанның һәм Башкортстанның халык артисты, Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, сөекле җырчыбыз Фәридә Кудашеваның башкару осталыгына соклана, истәлек-мәкаләләрендә «Кудашева моңы»ның серен эзли, аны ничек тә табарга, аңлатырга тырыша. Үземне бу мәсьәләдә яңалык ачармын дип уйламыйм. Шулай да, музыка белеменә ия һәм вакытында хор-ансамбльләр, җырчылар белән эшләү тәҗрибәм булганга күрә, кулыма каләм алырга баздым. Минем дә балачактан ук Фәридә апа Кудашеваның сихерле моңы озата килде. Җырлавын пластинкалардан, соңрак радиодан тыңлап, аларны үзем дә өйрәнеп, җырлый-җырлый сәнгать дөньясына кереп киттем.

Әйе, Нажар Нәҗми әйткәнчә, Фәридә Кудашеваның башкару сәнгате турында мәкалә язу үтә кыен, чөнки аны тыңларга, йөрәк белән тоярга кирәк. Аңа бәя бирү дә җиңел түгел, чөнки аның сәнгате үзе башкаларны бәһаләү үлчәме дәрәҗәсенә күтәрелгән сәнгать.

Менә үзем «илаһи моң иясе» дип яздым да... уйга калдым. Илаһи моң иясе бер Аллаһы Тәгалә генә түгелме соң? Һәр җырчының үз моңы. Әмма Раббыбыз моңны теләгән кешесенә мул итеп бирә, теләмәгәненә бөтенләй бирми, югыйсә.

Әүлияләр тарихыннан бер мисал китерәсем килә: Давыт пәйгамбәргә Аллаһы Тәгалә могҗизага тиң искиткеч гүзәл тавыш биргән. Ул үзенә иңдерелгән китапны укыганда кошлар – очуыннан, сулар – агуыннан, җилләр исүеннән туктаган. Аны бөтен дөнья таң калып тыңлаган, аңа кушылып бөтен дөнья илаһны зикер кылган... Бәлки, Фәридәбезнең тамырлары да шул Давыт пәйгамбәргә барып тоташадыр? Ф.Кудашева Аллаһ тарафыннан бирелгән олуг бүләкне газиз халкы белән бүлешә...

Хак Тәгалә аңа, табигый сәләт өстенә, зиһен дә биргән. Репертуары бай булу – өч меңләп җырның сүзләрен, көйләрен истә калдыру – мөкәммәл ишетүгә өстәп, әле тагын зиһен-зирәклек күрсәткече дә түгелме? Җырчыны – җыр, җырны – җырчы күтәрә, дибез. Репертуарының төзелеше дә матурлыктан һәм моңнан

Рөстәм Яхин, Айрат Арсланов, Фәридә Кудашева

яратылган шагыйрьләрнең (Г.Тукай, Х.Туфан, С.Кудаш, Ә.Атнабаев, Ш.Биккол, М.Кәрим, Н.Исәнбәт, Г.Зәйнәшева һ.б.) сүзләренә шундый ук композиторлар (С.Сәйдәшев, М.Мозаффаров, С.Садыйкова, З.Исмәгыйлев, Ф.Әхмәтов, М.Макаров, Р.Мортазин, Ф.Әхмәдиев, Б.Гайсин һ.б.) иҗат иткән җырлардан тора. Шагыйрьнең, көйченең һәм җырчының сагыш-гамьнәре гомумкешелек сагыш-гамьнәре белән кушыла.

Ф.Кудашеваның җырлау осталыгы белән моң төшенчәсен үзара аерып карап булмый. Һәр кешенең тавышы үзенә генә хас тембрга ия. Фәридә ханымның тембрын көчле диеп булмый, әмма ул кабатланмас, үзенә генә хас төсле-бизәкле, яңгырашы буенча ягымлы, җылы, якты... Мондый сыйфатларга ия тавыш үзгәртүгә, төзәтүгә бирелми. Ясалма юл белән тавышны көчлерәк, сулышны киңрәк итәргә була, әмма тембрны моңлырак итү мөмкин түгел: бәллүр савытны тагын да матурлатам дип челпәрәмә китерүгә тиң бу. Фәридә ханым үзенә бирелгән табигый тавыш тембрын бозмыйча, аны гомере буе саклап эш итә белде.

Вокаль осталыкның иң мөһим күрсәткече – дөрес сулыш алу – җырлау тынын үзләштерү, аңа ия булу. Ф.Кудашевага тын алу осталыгы табигатьтән бирелгән, дип әйтеп булмый. Ул аңа зур тырышлык, күнегүләр, күпьеллык тәҗрибә аркылы ирешкәндер. Фәридә ханымның сизелер-сизелмәс кенә алган тыны озын көйләрдә дүртьюллы куплетның бер юлына тулысынча җитә, ә кыска көйләрдә хәтта тулы бер куплетка җиткәне бар. Аның озын көй башкарганда (язмаларын тыңлап карагыз) сүз уртасында тын алуын очратмассың.

Җырчының сәхнәдә үзен иркен, гади тотышы да тамашачыны җәлеп итәргә булышкандыр. Табигыйлек, гадилек, эчкерсезлек... Мондый иҗатның сере бербөтен гармоник

камиллектә, дияр идем. Чын иҗатчы һәрьяклап гармоник камиллеккә омтыла.

Ф.Кудашева, халыкчан башкаручы буларак, сулыш алуда, нигездә, күкрәк ысулын куллана. Аның тавышы обертоннарга бай. Тембр обертоннар белән генә түгел, вибрато (тавыш җепселләренең җиңелчә тирбәлүе) белән дә билгеләнә. Вибрато тавышның «очучанлыгын» – ераккарак ишетелү сәләтен арттыра, куәтли. Резонаторлар дөрес эшләгәнгә, көчле булмаган тавыш та тамаша залының иң соңгы рәтләренә кадәр барып җитә, анда да үзгәрмичә, табигый тембрда ишетелә. Бәллүрдәй чиста, яңгыравыклы, «оча торган» тавышка ия Фәридә ханым...

«Җыр-көй һәм аны башкару – һәр милләт өчен үзенчәлекле әйбер, татар җырлавында да үзенә генә хас йолалар, үзе яраткан алымнар, манералар бар, – ди күренекле әдибебез Нәкый Исәнбәт. – *Андагы моң техник момент кына түгел, ул халык җыр-моң традициясе белән дә бәйле бер нәрсә. «Моң»ны кайгы-сагыш мәгънәсендә аңларга ярамый. Моң ул халыкның күңел ихтыяҗын үти. Җырчының осталыгы озын көйләрне җырлый белүендә сынала»*, – дип үз фикерен белдерә. Безнең халыкка Фәридәнекедәй көчәнүсез, йомшак, тигез яңгыраган моң хас та инде! Бөегебез Тукайның да: *«Безнең бер көйне татар булмаган бер кешедән җырлатсаң, көемезнең алтынын кояр шикелле тоела... Халык җырлары үзенең мөһмәлияте вә җитешсезлекләре белән бергә, әлбәттә, үземезгә генә сөекле булырга тиеш һәм сөекле дә»*, – дигән төпле фикере белән килешмәү мөмкин түгел. Ә Ф.Кудашева – халык көйләре җырчысы. Аның киң диапазонлы, озын сулыш таләп итә торган җырларны югары кимәлдә башкаруы сокландыра.

Фәридә ханым башлыча лирик

СИБГАТ ХӘКИМ,
Татарстанның халык шагыйре, Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты

Фәридәне мин тыныч кына тыңлый алмыйм, гел эчтән елыйм, җирем, тарихым, халкымның бөтен узганы алга баса, әнкәй күз алдына килә, аның тавышын ишетәм, саф татар теле, андый тел белән җырлаган бер генә җырчы да юк. Телендә аның бөтен моң!

ИЛБАРИС НАДИРОВ,
фольклор белгече, Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты

Аның моңында җанны тергезә торган яктылык, тылсым бар. Ул моңда кайгы-сагышлар бергә үрелгән, бергә ишелгән.

МӘХМҮТ НИГЪМӘТҖАНОВ,
фольклорчы, музыка белгече, Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты

Фәридә Кудашеваның башкару сәнгате, әлбәттә, башка җырчылар өчен үзенә бер эталон. Репертуарга таләпчәнлеге дә үзенә генә хас, үзенә генә лаек кабатланмас осталык, стиль, үз йөзе. Милләтебезнең милли моңнарын саклап килүче сәнгать белгечләренә өйрәнер өчен бетмәс-төкәнмәс чыганак.

РАФАЭЛЬ ИЛЬЯСОВ,
җырчы, Татарстанның халык артисты

Фәридә Кудашеваның җырлавы, аның ягымлы, йөрәкләрне иркәли торган моңлы тавышы һәркемнең – өлкәннәрнең дә, яшьләрнең дә – күңел түрендә, бәгырендә. Халкыбыз көйләрен, композиторларыбыз җырларын үзенә генә хас халыкчан моң белән җырлап, ул һичкемне кабатламый торган мәшһүр башкару остасы булып, бөтен мөселман дөньясына танылды. Фәридә апаны мин безнең газиз ана телебез сагында торучы фидакяр, көрәшче җырчыбыз дип бәялим.

җырларны үз итә, әмма ул аларны төшенке рухта түгел, ә бәлки тормышка ышанучан, оптимистик төсмерләрдә бирергә омтыла. Һәр җыры үзенчә, һәр җыры үзенә күрә бер мини-спектакль.

Җырчы колоратур бизәкләрне дә үзенчә – Фәридәчә ала. Сузык һәм тартык авазларның тигез бәйләнеп, бер-берсенә үрелеп баруыннан табигый легато барлыкка килә. Фәридә ханым глиссандо алымын да урынлы куллана, аның моңлы авазы ясалма эффектлар кулланмыйча да тыңлаучыны елатырга мөмкин.

Ф.Кудашева еш кына баянга, курайга, аккордеонга кушылып җырлый, нәтиҗәдә алар офертенгә әверелә: әйтик, «Туган тел»нең азагында, синтезатор һәм фортепиано аккомпанементына ияреп, җырчының тавышы, космик аһәңгә әйләнеп, күкләргә китеп югала кебек...

Аның башкаруында ярдәмче тавышлар, яңгыраш паузалары куллану, кайбер сүзләрне диалекталь шәкелдә җырлау («ал булмай, булмай...»), «и» һәм кайбер авазларны «ачыграк» һәм «йомыбрак», кайбер урыннарда борын авазы җибәрү – болар барысы да, яңгырашка хилафлык китермичә, тавышны аерылып торган тембраль буяуларга баета. Аһәңне чаманы югалтмыйча филировкалау да аңа ят түгел. Мондый алымнар җырлауны бизи, аны җанландыра, динамик палитрасын баета, тавышны тәэсирле итүгә китерә. Җырларда, бигрәк тә композиторлар әсәрләрендә, ул вокализлар кертеп җибәрә, бу алым лирик әсәрне драматик яңгырашка якынайта.

Зифа Басыйрова, Әлфия Авзалова, Абдулла Солтановлар кебек, Фәридә Кудашева да консерваториядә яисә музыка уку йортларында махсус белем алмаган. Ә ничә буын җырчылар аларча җырларга тырышты! Фәридә дә – бердәнбер, кабатланмас моңы белән (исеме дә гарәпчәдән «бердәнбер», «кабатланмас» дигәнне аңлата) тулы бер вокаль мәктәп булдырган җырчы. Бер әңгәмәсендә: *«Мин, музыка белемем булмаса да, халыкча җырлауга укыта алыр идем,* – ди ул. – *Элек-электән татар-башкортта халыкча җырлауның телдән телгә, авыздан авызга өйрәтү методы кулланылган һәм алар җырлауның милли мәктәбен булдырганнар».*

Фәридәнең җырлау осталыгын баетуда, аңа яңа төсмерләр кертүдә хәләл җефете – оста музыкант, композитор, башкаручы солист, яхшы аккомпаниатор Бәхти Гайсин да зур роль уйный. Ул җәмәгате җырлаганда аның тын алышына, авызын ачуына, күз карашына кадәр тоя. Талантлы музыкантның аккордеонда уйнавын беркем белән дә чагыштырып булмый.

Нәкый Исәнбәт һәм Хәсән Туфан уртасында. Казан, 1984 ел

Композитор буларак, татар, башкорт фольклорының борынгы үрнәкләренә нигезләнгән җырларын тыңласаң, һәр әсәренең халыкчанлылыгын һәм заманча яңгыравын таныйсың.

Ф.Кудашеваның аккомпаниаторлары күп булмый. Иҗатының башлангыч чорында бик үзенчәлекле композитор, баянчы Таһир Кәримов белән хезмәттәшлек итә ул. Әүвәлге аудиоязмалары да Т.Кәримов белән яздырылган. Төрле вакытта баянчылар Әлфәрит Солтановка, Рәис Сафиуллинга, курайчы Азат Аетколовка, Бәхти Гайсин җитәкчелегендәге инструменталь ансамбльгә, фортепианода Александр Ключаревка, Радик Хәбибуллинга, Рөстәм Яхинга кушылып җырлаган ул. Бу аккомпаниаторлар җырчыга комачауламый, аның белән бердәй гармоник дуэт тудыралар.

Ни кызганыч, татар музыка сәнгатендә соңгы елларда поэтик һәм көй ягыннан җитешсез, һөнәри дәрәҗәсе зәгыйфь җырлар өстенлек алды. Җырчылар – «композитор», композиторлар «җырчы» булды. Профессиональлек югалды. Югыйсә, Фәридә Кудашевалар кебек иҗатчылар «табасыннан» төшкән әсәрләрне тамашачы өзелеп көтә, аларны күтәреп ала һәм яттан өйрәнә иде. Чын композиторлар, чын җырчылар, чын шагыйрьләр бар иде...

Фәридә Кудашева – бүгенге көн башкаручылары өчен бәяләп бетергесез энциклопедия. Аның җырлавында сакланып калган язмаларны тыңлап, «моң» төшенчәсен аңларга, музыкаль фразаларны дөрес төзергә, татар-башкорт җыр сәнгатен тирәнтен өйрәнергә мөмкин; тын алу культурасы, татар-башкорт мелизмнарын берберсеннән аерып, аларны чама белән генә куллану, халык җырларын артык «чүптән» арындыру эшендә өлге булырлык хәзинә ул. ■

Остазым Бакый Урманче

Надир Әлмиев

Кешегә яшәгән саен тормышының мәгънәсен аңларга тырышу хас. Мин дә шундый. Дистә еллар буе янәшәсеннән узып йөргән агачларга ешрак күз ташлыйм хәзер... Аларга карап уйга биреләм... Куркыныч сугыштан соңгы авыр елларда туган бала буларак, ул заман хатирәсе – соры Казан, туган йортым, уйнап үскән ишегалларым – хәтеремә ишелеп кенә төшә. Вакыт, тарихи чорларны алмаштырып, фасылларны кабатлап ага тора, ага тора, агач кәүсәсенә боҗралар өсти; баштан узган вакыйгалар, кадерле истәлекләр булып, хәтергә ята.

Бакый Урманче Казанга кайткач. 1957 ел

Артист әти белән музыкант әни *(Усман Әлмиев белән Разия Фәйзуллина. –* **М.Т.***)* гаиләсендә туганга күрә мин, ихтимал, театрда яшьтәшләремә караганда күбрәк булганмындыр. Әти еш кына репетициягә яисә яңа куелышка, хәтта кичке тамашага да ияртеп бара иде.

Композиторлар, рәссамнар, актерлар һәм шагыйрьләр – балачагымның аерылгысыз өлеше булды. Александр Ключарев, Җәүдәт Фәйзи табадан гына төшкән әсәрен күрсәтергә килә иде. Салих абый Сәйдәшевкә, киресенчә, репетициядән соң үзебез керә идек. Ул вакытта Камал театры белән Опера театры бер урында – хәзерге Тинчурин театры бинасында урнашкан иде, алар көнаралаш эшләде: бүген опера уйналса, иртәгә драма куелды. Салих абый шул ук йорттагы бер бүлмәдә торды. Ул гаять киң күңелле, ягымлы кеше булып исемдә калган. Зәңгәрсу күз, мәгънәле караш. Сатуда

«Йөзем җыю». 1958 ел

һичкайчан күренмәгән татлы конфетлар белән сыйлый иде мине. Мөгаен, бу нигъмәтләрне күчтәнәчкә китергәннәрдер – аны халык бик ярата, үз итә иде.

Бәйрәм саен Нәҗип Җиһанов, Рөстәм Яхин, Мостафа Ногман, Айрат Арслан, Камал театрының карт артистлары (ул вакытта барысы да яшь әле) сугылмый калмый иде. Кыскасы, фатирыбыздан талантлар өзелмәде. Бу сөхбәтләшүләр үсмер елларымны нурга күмде һәм күңелемнең иң җылы почмагына мәңгегә урнашты.

1957 елда Мәскәүдә узган Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы көннәрендә әти-әнием Бакый ага Урманче белән таныша. Аның пайтәхеттә яшәгән чагы була. Әти-әнием сынчы-рәссамны Казанга күчәргә, монда иҗат итәргә чакыра. Шул рәвешле Бакый ага татар дөньясының мәркәзенә кайта. Күченү мәрәкәләрен бик яхшы хәтерлим әле. ТАССРның Мәдәният министрлыгы (Хаҗи Рәхмәтуллинның министр чагы) аны, кунакханә урынына, хөкүмәт әгъзалары гына ял итә торган «Ливадия» шифаханәсенә урнаштыра. Бераздан бирегә материаллар агыла башлый – мәрмәр кисәкләре, агач кәүсәләре... Аерата Урта Азия грушасы хәтердә калган. Чөнки соңыннан ул могҗизалы рәвештә «Сагыш» сынына әверелде һәм минем бу сынны бар итүдә турыдан-туры катнашым булды. Груша буй-буй ярылы, аны, эшкә ярарлык хәлгә китерер өчен, шундый ук материал белән ямарга кирәк иде. Чырага келәй сылыйм да, ярыкка сугып кертәм, аннары, кибеп чыккач, шомар-

тасы гына кала. Башка кәүсәләр дә «эшкәртү» уза. Агач белән мәш килү миңа бик ошый иде. Шулчакларда уеп бизәк ясауның тәүге серләренә төшендем.

Бакый ага безгә көнаралаш килеп йөрде. Йә Министрлар Советына, йә Мәдәният министрлыгына, йә Рәссамнар берлегенә барышлый кереп чыга... Дусларының хәлен-әхвәлен белешә. Ә болай бик күп эшли иде ул. Бик бирелеп эшли иде. Вакытын юк-барга әрәм итмәскә тырышты. Озакламый аңа Ленин районындагы Производственная урамында төзелгән йорттан фатир бирделәр. Бер бүлмәсен остаханә итте. Тагын күпмедер вакыт узгач, Бакый ага коттеджлы булды, анысын сыннар ясау остаханәсенә әверелдерде. Зур скульптуралар сыйсын өчен идәннәрне кубарырга, җирне метр ярым казырга, ә түшәмне күтәрергә туры килде.

Шулай да, күңелен бушатырга кирәк чакта, Бакый ага элеккечә безгә йөрде. Ул Соловкида Мәскәү һәм Ленинград профессорлары, дин әһелләре белән бергә иза чигүен искә төшерде, «анда бер генә җинаятьче дә юк, барысы да интеллигенция вәкилләре иде», дип хәтерен яңартты.

...Берничә ел «утырганнан» соң, Бакый ага Казанга кайта, сәнгать техникумында (монда, булачак рәссамнардан тыш, музыкантлар, артистлар, композиторлар әзерлиләр) эшли. Әмма бәхетле мизгелләр озакка бармый: бераздан аны яңадан сөргенгә – бу юлы Урта Азия республикаларына сөрәләр һәм... 1956 елда, диктаторның вафатыннан соң гына аклыйлар.

Бакый ага торган йортта еш булдым мин, үзеңне алтын куллы останың ярдәмчесе итеп тою (балчык изү, пластилин шарчыклар әзерләү, гипс измәсе ясау) йөрәгемдә һәрвакыт чиксез горурлык хисләре уятты. Эш коралларының байтагын ул үзе ясаган, арада Алманиядә җитештерелгәннәре дә бар иде. Чимал буларак, нигездә, мәрмәр белән агачны үз итте. Күпмедер вакыт узгач, остаханәгә Урта Азиядән берничә дистә скульптура, шактый гына санда картина кайтты (бүген алар Татарстан Республикасының Сынлы сәнгать һәм Бакый Урманче музейларында, шулай ук «Хәзинә» галереясында саклана).

Сәнгать училищесына укырга керүемдә Бакый аганың турыдан-туры катнашы булды – Виктор Иванович Куделькиннан (директор) мине ирекле тыңлаучы сыйфатында әлеге уку йортына кабул итүне сорады ул. Уку чорының кыл уртасы, кыш көне иде. Җиң сызганып «энә белән кое казырга» керешкәч, Бакый ага һәр эшемне җентекләп күзәтеп барды, киңәш-табыштан аермады. Билгеле, аның һәр әйткәне осталарча төгәл, урынлы иде.

Башкортстан буйлап сәяхәт кылганда да Бакый агадан күп нәрсәгә өйрәндем мин: җирле хакимият җиңел машина биреп, без Дүртөйле районында урнашкан татар авылларының тормыш-көнкүреше белән танышып йөрдек. Рәссам борынгы агач архитектура үрнәкләрен, татар йортының эчке күренешен өйрәнде. Ул ясаган акварель этюдлар соңыннан күп күргәзмәләрдә тамашачы хозурына тәкъдим ителде.

Дәрдемәнд сынын минем күз алдымда хасил итте ул. Башта бал-

чыктан, аннары гипстан әвәләде. Шуннан соң гына мәрмәргә тотынды. Бүген Язучылар берлегендә сакланган Тукай сурәтенең барлыкка килүенә дә шаһит булдым. Шагыйрьнең иңнәрен остазым миннән кучереп ясады.

Бакый ага әнинең ике сурәтен «язды». Аның берсе – кечкенәсе – Урманче музеенда, икенчесе миндә саклана. Һәрдаим гастрольләрдә йөргәнгә күрә, әти, Бакый аганың кыставына карамастан, портрет ясатырга вакыт таба алмады.

Җәй көне әни, гадәттә, Кызыл Байракта ял итә иде. Бакый ага да бу авылны үз итте. Рөстәм Яхин да биредә еш кунак булды. Иделнең салмаклыгы, киңлекләренең гүзәллеге җанны тынычландыра, тормышның һәрвакыт шулай кабаланмыйча-ашыкмыйча бер көйгә агачагына ышандыра иде...

«Тәнкәең ак». Дәрдемәнднең «Рәсем» шигыренә иллюстрация. 1968

Тагын бер мөһим хатирә. 1970 елда алты яшь рәссамның (Герман Иванов, Владимир Нестеренко, Рәшит Фәттахов, Игорь Башмаков, Евгений Голубцов һәм мин фәкыйрегез) уртак күргәзмәсе оештырылды. Хәзер аны яшьләрнең Беренче күргәзмәсе дип атау гадәткә керде. Әмма Бакый ага булмаса, бу чараның язмышы ничек хәл ителер иде әле – билгесез. Ул чакта комсомол оешмасында шөбһә туган, икеләнә калганнар: оештырыргамы, оештырмаскамы? Мондый күргәзмә совет сәнгате өчен ят, кирәксез нәрсә, дигән фикер белән тарткалашкан алар. Минем гозеремне тыңлап, комсомол обкомына барган Бакый ага гына мәсьәләне уңай хәл кылып кайта алды: күргәзмәне шул ук көнне оештырырга булдылар. Чара халык арасында зур кызыксыну уятты...

Бакый ага мәңгелеккә киткәнче Казанда яшәде. Берничә тапкыр Урта Азиягә барып кайтырга гына бүленде. Бу яклар аны, чыннан да, әсир иткән иде, күрәсең.

...Ябалдашлары никадәр җәелеп үсмәсен, агачны барыбер тамырлары гына чын агач итә. Без дә тормышыбызның күпмедер өлешен яшәгәч, артка – башлангычыбызга борылып карыйбыз, теге яисә бу вакыйгаларның сәбәпчесе булган «тамырлар»ны барлыйбыз. Бакый ага Урманчедан алган сабакларны мин гомерем буе хәтерләдем һәм әлегәчә хәтерли киләм. Ләкин остазлыгының төп күрсәткече итеп, барыбер, мәкаләдә телгә алынмаган сыйфатын китерер идем: ул, сәнгать юлын сайладың икән, гомер бу шул сайлаган юлыңа тугры калырга, көчеңне дә, вакытыңны да кызганмыйча иҗат итәргә өйрәтте. Һәм мин аның бу өйрәтмәсеннән тайпылмыйча яшәргә тырыштым.

Миләүшә Талипова әзерләде. ■

Бакый аганы сагыну

Дания Гайнетдинова

«Сагыш». Агач.
1966 ел

Яшьлек еллары хатирәләрен искә төшереп шул еллардагы фотосурәтләрне актарып утыр-ганда Бакый ага Урманченың Идел буенда учак тергезеп уха пешергән чагын объективка алган фоторәсем килеп чыкты. Уң кулында икмәк кисәге, сул кулы кесәдә, ә күзләре, ни турындадыр уйланып, учакка төбәлгән. Янәшәдә Идел өстендә моторлы көймә тибрәлә. Бу күренеш үзе бер иҗат әсәре!.. Ни турында уйланасың, Бакый ага, дип дәшәсе килә. Мөгаен, яшәеш, иҗат, туасы көннәр хакында уйланып баккандыр ул. Моннан ярты гасырга якын элек төшкән әлеге фото, бераз төсен үзгәртсә дә, гаҗәеп ихлас фотосурәт.

«Бибинур».
Картон, карандаш

Бәлки, аның Күл Черкенен, авылының гүзәл табигатен исенә төшереп уйланып торган мәледер бу? Ирексездән, күңелдә аның үзе язган шигъри юллары яңара:

Черкендә ындырыбыз,
Зөя буенда,
Салтыкта ишегалдында
Иген сугу дүртләп-
алтылап.
Кайда син,
бәхетле сабыйлык,
Күл Черкене урамыннан
Яланаяк күл буена
йөгергән чаклар?..

Әйе, Татарстанның һәм РСФСРның халык рәссамы, Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Бакый Урманче – татар рәсем һәм сынлы сәнгатен профессиональ дәрәҗәгә күтәргән зур осталарның берсе. Ул Татарстанның Буа районы (элеккеге Тәтеш өязе) Күл Черкене авылында 1897 елның 22 февралендә дөньяга аваз сала. Әнисе Мәхҗүбә абыстай белән этисе Идрис хәзрәт Урманчелар, аңа игелекле гомер теләп, Бакый исемен юкка гына сайламаганнардыр. Гомер бакый татар дөньясында билгеле шәхес булып, халкына хезмәт итсен һәм аның үзен дә милләте онытмас, дип юраганнардыр, мөгаен. Күл Черкененең шифалы тәмле суы, гүзәл табигате аны сабый чагыннан ук иҗатка илһамландырган:

«Самавыр янында»

Комлык. Туплауда кара- терлек
Җылы су коена,
Без уйныйбыз
комда кабык сикереш...
Чибәр кызлар, киленчәкләр
Аллы- гөлле гүзәл киемнәрдән
Басмадан гел суын алалар.
Йомшак су чәйгә яхшы икән,
Шундый судан чәй
эчәләр әби-апалар...

Бакый аганың әлеге шигырь юлларын ятлый-ятлый аның үткәнен барлыйбыз.Ун яшьлек сабыен ничә чакрымнарга Казанга – «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга илткәндә Идрис хәзрәт ниләр турында уйланды икән?.. Кем белгән, әтисе әлеге мәдрәсәгә укырга бирмәгән булса, Бакый ага, бәлки, Г.Тукайны якыннан ук күрми дә калган булыр иде. Дөрес, ул Тукайны узып барышлый күргәләгән, очраштыргалаган булган, ул аралашырга бик яратмый иде бугай, дип сөйләгән язмасы бүген дә радиобыз фондында саклана. Бәхеткә, аңа 1913 елның салкын апрель төнендә, дус шәкертләре белән бергәләп, Клячкин хастаханәсендә шагыйрьнең баш очында Коръән хәтем итү, ягъни Коръән чыгу насыйп була. Әлеге чыгышында Бакый ага ул турыда да искә ала. Шул чагында үсмер Бакый шагыйрьнең йөз чалымнарын, күңеле тулы шигырь уты янып торган яшь Тукайның сүнә баруын эчке дөньясына кадәр йөрәк түренә сеңдереп куйган булгандыр. Югыйсә, күпме еллар үткәннән соң, шагыйрьнең скульптур портретын мәрмәрдән мәңгеләштермәс иде.

«Сепарат янында». Киндер, майлы буяу. 1928 ел

Төмәндә иҗат сәфәрендә булганда мин аның безгә нәмәгълүм тагын бер эшен күреп кабат сөендем. Анда шул төбәктә яшәп иҗат итүче журналист, Бакый агаларның гаилә дусты Бибинур Сабирова сурәте.

– Мин Бакый абый белән Флора ханымнарда еш кунак була идем. Көзге көннәрнең берсендә кабат Казанга Бакый агаларга килдем, – дип башлады Бибинур апа әлеге картина турындагы хатирәсен. – Килгән саен бәйләү алып киләм. Бу юлы Бакый агага җылы свитер бәйләп утырам. Бакый ага каршыма утырды да: «Син бәйләвеңне бел, миңа игътибар итмә», – дип мине рәсемгә төшерә. «Бу рәсем миндә генә саклана», – диде әңгәмәдәшем. Рәсемдә сурәтләнгән Бибинур апаның җылы мамык свитерын Бакый ага өстендә күпләр күргәндер дә әле. Тәне-җаны җылыга сусаган чакларда Флора апага: «Бибинур»ны китер әле», – дип, шул мамык свитерны киеп куя торган булган.

***

Кабат аның 1972 нче елда Идел буенда төшкән фотосына күз салам... Көймәдә йөзәргә дә ярата иде шул Бакый ага. Югыйсә, үзе дә бер картинасын «Җилкәнле көймәдә» дип атамас иде. Идел аның өчен диңгезгә тиң елгаларның берсе булгандыр. Идел генә микән, Зөя елгасын да никадәр зурлап, йомшак суы чәйгә яхшы икән, дип язмаган булыр иде:

Ничә еллар шулай агасың,
Бормаланып, ярып татар саласын.
Бер ягыңда калдырасың никтер,
Тау ягының Буа каласын...

Бакый аганың Беренче бөтендөнья сугышы чорында армиягә алынып, андагы Австрия хәрби әсирләреннән рәсем сәнгатенә өйрәнүе дә бер гаҗәеп күренеш. Гимнастерка һәм кырыс солдат тормышы аның иҗатка булган омтылышын сүндермәгән, ә бәлки аңа иҗат дәрте өстәгән, дияргә җирлек бар.

Бакый ага Урманче башта Казанда сәнгать мәктәбендә укый, аннары Мәскәүдә Югары художество-техник остаханәгә кереп, белемен камилләштерә. Аңа, мөгаен, әнисенең кул эшенә, чигүтегүгә осталыгы да берникадәр этәргеч биргәндер. Ә бәлки бабасы Хәсән Урманченың буяучы булуы тәэсир иткәндер. Сабый чагыннан ук гаиләдә туку, чигү кебек халык иҗатының якынлыгы ярдәм итми калмагандыр. Балачагында ук рәсем ясап, әвәләп төрле уенчыклар эшләү күңел таләбе булгандыр, мөгаен.

Язмыш аны Мәскәүгә, Донбасска да илтә, Алма-Ата, Сәмәрканд, Ташкентта да яшәтә, кабат Казанга да алып кайта. Кайда гына яшәп иҗат итсә дә, аның әсәрләре үзебезнең татар дөньясына алып керә дә көй-моң дәрьясында йөздерә, хәтта сагыну-сагышта уйландыра. Аның «Самавыр янында» яисә «Сепарат янында» дигән картиналарын гына күрегез, чын татар авылы өенә



килеп кергән кебек буласың. Ә «Сагыш» әсәре безне уйга сала, тетрәндерә, бәгырьләрне айкый. Бакый ага шушы әсәре белән генә дә тарихта үз урынын алган олы шәхес. Бу әсәрдә тулы бер роман язарлык образ бар. «Ибн Фадланның Болгарга килүе» әсәрендә дә нинди тирән мәгънә ята. Аның тарихи шәхесләребез, әдәбият-сәнгать әһелләре, ялкынлы революционерларга багышланган скульптур портрет иҗат итүе, шамаилләре халкыбызның рухи байлыгын һәм илаһилыгын, кыюлыгын тасвирлый. Бакый ага илебездә иҗат кешесенә бераз чикләүләр булган заманда да шул чор идеологиясенә каршы тору чарасын таба. Киң күләмле пейзаж һәм натюрмортлары, портретлары аша туган ил табигатен, халкын зурлый, милли үзаңыбызны уятырлык әсәрләр иҗат итә.

Бакый ага татар халкының иҗат дөньясында киңкырлы, талантлы, олы шәхес. Аның, скрипка кылларын тартып, халкыбыз җырларын, бәет, дастаннарын җырлап утыруы үзе бер дөнья. Ул аларны башкарып кына калмыйча, ак кәгазь битенә теркәп тә барган. Ә үзе иҗат иткән тирән мәгънәле шигырьләре кемнәрне генә битараф калдырыр икән. Гомере буе үзе кичергән, күргән-белгәннәрен бөртекләп, көндәлеккә теркәп бару бәхете бик сирәкләргә генә биреләдер. Безнең «Татарстан» радиосының алтын фондында аңа багышланган тапшырулар һәм останың үз тавышы да саклана. Сагынган чакларда без аңа сыгынабыз...

Идел буенда уха пешергәндә уйланып торган чагы сурәтләнгән фоторәсем дә аның милләт язмышы турында уйлануына бер дәлил сыман. Сагынабыз сине, Бакый ага, юксынабыз, олы иҗатыңа табынабыз, диме, ни диярсең... ■

Миллият сүзлеге

Адлер Тимергалин

ПӘРИ *ф.* – «Җен төркеменнән иң матуры». Күчерелмә мәгънәдә – чибәр кыз. Борынгы төрки телдә: «яхшылыклы рух», «фәрештә» һәм «чибәркәй» мәгънәләренә ия булган. «Ислам на европейском Востоке» энциклопедиясе *пери* сүзен һинд-европа телендәге «пер» – тудыру, дөньяга чыгару сүзе белән бәйли.

Татарда *дию пәрие* төшенчәсе дә бар. *//Пәри кызы. Мунча пәрие. Шекә пәрие.* Ләкин Тукайда таз малайга казый: «*И таз пәри*» – дип эндәшә. *Пәри иялəшкән (пәри иләшкән, пәри илләшкән)* – пәри коткысына бирелгән (кеше), пәри оялаган (йорт, җир). *Пәрии руй (ф.)* – пәри кызыныкыдай матур йөз.

Иран мифологиясендә пәриләр – гадәттә чибәр хатын-кыз рәвешендәге гайре табигый затлар. Аларның явызлары да, яхшылык кылучылары да була, имеш. Пәриләрнең патшалары һәм патшабикәләре дә бар. Пәриләр кешегә кереп ояларга мөмкин, ул чагында кеше пәри сыйфатларын ала. Халык ышануынча, пәриләр еш кына бакчаларда күгәрчен рәвешендә күренәләр, имеш.

Ир затыннан булган пәриләр фольклорда сирәк очрый һәм гадәттә алар пәри кызларының әтисе, туганы яки хуҗасы була. «Кыйсса-и Йосыф»та үзенең гүзәллеге белән ирәя башлаган Йосыфка Җәбраил килеп, аңа «хак сәнгатен» (халик кылучы Аллаһ иҗатын) күрсәтә: «Өченче көн бер шәһәргә кәрван керде, Шәһәр халкы һәммәсе дә пәри иде, шунда Йосыф пәриләрнең йөзен күрде: Һәрбересе Йосыфтан да чибәр имди». Шушы илаһи хакыйкатьне аңлагач, Йосыф тәүбә кыла.

«Кыйсса-и Йосыф» поэмасының бер версиясендә түбәндәге юлларга тап булабыз: «Адәм углы белән бер пәри дә булган, Йосыф белән дә шулай бер пәри туган, Һәр кем туса, бер пәри дә туып торган, Әгәр үлсә, ул пәри дә үлгән имди».

Татарда «Пәри башка, җен башка» дигән сүз бар (Нәкый Исәнбәт: «Пәри – Иран мифы, җен – гарәпнеке булуы белән чыннан да башка-башка», – ди), ләкин кайчагында бу төшенчәләр арасында кискен чик үткәрү кыен. Шуңа күрә еш кына алар «җен-пәриләр» исеме белән берләштерелеп тә искә алыналар, ә «Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге»ндә, алдарак күрсәткәнебезчә, пәригә «җен төркеменнән иң матуры»

*Дәвамы. 2014 елның 3 нче санынннан басылып килә.

В.Васнецов. «Сирин һәм алконост». 1896 ел

дигән билгеләмә бирелә. Җен-пәриләр гарәпчә – *әньяб-әгъвәл.*

Халык ырымнарында пәриләрнең исемнәре дә телгә алына. Мәс., егылган җиргә *чалпу ташлау* йоласы булган. Бу вакытта укыла торган «чалпу догасы»н кәгазьгә язып, шунда тугыз пәри исемен дә язганнар, болар: а, гу, ка, ха, хү, сәр, шәр, хә, мә «исемнәре». (Казан арты – Дөбъяз якларында язып алынган, Ф.С.Баязитова.)

«Пәри» сүзенә охшаш яңгырашлы мәгънәдәш сүзләр чуаш, мари һәм удмурт телләренә дә хас.

Диалектта – *пир* (Мордва республикасының Ләмбрә һәм Рузаевка яклары сөйләшендә – *бес, черт* мәгънәсендә). *//Пир сугу* – җен кагылу. *Пир балалары кебек чинәшә-чинәшә уздылар йәшләр урамнан.*

«Пәри» рус теленә гадәттә *пери, фея* дип тәрҗемә ителә, ә «җен» – джинн.

ПЕРМЬ – Төньяк Уралдагы иң зур шәһәр. Казан сарае Боерыкханәсе (Приказы) карамагында булган җирләрдә 1723 елда нигезләнгән. Башта, 1568 елда Кама елгасы буенда Брюханово авылы барлыкка килә, аннары бакыр кою заводының поселогы оеша. Шәһәр дип аталуы 1780 елдан. 1708-1781 елларда Казан губернасына кергән.

Борынгы рәсми кәгазьләрдә һәм сөйләм телендә *Пермь* татарча *Пирмә* дип аталган. *//Пирмәгә пароходта һәм аннан Екатеринбургка тимер юлда, аннан Чиләбе аркылы Троицкига почта атларында бардык.* Сөләйман Аитовның хатирәләреннән.

Борынгы рус елъязмаларыннан ук билгеле булса да, Пермь атамасының этимологиясе аныксыз. Аны коми телендәге *парма* (тайга) сүзенә бәйләп, шулай ук Скандинавия сагаларыннан мәгълүм *Биармия* (төньякта урнашкан бай бер ил) атамасы нигезендә аңлатырга тырышып карадылар, әмма бу мәсьәлә һаман ачык килеш кала, чөнки, әйтик, Биармиянең Ак диңгездән көнчыгыштарак урнашуы мөмкин түгел.

РИЗЫК г. – 1. Ашамлык, азык. Коръәндә – Аллаһ кешегә бирә торган көндәлек икмәк (Инҗилдә русча – *хлеб насущный*). Шуңа күрә Аллаһыны *әр-Рәззак* – Ризыкландыручы дип тә атыйлар. *//Ризыгы киң булуын һәм гомеренең озын булуын теләгән кеше туганнары белән элемтәне өзмәсен.* Хәдис. *«Оялган кемсәнең ризкы булыр тар».* Габделҗәббар Кандалыйдан. *Бәндәне ризык дигән кыймылдатыр.* Акмулла. *Ризыгын кыю* – берәүнең гомерен кисү. 2. Диванга теркәлгән кешеләргә 638 елда Гомәр

хәлифә билгеләгән ашамлык паегы. Мисырда, мәсәлән, бу паекка 25 кг бодай, 1,5 л үсемлек мае, шулкадәр үк серкә һәм беркадәр ит кергән. Сүриядә бодай паегы 18-19 кг, Гыйракта 25 кг чамасы тәшкил иткән. Соңрак гаскәриләрнең хезмәт хакын да «ризык» дип атаганнар (русча – *довольствие*). Патша Россиясендә, мәсәлән, сугыш яки хәрби походлар вакытында сугышчыларга көн саен ипи урынына ике кадак сохари бирелә торган була.

Ризыкның күплек саны шәкеле – *әрзак*.

РИМ – Италиянең башкаласы. Итальяннар үзләре аны *Рома* дип атыйлар. Шәһәргә исем шундагы Тибр елгасының борынгы исеме *Рома* буенча бирелгән, имештер, Рим шәһәрен нигезләгән *Ромул* исеме буенча түгел.

Хәзерге татар телендә кабул ителгән Рим атамасы безгә русчада бозылган килеш килеп керә (шундый ук метаморфоза Франциянең башкаласы *Париж* белән дә кабатланган, дөрес язылышы *Пари* булырга тиеш иде).

Асылда элекке татарча чыганакларда Рум атамасы да кулланылып килгән. *//«Рум» сүрәсе. Баба Румия* – Рим папасы. *Рум (Румистан)* – Византия (Көнчыгыш Рим империясе). *Рум иле. Румия хисабы* – Рим императоры Юлий Цезарь керткән ел хисабы, Юлий календаре (*Юлиан календарь* дип әйтү – хата).

Юллар Римга илтә. Бу сүзләрне француз әдибе Лафонтен афоризмы дип саныйлар.

РИШВӘТ *г.* – Бирәүнең үз файдасына эшләсен өчен икенче берәүгә биргән акчасы, бүләге; алымчак, бирмә. Русча – *взятка. //Ришвәте хор* – ришвәт алучы. Ришвәт алучыны халык телендә *алымсак* дип тә атыйлар. «Татарча-русча сүзлек»тә (1966) ришвәт алучы мәгънәсендә тагы *кулагай* сүзе теркәлгән. Себер татарлары мондый кешене *алгыр* дип атыйлар икән.

РИШВӘТЧЕЛЕК *гт.* – Ришвәт алучылык. Борын-борынгыдан килә торган бу яман чир патша Россиясендә, аннары СССРда һәм бүгенге Россия Федерациясендә гадәттән тыш көчле тамырлар җибәреп, асылда башка бик күп җинаятьләрне каплауга һәм йомып калдыруга хезмәт итә торган бер криминаль факторга әйләнде.

XIX гасыр урталарында Казан университетында укыткан профессор Д.И.Мейер ришвәтчелекне рус тормышына хурлык тамгасы сала торган яман шеш дип саный. «Сез адым саен, гомерегезнең һәр мизгелендә, бернинди кыенлыкларга яки корбаннарга карамастан, аның белән көрәшергә тиешсез», – дип студентларга мөрәҗәгать итә ул. Аның бу сүзләре бүген тагы да актуальрәк яңгырый. Хәер, яңгырамый шул... Чөнки ришвәтчелеккә каршы көрәшергә тиешле органнарда һәм оешмаларда эшләүче чын мәгънәсендә *мошенниклар* үзләре үк ришвәт хисабына типтереп яшиләр һәм авыру җәмәгатьчелек каршында эш майтарган намус ияләре булып кыланалар гына.

Шунысы көн кебек ачык: монда – ришвәтчелеккә каршы көрәштә – «гайкаларны» әкрен-әкрен генә борып тыгызлау, ягъни эволюцион юл тиешле нәтиҗәне бирмәячәк, революцион чаралар кирәк.

РОССИЯ ТАТАР ШӘКЕРТЛӘРЕНЕҢ БЕРЕНЧЕ КОРЫЛТАЕ – 1906 елның 10-15 майларында Казанда үткәрелгән. Корылтайны Ислах комитеты җыя, ә аның программасы, чыгышлар, шул җөмләдән мәдрәсәләрдә Ислах турындагы чыгыш та, Фатих Әмирхан тарафыннан яки аның җитәкчелегендә әзерләнә. Корылтайның рәисе дә Ф.Әмирхан булган.

Шәкертләрнең икенче җыелышы 1907 елның җәендә шулай ук Казанда үткәрелгән. ■

Милләт, халык, кабилә, ыру исемнәре – этнонимнар бик борыннан килә. Шуңа аларның этимологиясе – төп мәгънәсе дәгъвалы да була. «Йөз этнонимга берсе дәгъвасыз булганны табу да кыен», – ди тел галиме Никонов.

Бер үк халыкны төрлечә атап йөртәләр. Мәсәлән, урыслар башкортны башкир-башкирин дип атый. Казакъ – истәк, үзбәк – нугай, ди. Татар да төрлечә атала: урыс – татарин, ди, мари – суәс, удмурт – бигәр, чуваш – тудар, инглиз – тартар, таҗик нугай дип йөртә һ.б. Бу да тарихи мәгънәне табуны кыенлаштыра.

Ф.Энгельс, этнонимнарның


Татрадио

Әдәби-драматик тапш. бүлеге

Хөрмәтле иптәшләр!

Казандагы белеш-танышлар: – „Ник син радио аша тел хак. тапшыруларда катнашмыйсың?" диләр. Катнашырга булдым. Бу мәкалә башы булсын шуның.

Элек минем 2 мәкаләне биргән идегез. Вакыт күп үтте, – нигездә юктыр!

Бер нәни мәкаләгә язсагыз, бик хуш булачак.

Сәлам белән Йосыф Гәрәй

26.II.80

Тел. 22-20-64

450078 Уфа-78

Айская 76, кв. 11

Этнонимнар ни сөйли?

Йосыф Гәрәй

күбрәге уйлап, аңлап кушылмагандыр, очраклы рәвештә килеп чыккандыр, ди. Әмма күп халыкның үзен-үзе кушкан исеме «кеше» мәгънәсендә, имеш. Күрәсең, ул «чын кеше» дип әйтү булган. Хосусан, «ненец» дигән сүз һәм коми халкының элекке этнонимы «мурт» – кеше дигәнне белдерә, диләр галимнәр.

Шушы искәрмәләрдән соң, Татарстанда, Башкортстанда яшәүче халыкларның исемнәрен байкап чыгыйк.

«Ар» – башкорт, татар удмуртны шулай атый. Бу сүз дә «кеше» мәгънәсендә, ә «удмурт» ике кисәктән тора: «уд» (үсенте, шытым) һәм «мурт» – үрә әйткәнчә, кеше. Бергә, күрәсең, «үрчемле халык» яки «өлгергән халык» дигән сүз була.

«Башкорт»ны төрлечә аңлатып карыйлар. Борынгы телдә бүре – «корт-корыт» аталган. «Йосыф вә Зөләйха» поэмасында да бүре гел «корт» дип атала. «Башкорт» сүзен икегә бүлеп, «баш» һәм «корт»ны «баш бүре» яки «бүре башы» дип аңлатучылар бар. Илләмәгәр «баш төркем» – «баш кабилә» дип аңлау дөреслеккә якындыр. Корт (икенче төрле: кор) сүзенең бүтән мәгънәләре дә бар: өем, өер, төркем, гаскәри бүлек һәм башкалар.

Элек авылның гомуми йомышларын башкарган авыл картларын «ирләр коры» дигәннәр, кораллы төркем башлыгы «корбашы» аталган. Замандаш

яки бер полкта, бер походта булган кеше мәгънәсендәге «кордаш» та шул ук «корт-кор» сүзеннән. Соңгы вакытта урыстан кергән «гурт» та шушы тамырдан. Монда «корт» сүзе чит телдә күп йөреп, аз гына үзгәреп, кире кайтты. Хәзер терлек-туар көтүләрен «беренче гурт», «икенче гурт» дип тә әйтәләр.

Башкортлар хакында тәүге мәгълүматны Әхмәд ибне Фазлан (гарәп патшасының Идел буендагы Болгар дәүләтенә килгән илчесенең сәркатибе) 922 нче елда язып калдырган. Башкортларны ул Иделгә якын җирдә, Кинәле су төбәгендә очраткан һәм «башкорд» дип язып алган. Фазлан (*Фадлан.* – **Ред.**) күргән башкортлар баш (ягъни зур, өлкән, баш, дәү...) «корт-кор» (ягъни ыру, йорт, яисә аймак, ил, кабилә, ара, түбә...) булгандыр. Соңыннан бу сүз гомум атамага әйләнгән.

«Мари» сүзе борынгы сармат халкы теленнән калганга охшый. Безнең эрадан 6-7 гасыр элек Идел-Урал арасында сарматлар мариларның ерак әбибабаларына күрше булып яшәгәннәр. Бу этнонимны, күрәсең, алар биргән. Шушы рәвешчә, халыкка күрше ил биргән исем тарихта еш очрый. Мәсәлән, «татар» этнонимы да читтән килгән.

Сарматлар беренче гасырда көньякка күченәләр һәм «Роксалан Алан» исемен алалар. Аларның калдык нәселе – бүгенге осетиннар. Алар телендә «мари» сүзе булмаса да, аларга кардәш көрд телендә әле дә «мари» сүзе «кеше» дигәнгә тиң. Бу сүз «бәлүҗи» (белуджки) халкы телендә дә бар.

Башкортстанда «төмән» дигән халык та бар. Алар – татарлар. Алтын Урдада ил төмәннәргә («ун меңнәр»гә) бүленгән. Бер төмән ун меңлек гаскәр бирергә тиеш булган. Бүздәк, Каргалы, Шанлыкул һ.б. як төмәннәре әнә шундый идарә бүлеме кешеләре, мөгаен.

«Мукшы» ыруы – мордва халкының бер өлеше («Мокша»). Башкортстанга шул ыру вәкилләре килгән. Шуңа бөтен мордвага мукшы диләр. Бу атама Мордовиядәге елга исеменнән алынган. Мондый хәлләр дә бар: Танып буенда (Башкортстанда) Танып ыруы оешкан. Уфа суы буенда «Үпә» ыруы яшәгән.

«Урыс»ларның этнонимын рус-русый (сарый) сүзеннән, диләр галимнәр. Мондый «төсле этноним»нар бер урыста гына түгел. Сары уйгыр, кара кыргыз һ.б. бар. Борынгы кыпчаклар да «коман» аталган, ягъни «сары», чөнки алар сары чәчле, зәңгәр күзле булган. Урыслар аларны шуңа половцы дип атаган, чөнки «половый» – сары дигән сүз.

«Татар» этнонимын Европага 1223 нче елда монголларның алдынгы отряды китерә. Ул отряд «татар» дигән кабиләдән торган. 1240 нчы елларда Алтын Урда дәүләте төзелгәч, аның кул астындагы төрки халыклар (болгар, башкорт, кыпчак, алтайлар, мангыт, баймаклы һәм элекке хазар, печәнәк, авар, угызуз, гунн-һунн калдыклары – барысы да хаким халык исеме белән татар дип аталган. Революциягә чаклы азәрбайҗаннар да татар дип атала иде.

«Татар сүзе» ерак Шәрыкънең кайбер аз санлы халыклары телендә «оста укчы» дигән төшенчәне бирә, ди. Кытайлар монголларның татар кабиләсен «тата» дип йөрткәннәр. Чөнки Кытай телендә «р» авазы юк. Ә бу сүз, имеш, «ят телле халык» мәгънәсендә. Бер этнонимның ике мәгънәдә булуы да һич тә гаҗәп түгел.

«Типтәр» – милләт исеме түгел. Башкорт ырулары белән килешеп, килеп утырган кеше, «буш җирне эшкәртүче» – колонист дигәне булыр бу сүз. Аны «дәфтәр», «типчү» сүзләре белән бәйләргә теләүчеләр дә бар. Әмма аңа һич нигез юк.

«Типтәр» сүзен борынгы иран теленнән табалар галимнәр. Шулай булгач, бәлки, ул сармат сүзедер. Сарматлар бит иранча сөйләшкәннәр.

«Украинец» – окрайна – бер читтәге җир дигән сүздән туган. Инкыйлабка кадәр Украина – Малороссия, украинлылар «малорус», дип аталалар иде. Инкыйлабтан соң бу терминнарны фән кулланмый. ■

Чырткемесь

Фәйрүз Госман

1991 ел. Удмуртия башкаласы Ижауга сәфәр чыктык. Үткән атнада барган егетләр чират торып та алып кайта алмаган «Москвич»ны алып кайтуны безгә йөкләделәр. Автозаводка килсәк – андагы халык! Чират кырмыска оясыдай мыжлап тора. Нишләргә?! Күренеп тора – атна-ун көн ятсаң да, машина алу бәхете тәтемәячәк.

Машина җибәрергә дигән таныклыкка кул куярга тиешле баш инженер янына бер-бер артлы керә торалар, амин тотып чыга торалар – кул куймый, бүгенгә машина юк – бер атнадан, бер айдан килегез. Юк, мин әйтәм, болай булмый, моны кул куйдыртырдай берәр көчле «аргумент» табарга кирәк, яки берәр олы түрәдән «звонок» бирдертергә. Башкача өмет юк, эзләнәбез, уйланабыз, сәгать үтә, звонок бирердәй түрә дә, аргумент та табылмый. Шулвакыт яныпызга шунда эшли торган бер егет килеп, тәмәке тартырга утырды. Сораштырабыз моннан – ничек итсәк, машина алып булыр икән, дибез. Бу да ярдәм кулы сузардай кеше булып чыкмады. Шулай да ул теге инженерның удмурт кешесе булуын әйтеп һәм берничә удмурт сүзен өйрәтеп китте. Шуннан, ярар, үткән көн үткән, кереп чыгыйм әле, мин әйтәм, ичмасам, нинди кеше икәнен күреп чыгармын. Кергән уңайга ук:

– Чырткемесь, Геннадий Николаевич! Мин Чаллыдан килгән идем, сезнең белән якын күршеләр. Сез бездән «КамАЗ»лар аласыз, безгә дә бер ИЖ-2715 биреп җибәрсәгез иде, – дип мөрәҗәгать иттем. Шаккатты бу:

– Ничә еллар эшлим, чит республикалардан килгән бер кешенең дә болай матур иттереп удмуртча исәнләшкәне юк иде әле, – ди. Һәм ул, «Машина бирергә», дип, таныклыкка шундук кул да куйды. Ышанмый торам. Чыккач, сорыйлар миннән:

– Безгә айлар буе юк, ә сиңа ничек кул куйды – күпме «төрттең»? – диләр.

– Бер чырткемесь... – мин әйтәм.

Татарстан радиосының
«Тел күрке – сүз»
тапшыруына нигезләп, басмага
***Рөстәм Акъегет** әзерләде.* ■


АЗБУКА
ТАТАРСКАГО ЯЗЫКА
съ
ОБСТОЯТЕЛЬНЫМЪ ОПИСАНІЕМЪ
БУКВЪ и СКЛАДОВЪ,
СОЧИНЕННАЯ
Казанскихъ Гимназій учителемъ,
и Адмиралтейской Конторы переводчикомъ
САГИТОМЪ ХАЛЬФИНЫМЪ,
и Татарскихъ въ Казанѣ слободъ Муллами
въ оныхъ Гимназіяхъ
разсмотренная и одобренная.
Печатана при Императорскомъ Московскомъ
Университетѣ, 1778 года.

Әлифба

(ТР Милли музее фондларыннан)

Татарстан Республикасы Милли музеенда төрле дәвер уку әсбаплары, әлифбалар, китап-дәфтәр һәм каләмнәр саклана.

Татарда беренче дөньяви басма әлифба урысча-татарча төзелә. 1778 елда Сәгыйть Хәлфин тарафыннан нәшер ителгән «Хәреф һәм иҗекләре тулы тасвирланган татар теле әлифбасы» белем бирү әсбапларыннан иң борынгысы. 1787 елда аның «Әлифбаи татар» дәреслеге дә басыла. С.Хәлфин әлеге әлифбаны Казан гимназиясендә укучы рус балаларын татар теленә өйрәтү өчен төзи. Ошбу басмалар белән милли музейның гимназиягә багышланган бүлегендә танышырга мөмкин. Шулай ук музейның фондында да төрле елларда нәшер ителгән дистәләгән татар әлифбасы бар.

Гүзәлия Җәләлева әзерләде. ■

Редакциядән: Арча шәһәрендә дөньяда бердәнбер «Әлифба» музее эшли.


X. Bədiqof
ƏLIFBA
UQI-JAZA
BELMƏVCELƏR
MƏKTƏPLƏRE
ƟCEN
QAZAN TATGOSIZDAT 1937


D. S. SAFIN
UQU KITAVЬ
IKENCE KISƏK
IKENCE KLAS ƟCEN
TATGOSIZDAT
QAZAN 1938

Проф. М. ФАЗЛУЛЛА
ЗУРЛАР ӨЧЕН
ӘЛИФБА

ГАББАС СӘЙФУЛЛИН
ӘЛИФБА
КАЗАН · ТАТГОСИЗДАТ · 1950

А
БУКВАРЬ

«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1916 елның сентябрь ае

Текстны һәм искәрмәләрне басмага Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

Кун сатып мәҗбүри карар бозган өчен

Күптән түгел генә Усиядә[1] Сембер итекчесен капчыкларга олтанлык күн төяп пароходка кергән чакта полиция тоткан иде, һәм ул итекче бу күннәрне Печән базары сәүдәгәрләреннән алганлыгын белдергән иде. Хәзерге көндә бу күнне сатучылар табылган һәм үзләренең сатканлыкларын вә күнне хәзинәгә дигән итекләрдән «икътисад» кыйлып калдырып җыйганлыкларын игътираф иткәннәр [таныганнар]. Боларның һәммәсе өстеннән протокол куелган вә күннәре мөсадәрә ителгән [конфискацияләнгән]. Ахырында вилаять валисе [губернатор] Сембер итекчесе Вахрушинны губернадан күн чыгаруны тыя торган мәҗбүри карарны бозганы өчен бер ай, күн сатучы Габдулла Ваһапов белән Закир Гәрәевне күн сатудан тыя торган мәҗбүри карарны бозганлыклары өчен өчәр ай хәбескә [төрмәгә] ябарга ясаган.

Кояш. – 1916. – №1020. – 13 сент.

Фәкыйрь шәкертләргә иганә

Шәһәр Думасының соңгы мәҗлесендә студентларга ярдәм бирү мәсьәләсе белән мәдрәсәләрдәге фәкыйрь шәкертләргә дә ярдәм бирергә кирәклеген Садри Максуди мәҗлескә гарыз иткән [белдергән] иде. Дума, мондый шәкертләрнең чамасы мәгълүм булмаганга, аларга ни чамада иганә бирергә мөмкин булачагын тәхмин итә [чамалый] алмый калды вә һәммә мәктәпләрдән фәкыйрь шәкертләр хакында мәгълүмат алып, бу мәсьәләне 20 нче сентябрьдә хәл итәргә калдырды. Мәдрәсәләр мөдәррисләре, фәкыйрь шәкертләргә ярдәм йөзеннән, үзләренең мәдрәсәләрендә укучы мохтаҗ шәкертләр микъдарын язып, гласныйлардан беренә бирүләре матлуб [сорала]. Мәгълүмат бер йиргә җыелсын өчен, мәсьәләне күтәрүче Садрый әфәнде Максудига тапшырылуы мәслихәттер.

Мәктәпләрне берләштерү

Соңгы көннәрдә Бишбалтаның имам вә могтәбәрләре, үзара киңәш ясаганнан соң, Бишбалтаның ике мәхәлләсендәге мәктәпләрне берләштерергә карар биргәннәр. Моннан соңра инде Бишбалтаның һәр ике мәхәллә мәктәбе «Бишбалта ислам мәктәбе» исемендә программа илә дәвам итәчәк, «фәлән хәзрәт» вә «төгән хәзрәт» мәктәбе булмаячак.

Кояш. – 1916. – №1021. – 15 сент.

Диянәт вә миллиятне саклау юлына

Евангелистовский урамындагы Исхак мөәзин йорты шушы көннәрдә Печән базары мәсҗеде мәдрәсәсе өчен 24 мең сумга сатып алынган. Моның өчен шәһәремезнең могтәбәранынннан Исмәгыйль Үтәмешов, Габдерахман Ишмо-

* Даталар иске стиль белән бирелә.

[1] Усия – Устье, Казансуның Иделгә койган урынында булган пристань. Хәзер су астында.

ратов, Галим Галиев әфәнделәр бишәр мең, Гайнетдин әфәнде Сабитов ике мең сум иганә иткәннәр.

Кояш. – 1916. – №1022. – 18 сент.

Нишан гали

5 нче драгунский Каргопольский полкның штабс-ротмистры Хаҗи Мөхәммәдовка, дошманга каршы көрәштә имтияз [батырлык] казанганы өчен, кылычлы 2 нче дәрәҗә с.Анна нишаны [ордены] ихсан ителгән.

Кояш. – 1916. – №1023. – 20 сент.

Шәһәр карары вә татар сәхнәсе

Шәһәр Думасының 25 нче август мәҗлесендә электрны икътисад нияте белән, кинематограф вә театрларга гади көннәрдә тамашаны 7 ярым сәгатьтән алда башламаска карар биргәннәр вә губернатор тарафыннан 10 сентябрьдә бу тасдыйк ителгән [расланган] иде. Бу карарга бинаән [нигезләнеп], җомга көннәр вә мөселман бәйрәмнәрен «гади көннәр»дән хисапларга тугры килә иде. «Сәйяр» труппасы артистлары вәкиле Габдулла Кариев, управага гариза биреп, җомга вә бәйрәм көннәрдә бу театрга көндезге 3тән 6гача ут бирерлек итеп әлеге карарны тәсхих итәргә [төзәтергә] сорган вә моның мөселман җәмәгасенә файдалы күңел ачу урыннары наменә кабулга ашырылуын өмид ителгәнлеген белдергән[2].

Кояш. – 1916. – №1024. – 24 сент.

Корбан гаете

Казанның бөтен мәхәлләләрендә корбан гаете шинбә [шимбә] көн, 24 нче сентябрьдә укылды. Казан әтрафындагы [янындагы] бәгъзы карьяләрдә [кайбер авылларда] дә якшәнбе укылганлыгы ишетелә. Оренбургта да шулай ук бер көн соң укылганлыгы аңлана. Безнең Казан имамнарыннан берсе гаетне якшәнбе укырга тиешлеген, үзенең гаммәгә [массага] ияреп кенә шинбә гает укырга мәҗбүр булганлыгын мәсҗедтә җәмәгатькә сөйләгән. Җәмәгать эчендә бәгъзыларының: «Алай булгач, безнең чалган корбаннарыбыз кая китте? Аларның хәле ни булды инде? Елында бер-ике мәртәбә генә килә торган гает көннәрен дә нык билгеләрлек кадәр дини эшлеклелек күрсәтә алмыйсыз!» – дип бәхәс вә тәкдир итүләренә [шелтәләүләренә] каршы имам әфәнде оятлы булган.

Ага-эненең, йортларына алып барып, гаскәри мөселманнарны корбан ите белән зыяфәт [кунак] иткәнлекләре вә кулларыннан килгән кадәр аларга бәйрәмлек тә биргәнлекләре ишетелде.

Соңгы мобилизация нәкъ гәрәфә вә гает көннәрендә булуы сәбәпле, халыкның зур бер кыйсеме [өлеше] ул көннәрне гает итәргә бушый алмады.

Гаетнең икенче көнендә көндез Большой театр бинасында бирелгән татарча спектакль, көннең начарлыгына карамастан, бик күп караучы җәлеп иткән иде. Уйналган нәрсәнең искергән нәрсә булучылыгыннан вә вакытының да көндез булучылыгыннан булса кирәк, театрга килгән халыкның 99 фаизе [проценты] гавамнан [гади халыктан] гыйбарәт иде. Могтәбәран вә зыялылар таифәсенә мәнсүб [төркеменә караган] халык юк диярлек дәрәҗәдә аз иде. Уен, гомумән, шома гына үтте вә караучыларның хушына китте.

Кояш. – 1916. – №1025. – 30 сент. ■

---

[2] Газетаның 30 сентябрь санында шәһәр главасының Габдулла Кариев үтенечен кабул итүе һәм уңай җавап бирүе турында мәгълүмат бар.

Вак-вак ләтыйфәләр* һәм хикәя кисәкләре

БЕЛӘМСЕЗ, КАЙСЫ ХАКЛЫ?

Сөйлим әле әбиләрчә хикәят,
Вафасыз дөньядан итеп шикаять.
Бу дөньяда хәзер юк һич төзеклек,
Кая гына карасаң да бозыклык.
Менә яшьләр белән картлар талашта,
Минем сүзем дөрест, дип тарткалашта.
Талаш кызып бара гел моңа хәтле,
Беленгән юк боларның кайсы хаклы.
Хатыннар гел хәзер ирен гаепли,
Ничә төрле гаепне аңа йөкли.
Имеш, аның ире бигрәк йөрәксез,
Тагын акча әрәм итә кирәксез.
Ә ирләр гел, хатыннарда гаеп, ди,
Аларда аз гына аңлау да юк, ди.
Ни алсаң да чыга барсы әрәмгә,
Китә бар акчалар әрәм-шәрәмгә.
Талашалар, язышып, моңа хәтле,
Беленгән юк боларның кайсы хаклы.
Талашалар гәзитәчеләр үзара,
Каләм берлә килешеп парә-парә.
Көчәеп бара һаман чәнчешүләр,
Ничек булып бетәр бу бара-бара,
Син алма кайсыбер журналны кулга,
Шушы талаш белән тулгандыр ул да.
Мөхәррирләр үзара тарткалашта,
Бөтен көчен сарыф иткән талашка.
Талаш кызып бара гел моңа хәтле:
Беләмсез, кайсы хаксыз, кайсы хаклы?

«Астыртын».
«Ялт-йолт» – 1914. – №75. – Б.4.

КАНАТЛЫ АВЫРУ

Надан карт бай докторга барып күренә. Доктор байдан карап, сорашып бетергәч:
– Сездә, әфәндем, «летучий ревматизм», – ди.
Бай:
– Һәм дөрест тә, кайдан белдегез, доктор әфәнде? Минем шул авыруым оча торган булырга кирәк, чөнки кич белән аркам сызлый, ә иртә белән хатынымның янбашлары чәнечә, төшкә таба кәһәр суккан авыру асраугa барып ябыша да, ул, билем-билем, дип акырып ята.

«Өй анасы»
«Ялт-йолт» – 1914. – № 83. – Б.14.

ЯРТЫ БАРМАК

Калын корсаклы, мөтәкәббир[1], иске бер бай хаҗи туй мәҗлесенә килгәч, мәҗлестәгеләр илә күрешеп чыга. Мөтәкәббир хаҗи үзенә тиң санаган бай хаҗилар илә һәм хәзрәтләр илә бөтен кулын сузып гаять мөтәвазиган[2] күрешкәннән соң инде, үзеннән түбән саналган, хаҗи түгел яшь байларга кулының яртысын гына

*Ләтыйфә – мәзәк.
[1] Мөтәкәббир – үз-үзен зур күрүче, эреләнүче, масаючы.
[2] Мөтәвазиган – түбәнчелек белән.

«ЯРАКЛЫ КЕШЕ» (КАНДИДАТ)

Кара син, бу малайны, әле үткән елда гына безнең казармада
мелла иде, хәзер үзе бөтен меллаларга баш булмакчы!

төртеп, ахырда шәкерт сыман бер яшь егеткә җиткәч, бераз чекрәеп карап тора да, аны мөгаллим дип, ерактан гына бер бармагын суза. Егет, аның бармагын кысып, җибәрмичә:

– Хаҗи әфәнде, бу ни эшең? Мине кем дип белдегез?

Бай:

– Кем булырсың, мөгаллимдер син, мөгаллимдер.

Егет (аның бармагын җибәреп):

– Гафу итегез, хаҗи әфәнде, мин мөгаллим түгел, шәкерт кенә әле. Шәкертләр өчен ярты гына бармак тиешле була торгандыр, рәхим итеп миңа биргән бармагыңызның яртысын кайтарып алыңыз, – ди.

«Ялт-йолт» – 1914. – №83. – Б.14.

МАКТАНУ

Укучы:

– Сезнең соңгы расказыгыз миңа бик ошады, хәтта икенче мәртәбә дә бер дә ялыкмыйча укып чыктым.

Язучы:

– Шулаймыни? Икенче мәртәбә дә укыдыгызмыни?

Укучы:

– Әйе! Беренче дәфга бер мәҗмугаи асарда мин ул расказны укыган идем, икенче мәртәбә сезнеке итеп укыдым.

«Ялт-йолт» – 1916. – №105. – Б.13.

Текстны һәм искәрмәләрне басмага ***Рәйсә Шәрәфиева*** *әзерләде.* ■

Мирасворд

Җеп эрләү өчен йон, мамыкны беркетә торган тараклы такта

Нәҗип Җиһанов операсы

... чарадан бичара

Үзбәкләрнең элекке исеме

Хәсән Туфан поэмасы

Совет космонавты

Агачтан кырып эшләнгән тирән тәлинкә, табак (диал.)

Греция-дәге тау

Борынгы грек драматургы

Каз өмәләре вакытында егет-кызларның су буена төшү гадәте

Нурланыш берәмлеге

«Әлүф, яки гүзәл кыз Хәдичә» романы авторы

Одиссей Ватаны

Миргазиян ...

Саф, шеренга

Алдан бара торган гаскәр, авангард (бор.)

Таҗик биюе

Кубрат хан улы

Пөхтә, җыйнак, ипле (диал.)

Шахта, рудник (иск.)

Кытайда элекке озынлык үлчәве

Борынгы грек шагыйре

Казандагы бистә

Теге дөньяда мөселманнарны күккә очырта торган канатлы ат

Кытайда императорлар династиясе

1906-1918 елларда Оренбургта чыккан татарча газета

Купшы, кәяз

«... - Сок» бәете

Дала, сахра, ялан җир, кыр, чүл (иск.)

Мылтык чакмасы

Ашарга яраклы үлән

Бер пот әйбер сыешлы агач яки калай савыт

Кара диңгез буенда яшәгән борынгы кабилә

Яшертен сүз, хәбәр, донос

Ау кошының башына кидерелә торган калфак (бор.)

Кадер-хөрмәт (диал.)

Композитор ... Хәсәнов

Язучы ... Гаффар

Теркәгеч

Ишек, капка бите

Карл ...

Ел (иск.)

Рәис Габдулла төзеде.

8 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: көбә, Сәйф, Нәби, Носы, Архимед, Гулиа, Фо, Тенеки, укалы, ТНТ, һун, урда, Спартак, кып, алача, Имәни, Исәнбәт, әни, тәбә, мум, серб, ияр.
Өстән аска: груһ, кси, өмә, кузы, балпан, Әюп, Әмири, Нокса, Хатыйп, би, Аймәт, Мансур, этәмби, натр, бу, сандык, Дали, Әмир, Итака, Йосыф, чин, октава.

«Галия» мәдрәсәсе бинасы. Уфа. 1990 нчы еллар

«Безнең мирас»

елъязмасы / сентябрь

• 240 ел элек (1776)

6 сентябрьдә табиб һәм галим, милләтебезнең гореф-гадәт вә йолаларын өйрәнүче, «Статистик һәм этнографик мөнәсәбәтләрдә Казан татарлары» дип аталган әтрафлы китап авторы Карл Фукс (1776-1846) дөньяга килә.

• 140 ел элек (1876)

13 сентябрьдә Казанда Татар укытучылар мәктәбе (хәзер – Казан педагогия көллияте) ачыла.

• 110 ел элек (1906)

Уфада «Галия» мәдрәсәсе ачыла.

25 сентябрьдә «Карчыга» журналының беренче саны дөнья күрә.

• 90 ел элек (1926)

25 сентябрьдә Казанда яшь язучы Фәхри Әсгать (1901-1926) вафат була.

• 65 ел элек (1951)

«Совет әдәбияты» журналында Габдрахман Әпсәләмовның «Газинур» романы басыла башлый.

• 60 ел элек (1956)

28 сентябрьдә Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрының яңа бинасы ачыла.

23 сентябрьдә Габдулла Тукайның туган авылы Кушлавычта шагыйрьгә һәйкәл куела.

• 50 ел элек (1966)

«Казан утлары» журналында Шәриф Хөсәеновның «Зөбәйдә – адәм баласы» исемле трагикомедиясе басылып чыга.

• 25 ел элек (1991)

12-15 сентябрьдә Төркиянең «Йени форум» журналы «Совет-Төркия хезмәттәшлеге»нә багышланган зур сөйләшү үткәрә. Анда язучылардан Ринат Мөхәммәдиев, Мәдинә Маликова, Разил Вәлиев һәм Тәүфикъ Әйди катнаша.

30 сентябрьдә Татарстан Республикасының Фәннәр академиясе төзелә.

• 15 ел элек (2001)

3 сентябрьдә Татарстан Язучылар берлегендә Татарстанның Казакъстандагы вәкиле Морат Кәримов белән Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллинның очрашуы була. Дустанә әңгәмә дәвамында ике ил язучылары арасында элемтәләрне тагын да ныгыту турында сүз алып барыла. ■

СОДЕРЖАНИЕ

Историческое наследие: «Булгар. Археологические исследования». «Зулейха». А.Мухаммадиев; «Пришлось проявить осторожность, излагая своё мнение...» Р.Гарипов; «История газеты «Йолдыз». А.Максуди; «Наследие Равиля Амирхана». И.Загидуллин; «История деревни – история нации» (Круглый стол).

«Нашему наследию» 25: М.Махмутов, А.Каримуллин: «В каком наследии нуждаемся мы?»

Религиозное наследие: «Сказание об Ишмухаммат хажи». Г.Гатауллин.

Литературное наследие: «Кутадгу билик» (Благодатное знание). Ю.Баласагуни; «Белое облако Чингизхана». Ч.Айтматов; «Каждое его произведение – образец совершенства!» Л.Тимерова; Атилла Расих: «Я продолжаю надеяться...»; «По следам одной книги...» Г.Давыдова.

Художественное наследие: «Луч творчества на лучезарной сцене». А.Зарипов; «Обладатель божественного лиризма». Ф.Арслан; «Мой наставник Баки Урманче». Н.Альмиев; «Тоска по Баки ага». Д.Гайнутдинова.

Слово – украшение языка: «Словарь национальных терминов». А.Тимергалин; «О чём рассказывают этнонимы?» Ю.Гарай.

100 лет назад...: «Казанские вести» в газете «Кояш»: сентябрь 1916 года».

CONTENT

Historic heritage: «Bulgar. The archeological investigation». «Zuleikha» by A.Mukhammadiev; «We had to be very cautious in expressing our thoughts» by R. Garipov; «The history of «Yoldiz» newspaper» by A.Maksudi; «Ravil Amirkhan's heritage» by I.Zagidullin; «The history of village is the nation history» (Round table).

«Our heritage» celebrates 25: «In what kind of heritage do we need?» by M.Makhmutov, A.Karimullin

Religious heritage: «The legend about Ishmukhammat hadji» by G.Gataullin.

Literary heritage: «Kutadgu bilik» («The blessed knowledge») by U.Balasaguni; «The white cloud of Genghis Khan» by Ch.Aytmatov; «Each of his creative work is a sample of perfection!» by L. Timerova; Atilla Rasikh: «I still have a hope ...»; «According the track of one book...» by G.Davidova.

Creative heritage: «The sparkle of art on the radiant stage» by A.Zaripov; «The owner of divine lyricism» by F.Arslan; «Baki Urmanche is my mentor» by N.Almiev; «Missing Baki aga» by D.Gaynutdinova.

Word is a language charm: «The dictionary of national terms» by A.Timergalin; «What can ethnonyms tell?» by Y.Garay.

100 years ago...: «Kazan news» is in the «Koyash» newspaper: September of 1916.

Фәридә Хәсьянова

«Кырлайда беренче көн». Г.Тукайның «Исемдә калганнар» әсәренә иллюстрация. 2016 ел.
Кәгазь, катнаш техника

Фәридә Шаһимәрдән кызы Хәсьянова 1952 елның 11 декабрендә Казан шәһәрендә туа.

Фәридә Хәсьянова – ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның халык рәссамы. «Ак бүре» («Белый волк») әкиятенә иллюстрацияләр сериясе өчен, 1999 елда аңа Бакый Урманче исемендәге премия бирелә. 2004 елда, Россия халыкларының тарихи-мәдәни һәм табигый мирасын саклау һәм үстерү эшендәге казанышлары өчен, Россиянең тарихи шәһәрләр һәм төбәкләр берләшмәсе тарафыннан Нестор-Елъязмачы медале белән бүләкләнә.

Аның хезмәтләрен Татарстанның Сынлы сәнгать музее, «Тукай-Кырлай» музей-тыюлыгы, дәүләт оешмалары сатып алган, шулай ук Россия, Төркия, Литва, Германия, Һиндстан шәхси күргәзмәләрендә дә рәсемнәре бар.



«Болгар кувшины белән натюрморт». 2014.
«Татар сөлгесе» сериясеннән.
Киндер, майлы буяу

www.beznenmiras.ru

БЕЗ – МИРАСЛЫ ХАЛЫК!

«Безнең мирас» белән бергә булыгыз!

ИНДЕКС:

Татарстанда – 54132 (П-2343)

Россиядә – 70275

«Безнең мирас» журналына башкача язылу:

- *www.uslugi.tatarstan.ru сайты ярдәмендә*
- *редакциядә*
- *www.tatpodpiska.ru сайты ярдәмендә электрон версия*

4 612750 670172

«Безнең мирас» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» (Бауман ур., 19; 29/11) кибетеннән, «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), Казан метросы киоскларыннан сатып алырга мөмкин.